ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

# ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№07 (378)
ИЮЛЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

## ЯКУТИЯДӘН СӘЛАМ!

№07 (378)
ИЮЛЬ 2023

16+

**Редакция:**
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур.,
2 тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

# ЗУР ЙӨРӘКЛЕ КЕЧКЕНӘ ИЛ

Җәй – гомернең бер мизгеле, аны матур һәм истә калырлык итеп үткәрергә кирәк. «Татарстан» исә шулай эшләде дә: эссе җәй мизгелен мәңгелек туңлык иле – Якутиядә тотты. Һәм Казанга үзе белән кунакчыл Саха-Якутия турында онытылмаслык тәэсирләр алып кайтты. Басмабызның әлеге санында 1 миллион халкы булган «кечкенә илнең» зур проблемаларны ничек хәл итүе һәм әлеге мәңгелек туңлык хөкем сөргән җылы һәм кунакчыл патшалыкта бер генә мәртәбә булган, берничә вакыт поясын узып, июнь аенда чана шуып караган, Ысыах бәйрәмендә күңел ачканнарның бу уңган халыкның тормыш рәвеше белән танышуы, аңа сокλануы турында язабыз.

Сезнең сәяхәт итәргә яратучы редакциягез.

**Баш мөхәррир:** Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
**Шеф-редактор:** Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
**Баш мөхәррир урынбасары:** Фәридә Әхмәтҗанова
**Бүлек мөхәррирләре:** Руфия Фазылова, Николай Коновалов
**Веб-редактор:** Алсу Троицкая
**Авторлар:** Әхмәт Шакиров, Сафа Гәрәев, Оксана Бирюкова, Муса Юлдашев
**Фотографлар:** Александр Ефремов, Алсу Шакирова
**Дизайн-макет:** Олег Бурилов
**Вёрстка:** Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
**Препресс:** Игорь Глушков
**Корректор:** Айсылу Корманова
**Тышлыкта:** Айталина һәм Дмитрий Петровлар
Александр Ефремов фотосы

**Журнал 1920 елдан нәшер ителә**
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

**Тираж:**
**2 400 данә**
**Бәясе ирекле**

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

**Заказ №:** С–1708
**Басарга кул куелды:** 07.07.2023
**Чыгу көне:** 13.07.2023

**Коммерция директоры:**
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
**Коммерция директоры урынбасары:**
Гөлназ Яруллина,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9655-826-037
**Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:**
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

**Бухгалтерия:**
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

**Редакция советы:**
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛАХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла**

**Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә**

**«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә**
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе: **1026 сум 00 тиен**

**«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:**
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 102 ЯШЬ

# ТАТАРСТАННЫҢ 100 ҖӘҮҺӘРЕ

# БАРЫ ТИК ТАТАРСТАНДА

## РОМАШКИНОДАН ӨЧ МИЛЛИАРД ТОННА

Татарстандагы Тимәш (Ромашкино) авылы янында җир куеныннан бәреп чыккан нефть фонтаны дөньяда иң зур ятмаларның берсе ачылуын хәбәр итә! Бу хәл 1948 елның 25 июлендә мастер Сергей Кузьмин һәм бораулаучы Рәхим Халиков бригадасы тарафыннан борауланган 3 нче номерлы скважинаны сынау вакытында була. Моңарчы күрелмәгән куәткә ия фонтан тәүлегенә 120 тонна сусыз девон нефте бирә! Республиканың көньяк-көнчыгышында ачылган чыганакны Ромашкино ятмасы дип атыйлар. Халыкара классификация буенча ул супергигантлар рәтенә керә һәм дөньяның иң зур ун ятмасы исемлегендә урын ала. Татарстан исә иң бай нефть төбәгенә әйләнә. 75 ел эчендә әлеге нефть чыганагыннан 2,2 миллиард тоннадан артык нефть чыгарыла. Хәзерге вакытта биредә ел саен 15 миллион тоннадан артык углеводород чималы табыла. Ромашкино ятмасының расланган запаслары өч миллиард тоннадан артып китә.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

# ЭЧТӘЛЕК


### акыллы гамәлләр

**4. Казан – алдынгылар сафында**
Көнбатыш очкычларын нәрсә белән алыштырабыз

**8. Бизнес өчен – җәннәт**
Ни өчен «Алабуга» МИЗ Россиядә беренчелекне били

**16. Савым һәм артымнар өчен «цифр» җавап бирә**
Ясалма интеллект авылда нишли

**24. Әзер булганда рәхәт**
Фермерның башы авыртмаган чак

**28. «Кырлай» агрофирмасы**
Татарстанның бәрәңге башкаласы кайда

### игелекле эшләр

**34. Һәркемгә килешле кием**
Милли киемне кемнәр кия

**40. Гасыр үткәч...**
Татар милли киемен кайда яңарталар

**42. Мәңгелек туңлык җылысы**
Якут иле «Татарстан»ны ничек таң калдырды

**50. Игелекле кешеләрнең игелекле гамәлләре**
Ни өчен Яңа Чишмә – дөньяда иң матур урын

**60. Әбидә кунакта**
Элек бәрәңгене ничек өйгәннәр

### мәңгелек кыйммәтләр

**66. Мәхмүт Гәрәевнең мәңгелек көрәше**
Бер татар ничек тулы бер армияне алыштырган

**72. Аксакалларыбыз**
100 яшьлек сугыш ветераныниләр сөйли

**76. Изге чишмә янындагы шифалы ташлар**
Такталачык авылы кай ягы белән гаҗәпләндерде

**88. Истәлекле вакыйгалар**
2018 елгы футбол чемпионатыннан ниләр калды


Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: archive.gov.tatarstan.ru

## Акыллы гамәлләр

# 08.06

**Валерий Фальков, РФ Мәгариф министрлыгы башлыгы, – Казанда, «Формируя будущее» Халыкара мәгариф министрлары форумында:**

– Сыйфатлы белем бөтен дөньяда югары бәяләнә. Шуңа күрә безнең система замана таләпләренә туры килерлек үзгәрешләр кичерә. Ул, үз эченә илебездәге иң яхшы үрнәкләрне туплап, дөньядагы иң алдынгы тәҗрибәләрне өйрәнеп һәм истә тотып, заманчарак һәм уңайлырак була бара. Планлаштырылган үзгәрешләргә карамастан, без студентларның, беренче чиратта чит ил студентларының мәнфәгатьләрен тулысынча тәэмин итәчәкбез.

## Игелекле эшләр

# 14.06

**Сергей Когогин, «КАМАЗ» ГАҖ генераль директоры, – 2023 елгы Петербург халыкара икътисадый форумында, М-11 трассасы буенча пилотсыз йөк машиналарын җибәргән көндә:**

– Әлбәттә, автоном транспорт ягулык куллануны, буш тору вакытын киметәчәк һәм уртача тизлекне арттырачак. Хәрәкәт куркынычсызлыгын арттыру, транспорт хезмәтләренә бәяләрне төшерү, микроэлектроника, мәгълүмати технологияләр кебек яңа бизнесларны үстерү – болар барысы да әлеге проектны тормышка ашырганда булырга тиеш. Киләчәктә әлеге технология кирәк булачак, дип ышанам.

## Мәңгелек кыйммәтләр



# 20.06

**Тимур Ногманов, Әлмәт районы һәм Әлмәт шәһәре башлыгы, – шәһәрдә «Ёлки-10» фильмы күренешләрен төшерү башланып киткәннән соң телеграм-каналда:**

– Бездә кар яуды. Бик-бик күңелле. Барысы да шатлана, барысы да бии. Әйтерсең лә, Яңа ел җиткән. Бик күңелле күренеш.

Фото: tatar-inform.ru

игелекле эшләр
акыллы гамәлләр
мәңгелек кыйммәтләр /

## Бу санда тәкъдим итәбез:

Боинг һәм аэрбасларны **нинди** самолётлар алыштырачак

**Ни өчен** «Алабуга» МИЗ илдә беренчелекне били

Ясалма интеллект авылда **нишли**

Фермерның күңеле **кайчан** тыныч

# ҮЗЕБЕЗНЕҢ ТУ-214. ЫШАНЫЧЛЫ ҺӘМ КУРКЫНЫЧСЫЗ

Әскәр Сабиров

Биш ел эчендә Казан авиация заводы үзендә җыелган Ту-214 самолётлары санын елына егермегә кадәр арттырырга тиеш. Татарстан башкаласында Россия Премьер-министры Михаил Мишустин үткәргән киңәшмәдән соң, мондый гаять зур тизләнешнең чынга ашачагына шик калмады.



– Нichek, машина ничегрәк? – дип кызыксынды Премьер, фюзеляжына «Россия» дип язылган Ту-214 очкычының пилот кабинасына кергәч.

– Яхшы машина. Ышанычлы. Иң мөһиме – куркынычсыз.

– Һәм тагын иң мөһиме – ул тулысынча үзебездә эшләнгән детальләрдән җыелган, шулай бит? – диде Денис Мантуровка борылып Мишустин һәм элегрәк, импортка бәйле елларда, Туполев машиналары тарафдарлары рәтендә булмаган вице-премьердан уңай җавап алды.

Мишустин очкычның яңа салоны белән танышканда, Рөстәм Миңнехановның «болар янында «Боинг»лар ял итә» дигән сүзләренә елмаеп куйды. Танышу вакытында Премьер самолёт экипажын ике кешелек итеп үзгәртү күпмегә сузылачагы белән дә кызыксынды. Конструкторның, документларны тулысынча цифрлаштыруны исәпкә алып, бер ел-ел ярым вакыт таләп ителә, дигән җавабы, күрәсең, Мишустинны канәгатьләндерде.

Премьерның эшнең вагы-төягенә кадәр төшенергә тырышуы үзенә күрә бер билге буларак кабул ителде: авиазавод цехларын карап чыкканнан соң ук граждан авиациясе өлкәсендәге проектлар буенча оештырылган киңәшмә сүз булмаганнан гына сөйләшү булмады. Әлеге фикеремне Хөкүмәт десантының составы көчәйтте генә. Казанда Премьер белән бергә финанс министры Антон Силуанов, вице-премьер – сәнәгать һәм сәүдә министры

Фото: tupolev.ru, goverment.ru, tatar-imform.ru

Денис Мантуров, Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе генераль директоры Юрий Слюсарь эшләде... Барысы да – конкрет карар кабул итү хакына. Иртәгә яки бер айдан соң түгел – биредә һәм бүген.

## МАКСАТ – 2030 ЕЛГА КАДӘР МЕҢ САМОЛЁТ

Шунысын да чамалап була: Казандагы вәкиллекле киңәшмәнең катализаторы – Россия авиакомпанияләре тарафыннан Ту-214 белән кызыксынуның артуы. «Туполев» компаниясенең идарәче директоры Вадим Королёв төгәл саннарны да атады: 2032 елга кадәр 150 данә – Ту-214 самолётларына ихтыяҗ шундый.

– 20 самолётка ышанычлы контрактлар бар, – дип ачыклык кертте ул киңәшмә барышында. – 67 се буенча ниятләр турында килешүләр имзаланды, тагын 61 енә потенциаль заказчылардан гариза бар.

Авиакомпанияләрнең кызыксынуы аңлашыла: Казанның Ту-214 самолёты – бүгенге көндә тулысынча диярлек үзебезнең детальләрдән җыелган бердәнбер Россия очкычы. Оча торган. Сертификаты булган. Ышанычлы. Еллар дәвамында сыналган. Дөрес, перспективалы һәм өметле МС-21, «Сухой Суперджет» бар, ләкин, ихтимал, безнең авиациянең киләчәгедер. Әмма бу импортны алмаштыру һәм сериялап җитештерүгә чыгу өчен вакыт таләп итә, ә самолётлар бүген һәм якын елларда кирәк. Президент күрсәтмәсе нигезендә Хөкүмәт тарафыннан расланган Авиатранспорт тармагын үстерү буенча комплекслы программага ярашлы рәвештә, 2030 елга кадәр меңнән артык граждан һава судносы җитештерелергә тиеш.

– Һәм, әлбәттә, монда Казан авиазаводы өчен аерым роль каралган, – диде Михаил Мишустин, киңәшмәне ачып. – Бер ел ярым эчендә, ягъни 2025 елга ул ел саен ун Ту-214 чыгаруга ирешергә тиеш. Бу модельнең төп өстенлеге шунда: ул тулысынча үзебезнең детальләрдән, шул исәптән Россиядә җитештерелгән ПС-90А двигателеннән тора. Шуңа күрә, әлбәттә, мондый лайнерларны төзүне арттыру бик мөһим.

Түбәндәге бурыч шуннан килеп чыга да: проектны, аны алга таба үстерү һәм моның өчен кирәкле өстәмә финансларны табу юлларын билгеләргә кирәк.

## ЕЛЫНА УН ОЧКЫЧ. ӘЛЛӘ ЕГЕРМЕМЕ?

Елына 10 самолёт җитештерү – үзе үк завод һәм тармак өчен җиңел бурыч түгел. Элек Казанда иң яхшы дигәндә дә бер-ике очкыч җыелуын исәпкә алганда бигрәк тә. Ләкин бит элек граждан авиациясенә мөнәсәбәт тә башка иде – һава транспортында «Боинг»лар һәм «Аэрбас»лар хакимлек итте. Бүген исә барысы да үзгәрде.

– Хөкүмәт тармакка максималь ярдәм күрсәтә, – дип ассызыклады Михаил Мишустин. – Аерым алганда, махсус дәүләт программасы гамәлгә ашырыла, анда билгеләнгән чараларга быел 40,5 млрд сум акча каралган. Һәм якынча шулкадәр үк күләмдә киләсе елга да. Бу – җитештерүләрне һәм инженерлык үзәкләрен модернизацияләү, перспективалы двигательләр төзү һәм башка мөһим проектлар өчен исәпләнгән акчалар. Авиатөзелешнең фәнни-тикшеренү һәм конструкторлык эшләре кебек өстенлекле юнәлешләренә субсидияләр бирәбез. Аерым алганда, без күптән түгел Денис Валентинович (Мантуров) белән бу турыда фикер алыштык, өч еллык бюджетка әлеге максатларга 90 млрд сумнан артык акча салдык. Быелга шуларның 37 миллиард сумы тәгаенләнгән.

Мондый ярдәм фонында Казан авиация заводының киләчәктә Ту-214 очкычын елына 20 данәгә кадәр арттырырга әзерлеге (шөкер, потенциаль заказчылар да җитәрлек) булмастай эш кебек тоелмый. Алга таба киңәшмәдәге фикерләр күрсәткәнчә, әлеге әзерлек конкрет

саннар һәм җентекле эш программасы белән нығытылган. Аларны киңәшмәдә Вадим Королёв яңгыратты.

## БУРЫЧ – 83,6 МИЛЛИАРДЛЫК

Шулай итеп, махсус очыш авиаотряды тарафыннан эксплуатацияләнү елларында үз мөмкинлекләрен исбатлаган Ту-214, әйтик, 2030 елга кадәр РФ Авиатранспорт тармагын үстерү буенча комплекслы программада билгеләнгәнчә, 70 данәдә түгел, ә, ихтыяҗны исәпкә алып, тагын да күбрәк җитештерелсен өчен нәрсә эшләргә кирәк? Әлбәттә, җитештерүне киңәйтергә һәм модернизацияләргә, цифрлы технологияләргә күчәргә, сатудан соң сервисның заманча системасын оештырырга. Шул ук вакытта, башкарма директор аңлатуынча, «Туполев» ГАҖ, Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе һәм «Ростех»ка кергән башка корпорацияләр белән берлектә, 2027 елга 20 машина җыюга ирешү өчен кирәкле чаралар комплексын эшләгән. Алай гына да түгел, чараларның бер өлеше комплекслы үсеш программасына кертелгән, финанслар белән нығытылган һәм гамәлгә ашырыла.

Хәзер исә төп мәсьәлә – елына 20 самолёт чыгару мөмкинлегенә ирешү өчен алга таба планлаштырылганнарга финанслар табу. «Туполев» ГАҖдә моның өчен 83,6 млрд сум акча кирәк дип исәпләгәннәр. Әлеге суммадан нинди максатлар өчен күпме акча сарыф итү билгеләнгәнен санап тормыйбыз. Менә кайбер ориентирлар гына: 100 мең кв. метрдан артык җитештерү мәйданын төзү һәм реконструкциягә, шул исәптән агрегат һәм соңгы җыю линияләренә 22,7 млрд сум кирәк булачак, ә 10 млрд сум самолётны сатканнан соң хезмәт күрсәтү системасын оештыруга, шул исәптән очучылар составын әзерләү өчен тренажерлар булдыруга китәчәк. Тагын 23,5 млрд сумга якын Ту-214 самолётларын җитештерүдә катнашкан кооперация предприятиеләренең җитештерү куәтләрен киңәйтү өчен таләп ителәчәк.

**Михаил Мишустин, РФ Премьер-министры:**
– Без хәзер самолётлар гына төзеп калмыйбыз. Бүген тормыш циклын төзергә кирәк: аны чыгару, хезмәт күрсәтү, эксплуатацияләү, модернизацияләү. Һәм, әлбәттә, мондый проектларны шунда ук комплекслы планлаштырырга кирәк. Һәм тәэмин итү чылбырында катнашучылар бергәләп эшләргә тиеш. Бу җитештерүчеләргә һәм эшләүчеләргә дә, дәүләт органнарына да кагыла. Машиналарны базарга ничек чыгарырга һәм аларны куллануның башлангыч этабын алдан планлаштырырга, сатудан соң сыйфатлы хезмәт күрсәтүне оештырырга кирәк. Бу бик мөһим мәсьәлә.

## АВИАЗАВОД КУӘТЛӘРЕ 3,6 МӘРТӘБӘГӘ АРТАЧАК

Нәтиҗәдә без нәрсә алачакбыз? 2025 елга, елына 10 самолёт чыгару җайга салынгач, Казан заводының куәте 2,4 тапкырга артачак. Ә 2027 елга, 20 Ту-214 не чыгару мөмкин булгач, Казанда үз мөмкинлекләре буенча хәзерге заводны 3,6 тапкырга узып киткән предприятие эшләячәк! Әлбәттә, бу башка технологик дәрәҗә дә, җитештерүне оештыру да булачак. Җитештерү куәтләрен арттыру өстәмә рәвештә ике меңнән артык төп җитештерү эшчеләрен таләп итәчәк. Чагыштыру өчен: 2010 елда Казан авиация заводының барлык хезмәткәрләренең гомуми саны (ачык чыганаклардан алынган мәгълүматлар буенча) алты мең кешегә якын.

Бүгенге шартларда завод сафларын лаеклы кадрлар белән тулыландыру никадәр реаль соң? Предприятиедә кадрлар мәсьәләсен җиңел димиләр, әмма башкарыла торган гамәлләр әлеге проблеманы хәл итәргә ярдәм итәр, дип ышаналар. Квалификацияле хезмәткәрләрне җәлеп итү буенча киңәйтелгән реклама кампаниясе җитди аргументлар белән нығытылган. Аерым алганда, «Салават Күпере» торак комплексында алар өчен 50 процент ташлама белән арендалы торак бүлеп биреләчәк.

Профильле югары уку йортларында, республиканың махсус уку йортларында, Дементьев исемендәге Казан авиация-техника көллиятендә кадрлар әзерләү аерым өстен-

леккә ия. Хәзерге вакытта профильле махсус уку йортларының 400 гә якын студенты предприятиедә производство практикасын үтә. «Туполев» ГАҖ, Казан авиация институты белән берлектә, «Крылья Ростеха» бөтенроссия проектын гамәлгә ашыруда катнаша, аның асылы – самолёт төзелеше белгечлеге буенча яңа форматтагы инженерларны әзерләү. Ә май аенда завод базасында кадрларны гамәли-юнәлешле әзерләү өчен югары уку йортының профильле кафедрасы ачылды. Авиатөзүчеләр шулай ук Россия Мәгариф һәм фән министрлыгы Казан милли тикшеренү техник университетын «Приоритет-2023» программасына кертер, дип өметләнә. Әлеге программада катнашучы вузлар базасында алдынгы инженерлык мәктәпләре ачылачак.

## ПЛАННАР ЗУРДАН. БУЛДЫРЫРБЫЗМЫ?

Шунысы игътибарга лаек: «Туполев» ГАҖ, куәтләрне арттыру буенча грандиоз план әзерләп һәм кирәкле акча күләмен санап, кул кушырып кына утырмый. Киңәшмәдә Вадим Королёв хәбәр иткәнчә, «барлык юнәлешләр турында техник бирем проектлары әзерләнгән, техник-коммерция тәкъдимнәре соралган һәм өлешчә алынган», алай гына да түгел, проблемалы юнәлешләр буенча потенциаль тәэминатчылар белән җиһазлар китерүгә алдан килешүләр әзерләнгән һәм килештерелгән. Барлык төр производстволарны заманча җиһазлар белән технологик җиһазландыру самолёт җитештерүнең барлык процессларын цифрлаштыруны таләп итә, шуңа күрә билгеләнгән срокларга сыешу өчен, алдан ук «Берләштерелгән авиатөзелеш корпорациясе предприятиеләренең, Мәскәү һәм Казан авиация вузларының, башка тышкы контрагентларның конструкторлык-технологик хезмәтләреннән торган киң кооперация формалаша».

– Кайчандыр без хәрби машинаны цифрлаштырганда шундый эш белән шөгыльләнгән идек инде. Ул чакта КБ оештырылды, Россиянең конструктор яшәгән теләсә кайсы ноктасыннан нормаль ябык каналлар буенча эшләү мөмкинлеге тәэмин ителгән бердәм сервер булдырылды, – дип аңлатты Вадим Королёв.

2027 елдан башлап елына 20 Ту-214 самолётын җитештерүне тәэмин итү өчен тәкъдим ителгән эш стратегиясе реаль һәм бөтен нечкәлекләренә кадәр уйланылган. Киңәшмә барышы шуны раслады: мондый фикер аны тәкъдим итүчеләрдә генә түгел. Һәрхәлдә, тәкъдим ителгән планны раслау һәм Россия Федерациясенең Авиатранспорт тармагын үстерү буенча комплекслы программа нигезендә Ту-214 самолётларын җитештерү һәм финанслау күләмен билгеләүче документларга тиешле үзгәрешләр кертү үтенечен җитди каршылык һәм бәхәсләр тудырмады.

– Вадим Владимирович, биредә яңгыраган акча мәсьәләсен хәл итсәк, сез планның үтәлешен гарантиялисезме? – дип кызыксынды Королёвтан Премьер-министр. Һәм көтелгән җавапны алгач, йомгак ясады:

– Килештек!

Килешү, тиздән ачыкланганча, мөһим карар белән ныгытылды.

**Рөстәм Миңнеханов, Татарстан Рәисе, «Туполев» ГАҖ Директорлар советы рәисе:**

– Зур эш башкарылды. Принципта барлык объектлар да вакытында әзер булачак, һәм оборона-сәнәгать комплексы алдында торган бурычларны хәл итү контрольгә куела. Һәм иң мөһиме – без зур корпусны куллануга тапшырабыз, анда инде бу самолётларны җитештерүне җәелдерә алабыз. Финанс мәсьәләләрен хәл итәчәкбез. Кайда һәм нинди җиһазлар сатып алына, нинди бүлмәләр, биналар кирәклеге җентекләп каралган. Шуңа күрә без, Михаил Владимирович, бу бурычны 2027 елга кадәр гамәлгә ашырачакбыз. Бәлки, срокларны тагын бераз кыскартырбыз да.

– Ту-214 очкычларын күпләп җитештерү проекты бик мөһим. 2025 елдан башлап безгә елына 10 лайнер җыярга туры киләчәк, әмма мондый техникага ихтыяҗ хәзер күпкә югарырак. Бүген күргәннәребез һәм фикер алышуларыбызга нигезләнеп, Казан заводы зур күләмнәр белән эшли алыр, дип өметләнәм. Бу юнәлештә бергәләп тырышачакбыз, – дип йомгаклады Премьер иң мөһиме турында хәбәр итәр алдыннан. – Президент белән килешү буенча сезгә кичә кабул ителгән карарны җиткерәсем килә: бу проектка Милли иминлек фондыннан 41,8 млрд сум бүлеп бирелә. Бу карар, хөрмәтле коллегалар, бүген үк сез сөйләгәннәрне иң зур темпларда тормышка ашырырга мөмкинлек бирәчәк. Ягъни бу – җитештерүне технологик җиһазландыруга 27,4 млрд сумга кадәр, склад биналарын төзү һәм реконструкцияләүгә – 22 млрд сум, сатудан соңгы (Слюсарь әфәнде, сез әйттегез) хезмәт күрсәтү, шул исәптән тренажерлар сатып алуга, предприятиенең җитештерү куәтләренә – 10 млрд сум. Алга таба кирәкле акчалар – якынча 83 млрд сум, һәм тагын 42 млрд сум тирәсе – болары «Ростех» дәүләт корпорациясенең облигацияле займнары булырга мөмкин, аларны проектны финанслау өчен елына якынча 1,5% купон кереме белән 15 елга кадәр чыгарырга мөмкин. Хәзерге вакытта, минемчә, без бу мәсьәләне хәл иттек.

Ту-214 массакүләм җитештерүне көтә – бу инде бүген тәгаен билгеле. Димәк, аны җитештерү чыгымнарын киметү, эксплуатация процессында модернизацияләү һәм камилләштерү, тагын да яхшырак, экономиялерәк, көндәшлеккә сәләтлерәк итү мөмкинлеге пәйда була. Илебез авиасәнәгатен яңадан торгызу курсы дәвам итә.

# «АЛАБУГА»: КӨЧ АЛУ УРЫНЫ

Әхмәт Шакиров

Илебездәге махсус икътисадый зоналарның эшчәнлеге турындагы еллык хисабында* РФ Икътисадый үсеш министрлыгы шуны хәбәр итә: «Алабуга» МИЗ эшчәнлегенең нәтиҗәлелеге – 100 процент, ул Россиядә беренче урында.

Әлеге сан гаҗәпләндерми, чөнки ел саен Россия МИЗларының инвестицияләрне җәлеп итү сәләтен күрсәткән милли рейтингларда «Алабуга» төп күрсәткечләр буенча лидерлар рәтендә, резидентларның эшкуарлык эшчәнлеге һәм инвестицион активлыгы өчен уңай шартлар булдыруда да аңа тиңнәр юк. Чит ил бәяләмәләре үзебезнекеннән аерылып тормый: 2015-2020 елларда Financial Times версиясе буенча «Алабуга» «Трансчик хезмәттәшлеге», «Академик хезмәттәшлек» һәм «Күнекмәләрне үстерү» номинацияләрендә Европадагы иң яхшы МИЗ дип танылды.

Бүген «Алабуга» махсус икътисадый зонасы – 162 миллиард сумнан артык шәхси инвестицияләр ул. Бу – араларында Rockwool, Armstrong, 3M, Kastamonu, Hayat, Air Liquide, Şişecam кебек компанияләр булган илле җиде резидент. Шулай ук үз тармакларында лидер саналган компанияләрнең утыздан артык җитештерүе һәм 10 500 эш урыны дигән сүз. Һәм болар барысы да Татарстанда.

## РЕЗИДЕНТНЫҢ НЫКЛЫ АДЫМЫ

«Күргәннәр сокландыра! Мин үзем Татарстаннан, махсус икътисадый зонаның барлыгын белә идем, әмма мондый ук киң колачлы дип уйламадым да... Нәкъ менә безнең республикада шундый урын булуына бик шатмын. Экскурсиядән соң уртак проектлар эшләп була дигән өмет туды. Әлегә без «Кастамону»да гына булдык, һәм безнең компания пиццерияләр төзи. Без моннан үзебезгә продукция китертү белән кызыксындык. Башка резидентлар, шулай ук «Алабуга»ның үзе белән хезмәттәшлек итү мөмкинлеген дә өйрәнергә вакыт җитте, дип уйлыйм», – диде Россиядә «Додо пицца» корпоратив челтәре җитәкчесе Олег Кольцов, МИЗ белән танышканнан соң. Бизнесменның тәэсирләре яңалык түгел, дип әйтергә була. Чөнки монда беренче тапкыр килүчеләрнең барысы да диярлек күргәннәргә шаккатуларын әйтә. Күпләр тәэсирләнеп кенә калмый, резидент булып теркәлә дә. Вакыт аларның дөрес эшләвен раслый.

Фото: alabuga.ru

* 2021 ел йомгаклары буенча

Мәкалә башында искә алынган рейтинглар – шикләнүчеләр өчен җитди дәлил. Ләкин тагын да саллыраклары бар. Бирегә төрле илләрдән килгән инвесторлар «Алабуга»ның потенциалын үз тәҗрибәләрендә күрде. Нәтиҗәләр күбесенчә бик конкрет: аларның ниятләре, фаразлары кебек үк, йөз процентка акланган. Дөрес, кайвакыт чынбарлык хәтта иң кыю фаразларга да төзәтмәләр кертергә мәҗбүр итә. Мәсәлән, Төркиянең Kastamonu компаниясе, төзелешкә 300 миллион доллар кертеп, Алабугада үз заводын эшләтеп җибәргәндә, ике ел узгач, Россиянең идән япмалары базарында лидер булачагын фаразламагандыр да. Үз вакытында Алабуга предприятиесен ачу тантанасында «Кастамону Энтегре» вице-президенты Онур Гювен әйткәнчә, бизнес өчен «дөньяның бер генә илендә дә Татарстандагы кебек мөмкинлекләр тудырылмады, ярдәм күрсәтелмәде». Сигез ел элек алар, «Алабуга» МИЗ резиденты буларак, базарның әлеге сегментын актив яулый башлады, шуңа күрә компаниянең алга таба үсеп китүенә гаҗәпләнәсе юк. Бүгенге көндә Алабугадагы заводның куәте – елына 1, 05 млн $м^3$ МДФ плитәсе һәм 35 млн кв. метр ламинат. Идән япмалары Европаның, Азия һәм Латин Америкасының 27 иленә озатыла, ә компаниянең төбәккә керткән инвестициясе күләме 771,8 млн доллардан артып китте.

Россиянең алдынгы икътисадый зонасы территориясендә уңышка ирешкән бизнеска мисаллар ике-өч кенә түгел – дистәләгән. HAYAT KIMYA заводы, МИЗда күтәрелеп, биш ел эчендә Россиядә кәгазь-гигиена продукциясе базарында лидерга әйләнде, Даниянең Rockwool компаниясе Татарстанда базальт мамык җитештерү буенча иң зур заводын салды, Төркиянең Trakya компаниясенең үтә нык көзге пыялалары «Мәскәү-Сити»ны салганда кулланылды... Узган елда гына да «Алабуга» МИЗ резидентларының кереме 140 миллиард сумга якынны тәшкил итте.

## КЫЮ НИЯТЛӘР ӨЧЕН ҖЫЛЫ УРЫН

«Алабуга» МИЗны кайвакыт дәүләт эчендәге дәүләт дип атыйлар. 4000 гектар мәйданда махсус салым режимы эшли, монда таможня (МИЗ резидентлары өчен генә) дә үзләренеке, анда махсус преференцияләр каралган. Резидент статусын алган компания 10 елга җир, милек һәм транспортка салым түләүдән азат ителә. Табыш салымы? Беренче биш ел өчен нибары – ике процент (20 процент урынына), аннары киләсе биш ел өчен – җиде процент, аннан соң – 15,5 процент.

Чит ил җиһазларына пошлиналар? «Алабуга» территориясендә гамәлдә булган ирекле таможня зонасы режимы, МИЗ резидентлары ирекле таможня зонасы процедурасын кулланган очракта, әлеге җиһазлар МИЗ территориясендә вакытта, эшчәнлек алып бару турында килешү срогы тәмамланганчыга кадәр чит ил җиһазларына кертелгән таможня пошлиналарыннан һәм/яки салымнардан азат итүне күз уңында тота.

Салым һәм таможня преференцияләре – теләсә нинди бизнесның хыялы. Ләкин салым оҗмахы, әгәр ул цивилизациядән, коммуникацияләрдән, хезмәт ресурслары һәм сату базарларыннан ерак урнашкан булса, теләсә нинди даһи бизнес-ниятне дә тәмугка әйләндерә ала. «Алабуга» очрагында бу потенциаль резидентларга берничек тә яный алмый. МИЗ җитәкчелеге баштан ук: «Без, дөньяда иң яхшы инфраструктура булдырып, сәнәгатьне кешеләрнең имин тормышы хакына үстерәбез», – дип үзенең кыю миссиясен билгеләгән иде. Амбицияләр чынбарлык белән ныгытылды: «Алабуга» инфраструктурасы бүген үк дөньяда иң яхшыларның берсе санала.

## ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЕНӘ ТҮГЕЛ – ХЫЯЛ

МИЗ инфраструктурасын булдыруга 25 миллиард сум акча тотылган. Бу – өч дистә километр озынлыктагы идеаль асфальт юл, йөзләгән чакрым заманча инженерлык челтәре, беренче ышанычлылык категориясен тәэмин итә торган, куәте 350 МВт ка исәпләнгән үз электр челтәре инфраструктурасы. Шулай ук үз су каналы, шәп чистарту корылмалары, үз газ һәм җылылык бирү инфраструктурасы... Барлык бу байлык МИЗ резидентларына хезмәт итә. Бәяләр? Энергия ресурслары белән тәэмин итү челтәрләренә тоташтыру – 0 сум. Чагыштыру өчен, Мәскәүдә моңа – 29 миллион сум, төбәктә алты миллионнан артык акча тотарга туры килер иде.

Мондый өстенлекләр хисабына резидентларның күпме экономияләвен сөйләү кабул ителмәгән. Әмма җылылык изоляцияләү материаллары җитештерүче Rockwool бервакыт таможня ташламаларында экономия генә дә 12,6 млн сумны тәшкил итте дип сөйләгән, диләр. Шул ук вакытта әле вакытны экономияләү исәпкә алынмаган, ә бит ул да бик мөһим. Мисал өчен, үзләренең таможняларында барлык рәсмиләштерү эшләре гадәттә өч сәгатьтән дә артык вакыт алмый.

«Алабуга» гади сәнәгать-җитештерү мәйданчыгы гына түгел, бүген ул эшлекле, таможня һәм социаль өлкәләре булган тулы циклга ия алдынгы инфраструктур партнёр да, ди экспертлар. Бу нәрсә бирә соң? Әйдәгез, җентекләбрәк тикшерик. Беренчедән, автомобиль, елга һәм тимер юллар тоташкан урында урнашкан «Алабуга» алдан ук партнёрларны логистик проблемалардан азат итә. Идеаль керү урыны һәм юллардан тыш, монда йөкләрне китерү һәм эшкәртүнең уйланылган системасы эшли. Йөкләрне тулысынча эшкәртү хезмәте, 60 мең кв. метрлы контейнер мәйданчыгы, Куйбышев тимер юлына турыдан-туры чыга торган әчке тимер юл резидентларга вакыт һәм акчаны экономияләргә булыша. Моңа тагын МИЗның алдан ук каралган башка өстенлекләрен кушыгыз: резидентларның югары технологияле предприятиеләрендә җитештерелгән товарны сатып алучылар, кагыйдә буларак, «Алабуга»дан 1000 километр радиуста урнашкан.

Икенчедән, булачак резидентка монда үз җитештерүен төзү мәҗбүри түгел, мәсәлән, «А Плюс Парк» индустриаль паркында әзер җитештерү мәйданчыгын арендага алырга мөмкин. Әгәр проект тагын да кечкенәрәк икән, «Синергия» паркында офис-цех блогын арендалау да җитә. Клиентларга чыгымнарны җитди кыскартырга ярдәм итүче мондый тәкъдимнәргә МИЗда ихтыяҗ зур. 2020 елның апрелендә файдалануга тапшырылган 76 мең квадрат метрдан артык мәйданга ия уникаль «Синергия-2» индустриаль паркында (4.0 индустрия стандартларына җавап бирә) өч айдан соң буш мәйданнар калмады, барысы да резидентлар тарафыннан резервланды.

## ЯШӘ, ӨЙРӘН, ЭШЛӘ

Шунысы исәпләнгән: «Алабуга»дагы преференцияләр инвесторларга үз проектларын гамәлгә ашыру чыгымнарын 30 процентка кыскартырга мөмкинлек бирә. Россия резидентларының берсе, «Ак Дача» агрохолдингы, үз комплексыбызны башка урында төзегән булсак, 1 млн долларга күбрәк акча сарыф итәргә туры килер иде, дип раслый. Техник газлар җитештерүче Air Liquide француз компаниясе чыгымнарда бер ярым тапкырга күбрәк экономияләүләре турында сөйли.

Социаль, финанс һәм HR-структураларны яхшыртмыйча гына, югары нәтиҗәлелеккә ия, технологияле җитештерүләрне үстерү буенча дөньяда иң яхшы инфраструктураны төзүне күз алдына да китереп булмый. Билгеләнгән стратегия юнәлешендә «Алабуга» МИЗның алдагы биш ел эчендә 200 млрд сум күләмендә яңа шәхси проектларны финансларга әзерлеге мантыйкка бик тә туры килә. Предприятиеләрнең топ-менеджментына барлык уңайлы яшәү шартлары тудырылган «Өч аю» ябык коттедж поселогы һәм чит телләр буенча башка ил укытучылары эшләгән Alabuga international school халыкара мәктәбе – сәнәгать мәйданчыклары яки преференцияләр системасы кебек үк, махсус икътисадый зонаның органик бер өлеше.

«Алабуга»ны тулы циклны инфраструктура иткән тагын бер мөһим сфера бар. Сүз МИЗдагы югары технологияле производстволар өчен кадрлар әзерләү турында бара. Эшче кадрлар әзерләү буенча иң зур белем үзәкләренең берсе – «Алабуга-Политех» елына 10 мең белгеч укытып чыгара. Бу күп яктан киләчәк белем бирү системасының прообразы, ул идея һәм проектларда түгел, ә хәзер һәм биредә эшли.

– Мин күптән түгел интернетта «Алабуга» теләсә кайсы һөнәр иясен үзенә чакыра дигән реклама күрдем. Шул исәптән хәтта махсус белеме булмаган яшьләргә дә төрле эшче һөнәрләре тәкъдим итәләр. Аларны производствода укытырга әзерләр, – дип гаҗәпләнде РФ Премьер-министры Михаил Мишустин Татарстан Рәисе белән соңгы очрашуы вакытында. – Шунысы кызык, Рөстәм Нургалиевич, моның өчен һөнәр буенча нindidер компетенцияләр таләп ителми. Иң мөһиме эшләргә зур теләк булсын! Эшкә алган предриятие уку мөмкинлеген дә бирә.

«Алабуга-Политех» студентлары, дөнья дәрәҗәсендәге компанияләрнең алдынгы предприятиеләрендә эшләү, югары дәрәҗәдәге профессионаллар җитәкчелегендә иң шәп җиһазларны өйрәнү буенча уникаль мөмкинлеккә ия булып, сигез әзерлек юнәлешенә караган за-

манча белгечлекләр ала. Шул ук вакытта аларга югары стипендия, торак һәм эшкә урнашу гарантияләнә.

Хәер, соңгысы аның кадәр мәҗбүри түгел. «Алабуга-Политех» инженерлык көллияте студентлары, кагыйдә буларак, үз курсларын тәмамлаганчы ук, МИЗ предприятиеләре белгечләренә әйләнә – укыту системасы шулай җайлы корылган. Аны тәмамлаганда, һәр чыгарылыш укучысы, soft һәм hard skills күнекмәләренә ия әзер профессионал, халыкара җиһазлар җитештерүчеләр тарафыннан сертификатланган, белгечлеге буенча ике еллык эш тәҗрибәсенә ия була.

## УРЫННАР БУШ. WELCOME!

Бүген Россиядә 50 махсус икътисадый зона эшли. Илнең барлык МИЗлары табышының яртысы «Алабуга» өлешенә туры килә, ә сәнәгатьҗитештерү тибындагы МИЗлар арасында аның табышы 70 процентка якынны тәшкил итә. Континентларда вазгыять үзгәрүчән, әмма төп максат шул ук кала: «Алабуга» бизнес ихтыяҗларын канәгатьләндерү, икътисадны үстерү һәм иминлекне арттыру өчен дөнья дәрәҗәсендәге инфраструктураны актив рәвештә оештыруны дәвам итә.

Бу бирэдә 2021 елның маенда AURUS автомобильләрен серияле җитештерү башланды – «Алабуга» инвесторга «Синергия»дәге әзер индустриаль мәйданны тәкъдим итте. Монда ук 2022 елның ноябрендә Россиядә люкс классындагы беренче AURUS Komendant внедорожнигын җыю башланды, аның детальләре нигездә үзебездә чыгарыла. Проект, РФ Президенты Владимир Путин фикеренчә, Татарстанның үсеше өчен тагын бер җитди этәргеч булып тора.

Махсус икътисадый зонада гамәлгә ашырыла башлаган яңа масштаблы проектлар арасында куәте буенча Россиядә иң эре логистика үзәге дә бар. Дэн Сяопин исемендәге әлеге үзәк елына 100 мең контейнерны кабул итәргә тиеш, ул 65 гектарда урнашачак һәм, өстәмә күчереп йөртү эшләреннән башка, бөтен контейнер поездында йөк төяү һәм бушату операцияләрен башкарырга мөмкинлек бирәчәк. Беренче этапта гына да проектка 20 миллиард сум күләмендәге инвестиция кертелә. Терминал, үз чиратында, тагын бер суперпроект – «Этилен-600» индустриаль паркының бер өлеше булачак. Аңа кертелгән инвестиция күләме 1,3 трлн сумны тәшкил итәчәк, шуларның 140 млрд сумы – МИЗ кертемнәре. Индустриаль паркны булдыру турында килешүгә «Алабуга» һәм «СИБУР» ГАҖ 2022 елның августында кул куйды. «Этилен-600» Россиядә кече һәм урта тоннажлы химия җитештерүчеләргә нефть һәм газ химиясе чималын алу өчен уникаль мөмкинлекләр бирүче бердәнбер мәйданчык булачак.

«Алабуга» МИЗ генераль директоры Тимур Шаһивәлиев микроэлектрониканы киләчәктә перспективалы юнәлеш дип саный, әлеге мөһим өлкәдә Россиядә буш урыннар шактый булуын әйтә.

Сүз уңаеннан, бу юнәлештә беренче адымнар инде ясалган.

Россиядә импортны алмаштыруга бәйле бурычлар шактый, берсе икенчесеннән җитдирәк. Бу бизнес өчен уникаль мөмкинлек тә. «Сизәсездер, без бөтен фронтларда дөнья дәрәҗәсендәге корпорацияләр белән ярышабыз. Россиядә урыннар бушады, без дөнья дәрәҗәсендә түли алабыз. Чөнки безнең алда торган бурычлар да дөньякүләм дәрәҗәдә... Өйгә, «Алабуга»га кайтырга вакыт». Мондый текстлы плакат күптән түгел Нью-Йорктагы биналарның берсендә пәйда булды. Ул чит ил компанияләрендә эшләүче россиялеләргә юллана. Хәер, аларга гына түгел.

Россиядә урыннар бушады.

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНДА

**2022 ел**

**888,6 млрд сум**

ТӨП КАПИТАЛГА ИНВЕСТИЦИЯЛӘР

БУ **2021** ЕЛ ДӘРӘҖӘСЕНӘ КАРАТА **110,5%**

**25,1%**
эшкәртү җитештерүләрен үстерүгә инвестицияләр

**24,2%**
транспорт һәм саклау сферасына

**12,1%**
файдалы казылмалар табуга

**8,3%**
күчемсез милек белән операцияләр эшчәнлегенә

**4,7%**
авыл хуҗалыгы, урман хуҗалыгы, аучылык, балык тоту һәм балык үрчетү тармакларына



# ИНВЕСТИЦИЯЛЕ КЛИМАТ

**2нче урын – Татарстан**

РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ СУБЪЕКТЛАРЫНДА ИНВЕСТИЦИЯЛЕ КЛИМАТ ТОРЫШЫНЫҢ МИЛЛИ РЕЙТИНГЫНДА (2022 ЕЛ)

РЕСПУБЛИКАДА

**«Татарстан инвестицияләренә контроль»**

МӘГЪЛҮМАТ СИСТЕМАСЫ ЭШЛИ. АНДА ИНВЕСТИЦИЯЛЕ ПРОЕКТЛАР ЭЛЕКТРОН ФОРМАДА ТЕРКӘЛӘ ҺӘМ АЛЫП БАРЫЛА.

**178 проект**

2022 елда Татарстан Республикасының өстенлекле инвестицияле проектлары исемлегенә кергән

**140 проект**

2023 елга өстенлекләләр исемлегенә кергән

**16 млрд сумга якын**

2006–2022 елларда республикада инвестицияле проектларны гамәлгә ашыра торган предприятиеләргә бирелгән салым ташламалары күләме

**761 млрд сум**

югарыда аталган проектларны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән инвестицияләр күләме

**18 меңнән артык**

яңа эш урыны ачылган

**27,2 млрд сум**

Татарстан Республикасы бюджетына күчерелгән салым акчалары



# КЫРГА ХӨРМӘТ КӨНЕ

Фото: tatarstan.ru

Җәй уртасы. Сабан туйлары гөрләп узды, кырда башак тулышып килә. Игенче өчен әзрәк сулу алу мөмкинлеге туды кебек... Юк, кыш көне генә ял итеп алырга була, дип каршы төшәр авыл кешесе. Җәй – игенче, терлекче өчен эшнең иң кызу вакыты. Июль башында Татарстанда уза торган Бөтенроссия кыр көне дә аграрийларга ярдәм буларак оештырыла. Хезмәттәшләр белән очрашу, иң яхшы тәҗрибәләрне өйрәнү, яңалыклар белән танышу һәм үрнәк алу мөмкинлеге – ә аннан соң яңадан эшкә тотынырга да була. Иртәдән кичкә кадәр. Җәйге көн, язгысы кебек үк, ел ашата.

# Марат Җәббаров: «СТРАТЕГИК МАКСАТ – МАКСИМАЛЬ ЦИФРЛАШТЫРЫЛГАН ИКЪТИСАДЫЙ ТОТРЫКЛЫ ТАРМАК»

Әхмәт Шакиров

Органик бакчачылык һәм игенчелекнең киләчәге нинди? Ясалма интеллект терлекчеләргә ничек булыша? Шәхси ярдәмче хуҗалыкларга нинди субсидияләр каралган? «Илнең иң матур Сөтлебикәсе»н кайчан сайлаячаклар? «Татарстан» журналының бу һәм башка сорауларына ТР Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры җавап бирә.

## КӨТЕЛӘ ТОРГАН УҢЫШ ҺӘМ БАЗАР СЮРПРИЗЛАРЫ ТУРЫНДА

**– Июльдә инде беренче фаразларны ясарга мөмкиндер. Татарстан аграрийлары 2023 елда нинди уңыш алырга өметләнә?**

– Әйдәгез, барыбер хәзер үк фаразларга ашыкмыйк һәм конкрет саннар хакында сөйләшмик әле. Шунысын гына әйтә алам: явым-төшем кытлыгы аркасында үсемлекләргә үсү һәм өлгерү өчен шартлар быел бик уңайлы түгел. Әмма табигать безне ничек кенә сынамасын, алдыбызга ел саен куела

Фото: tatar-inform.ru, agro.tatarstan.ru

торган бурычны ничек тә үтәргә кирәк. Әлеге бурыч – үсемлекчелектә дә, терлекчелектә дә югары нәтиҗәләргә ирешү. Халыкны – үсемлекчелек продукциясе, ә терлекчелек тармагын сыйфатлы азык белән тулысынча тәэмин итү мөһим. Аграрийлар тарафыннан күрелгән чаралар, һава торышы сюрпризларына карамастан, бу бурычның һичшиксез үтәләчәгенә гарантия булып тора. Уҗым культуралары 472 мең гектар мәйданда чәчелде, туфракның һәр гектарына 82 килограммга якын минераль матдә кертелде (көзен уҗымнарга кертелгәнен дә исәпкә алып). Чүп үләннәренә каршы чаралар 2,1 миллион гектарда үткәрелде, корткычлар һәм чирләрдән 2 миллион гектар чәчүлек эшкәртелде. Аңлыйсыздыр инде, болар барысы да быелгы уңышның нинди булачагына конкрет ярдәм чаралары санала. Шулай ук моңа, мәсәлән, ашлама һәм саклагыч препаратлар комплексын үсемлекләрнең яфракларына сиптерү дә керә, әлеге ысул соңгы елларда Татарстанда актив кулланыла. Быел яфрак аша тукландыру 1,6 миллион гектар чәчүлектә үткәрелде, моның өчен 200 гә якын стационар эремә комплексы булдырылды. Әче туфракларның уңдырышлылыгын арттыру өчен исә известь кертелә, быел бу 80 мең гектарда башкарылачак. Планлаштырылган күләмнең чирегендә известь кертелгән инде.

**– Бай уңыш – һәрвакыт зур сөенеч ул. Әмма шул ук вакытта зур мәшәкать тә. Базар бәяләре бик түбән булган узган ел – моңа мисал. Базар катаклизмнарыннан дәва бармы ул? Алардан бәйсез булу өчен нишләргә?**

– Былтыр бөртекле культуралар уңышы тулаем ил буенча мул булды, шунлыктан аларны сатып алу бәясе арзанайды. Бу базар, һәм базар бәясен ясалма күтәрү мөмкин түгелдер ул. Әмма мондый очракларда авыл хуҗалыгы товарларын җитештерүчеләргә булышуның реаль чаралары бар, һәм алардан максималь файдалану мөһим. Аерым алганда, чынбарлыкта сатылган ашлыкка министрлыкта субсидияләр каралган. Быел аграрийлар алган мондый субсидияләрнең суммасы 720 миллион сум тәшкил итә.

Моннан тыш, республика предприятиеләре ашлыкны интервенция фондына сатты. Әлеге фондка ашлык уртача базар бәясеннән артыграк бәягә сатып алына. Мәсәлән, азык-төлек бодаен сатып алу бәясе 13500дән 14500 сумга кадәр (өстәмә кыйммәт салымыннан башка) тәшкил итә.

## СЫЙФАТ ҺӘМ ЯШЕЛ ТЕХНОЛОГИЯЛӘР ТУРЫНДА

**– Безнең ашлыкны саклау, эшкәртү куәтләре һаман арта барган уңыш күләменә һәм заман таләпләренә җавап бирерлекме?**

– Үзегез уйлап карагыз. Республикадагы барлык ашлык саклау предприятиеләренең проект куәте 2264,4 мең тонна тәшкил итә. Фактта да бераз гына калыша – 2206,9 мең тоннага тәңгәл. Татарстан кырларында җыелган уңыш өчен җитәрлек күләм бу. Әмма чын хуҗа бүгенге көн белән генә яшәми, киләчәкне күздә тотып та фикерли һәм гамәл кыла. Бәлки, ишеткәнсездер, июньдә Бөгелмә районында «Август-Агро» компаниясе яңа куәтле элеватор комплексы төзи башлады. Аның үткәрүчәнлек сәләте елына 450 мең тоннага кадәр тәшкил итәчәк, проект 2,9 миллиард сумга бәяләнә. Анда бер үк вакытта 112 мең тонна ашлык саклап булачак, аны Татарстан хуҗалыкларыннан да, күрше төбәкләрдән дә ташу ниятләнә. Аңлый торгансыздыр инде, заманча элеватор – ашлыкны кабул итү, чистарту, киптерү, саклауның заманча технологияләре ул, бу, табигый ки, чыгымнарны киметә һәм сыйфатны яхшырта.

**– Татарстанда бөртеклеләрдән мул уңыш җыю күнегелгән хәл инде. Ә продукциянең сыйфаты ничегрәк соң? Динамика күзәтеләме?**

– Җитештерелгән ашлыкның сыйфаты – һәрвакыт күп факторлар җыелмасы ул. Мәсәлән, табигый факторлар – вегетация чорында эффектив температуралар суммасы мөһим әһәмияткә ия. Күп нәрсә орлыкның сортына, сыйфатына бәйле. Ниһаять, чәчүлек һәм үсемлекләрне уңыш формалашу чорында тырышып кайгырту, бөтен кирәкле чараларны үз вакытында һәм җиренә җиткереп башкару да бик мөһим. Технологияләргә тирән кереп китәсем килми, шунысын гына әйтәм: алдарак искә алынган яфрак аша тукландыру нәтиҗәдә продукциянең сыйфатын яхшыртуга булыша. Мондый тукландыру һаман күбрәк файдаланыла. Уңай динамика да күз алдында: кырларыбызда бүген үстерелә торган иген сыйфаты һәм кулланылыш үзлекләре буенча моннан ун ел элеккедән күпкә яхшырак.

**– Татарстанда органик авыл хуҗалыгы уңышка өметләнә аламы?**

– Органик продукция җитештерүләре дә тиз үсә. Моңа иң яхшы дәлил – Татарстанда инде биш авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүченең беренче (югары) дәрәҗәле органик җитештерү тәңгәллеге яшел сертификатларына ия булуы. Бу – Мамадыш районының «Андрюшкино» АСХ ЖЧЖ (җиләк продукциясе), Лаеш районыннан ШЭ К(Ф)ХБ Исхакова Р. Ш. (бөртекле һәм терлек азыгы культуралары), Балтач районыннан ШЭ К(Ф)ХБ Гафиуллин Р.Н. (җиләк продукциясе), Баулы районыннан ШЭ Кыямов Ф.Ф. (терлек азыгы культуралары), Минзәлә районыннан ШЭ К(Ф) ХБ Маслаков Д.Г. (бөртекле культуралар). Моннан тыш, хәзерге вакытта конверсия процессында булган һәм сары сертификатка ия Мамадыш районының «Андрюшкино» АСХ ЖЧЖ (алмагачлар), Баулы районыннан ШЭ Кыямов Ф.Ф. (ябык грунт яшелчәләре), Тукай районыннан КФХ Хөснуллина Г.М. (алмагачлар), Арча районыннан ШЭ К (Ф) ХБ Аксаков Р.Р. (бөртекле һәм терлек азыгы культуралары), Чистай районы «Луч» ҖЧҖ (бөртекле, бөртекле-кузаклы һәм терлек азыгы культуралары) да бар. Әлеге хуҗалыклар инде быел ук үз амбицияләрен дәлилләр һәм шулай ук яшел сертификатка ия булыр, дип фаразлана. Исегезгә төшерәм, «Татарстан Республикасында органик продукция җитештерүне үстерү турында» закон ТРнда 2021 елның маенда кабул ителгән иде, аерым алганда, ул органик үсемлекчелек продукциясе җитештерүчеләренә субсидия бирү тәртибен дә билгеләде. Шул елны ук бюджеттан органик үсемлекчелек продукциясе җитештерүчеләренә ярдәмгә беренче 10 миллион сум акча бүленде һәм таратылды. Былтыр исә әлеге максатларга инде 18 миллион сум акча каралды. Яшел продукция җитештерүне үстерү перспективалары өметле, әмма, бөтен хыяллар тормышка ашсын өчен, әле күп тырышырга туры киләчәк. Безгә аны эшкәртүне көйләргә һәм тотрыклы сату базарлары формалаштырырга кирәк.

## САВЫМ, АРТЫМ ҺӘМ ЦИФРЛАШТЫРУ ТУРЫНДА

**– Без – Россиядә сөт җитештерү буенча лидер. Тармакның тагын да үсеше өчен резервлар бармы әле, әллә инде бу соңгы нәтиҗәме?**

– Һәр эштәге кебек үк, биредә дә камиллеккә чикләр юк. Әйе, Татарстан Россия сөтенең 6 проценттан артыграгын җитештерә һәм аның күләме буенча Россия Федерациясендә беренче урында тора. Әмма бу тынычлану өчен сәбәп була алмый. Үсештән туктыйсың икән, артта калачаксың. Узган елда республика үзенең тарихында беренче тапкыр 2 миллион тоннадан артыграк сөт җитештерде – хуҗалыкларның барлык категорияләрендә бергә 2 миллион 33 мең тонна тәшкил итте. Бурыч – алга таба да савым сыерларының сөт бирүчәнлеген арттыру.

**– Максатларга ирешү өчен нинди ресурслар файдаланылачак?**

– Республикада яңа терлекчелек фермалары һәм комплекслары төзелә, алдынгы технологияләр кертелә. Мәсәлән, үрчемне яхшырту өчен терлекләрне идентификацияләүнең бердәм системасы, көтү һәм аны ашату белән идарә итү программалары. Рацион компонентларын сыйфатлы кушу һәм болгату өчен терлек азыгы үзәкләре челтәре киңәйтелә. Шунысын әйтеп китү мөһим: мондый үзәкләр оештыру – өстенлекле юнәлешләрдән берсе ул. Инде 20 муниципаль районда 42 азык үзәге файдалануга тапшырылды, алар авыл хуҗалыгы оешмалары һәм шәхси ярдәмче хуҗалыклардагы 148 мең баштан артыграк мөгезле эре терлекне тәэмин итә.

Республикада 181 хуҗалык бүген цифрлы системалар белән эшли, аларда 174 мең баш сыер тупланган. Бу исә авыл хуҗалыгы оешмаларындагы барлык савым сыерларның 77 процентына тәңгәл. Әлеге хуҗалыклар барлык сөтнең 82 процентын җитештерә! Сөтчелек терлекчелегендә нәтиҗәлелекне арттыруга югары технологияләрнең ярдәмен күрсәткән менә дигән дәлил инде бу. Былтыр гына да әлеге хуҗалыкларда сөтне тулаем җитештерү 84 мең тоннага артты.

Әлеге чаралар комплексы авыл хуҗалыгы оешмаларындагы сыерларның продукция бирүчәнлеге буенча уртача еллык күрсәткечен 7125 килограммга җиткерү мөмкинлеген бирде. Бу аннан алдагы елга караганда 524 килограммга күбрәк.

**– Ә быел һәр сыердан күпме сөт саву ниятләнә?**

– Бурыч – еллык уртача продуктлылыкны – 7300 килограммга, ә хуҗалыкларның барлык категорияләрендә бергә сөт җитештерүне 2 миллион 64 мең тоннага җиткерү, шул исәптән 1 миллион 550 мең тоннасын – авыл хуҗалыгы оешмаларында һәм крестьян фермер хуҗалыкларында. Табигый ки, терлекчелек фермалары һәм комплексларын модернизацияләү, аларны югары технологияле җиһазларга күчерү дәвам итә. Яңа терлекчелек объектлары, терлек азыгы үзәкләре төзелә, алдынгы мәгълүмати технологияләр кертелә. Стратегик максат – максималь цифрлаштырылган икътисадый тотрыклы тармак булдыру.

**– Республика аграр тармакта цифрлаштыру кертү флагманнарыннан берсе санала. Аграрийлар авыл хуҗалыгының нәтиҗәлелеген арттыру өчен ясалма интеллекттан ничек файдалана?**

– Инде әйткәнемчә, цифрлы системалар белән терлекчелектә генә дә республиканың 181 хуҗалыгы эшли, аларда бөтен сөтнең 82 проценты җитештерелә! Безнең авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләрнең күбесе үз практикаларында Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы агросәнәгать комплексының дәүләт мәгълүмати системасын куллана. Ясалма интеллекттан файдалана торган әлеге системаның мөмкинлекләре бик зур. Мәсәлән, ул үсемлекчелектә авыл хуҗалыгына тәгаенләнгән җирләрнең тиешле максатта файдаланылмавын, сөрү сыйфатын, чабылган печән күләмен, кырда үстерелгән культуралар төркемнәрен ачыкларга булыша.

## БАШ САНЫ АРТУ ҺӘМ «СӨТЛЕБИКӘ ГҮЗӘЛКӘЙ» ТУРЫНДА

**– Сөт һәм ит җитештерү икенче ел рәттән арта, ә терлекләрнең баш саны кими. Киләчәктә дә шундый тенденция сакланачакмы?**

– Терлекчелектә продукция бирүчәнлекне арттыру чыннан да азрак санлы малдан да күбрәк сөт һәм ит алу мөмкинлеген бирә. Әмма стратегик планда малларның баш санын киметү күздә тотылмый. Киресенчә, аны саклау һәм хәтта арттыру өчен мөмкин булганның барысы да эшләнә. Былтыр республикада 18 мең баш савым сыерга исәпләнгән 24 сөтчелек комплексы файдалануга тапшырылды. Тагын 15,5 мең башка исәпләнгән 22 инвестпроект гамәлгә кертелә. Төзелгән комплексларны тутыру һәм көтүне яңарту өчен югары продуктив нәселле таналар сатып алу планлаштырыла. Заманча сөтчелек комплексларын төзү һәм файдалануга тапшыру – киләчәктә сыерларның баш санын ишәйтү һәм сөт җитештерүне ел саен 2–3 процентка арттыруның нигезе ул.

**– «Кыр көне» кысаларында илнең иң матур сыерын ачыклау бәйгесе узачак, дип сөйлиләр. «Иң матур Сөтлебикә» – шоумы яки шулай ук җитди эшлекле чарамы?**

– Болай дип әйтергә була: бу шоу да, эшлекле чара да, аның конкрет җитди бурычлары бар. Конкурста Россиянең голштин токымлы иң яхшы сыерын ачыкларга кирәк булачак. Чын матурлык конкурсындагы кебек, барысы да җитди булачак: судьялар, экспертлар һәм кырыс критерийлар. Сөтлебикәләрне дистәләп параметр буенча чагыштырачаклар – темпераментларыннан алып эстетик казанышларына кадәр. Гәүдә тирәнлеге, күкрәк киңлеге, арка линиясе, йөреш үзенчәлекләре – җиңүчене ачыклаганда барысы да исәпкә алыначак. Шоуның эшлекле асылына килгәндә исә, монда да барысы да төгәл: бөтенроссия бәйгесенең максаты – сөт юнәлешендәге нәселле хайваннарны популярлаштыру, селекция эшендәге алдынгы тәҗрибәне пропаган-

далау, илдәге генетик ресурслар базасын үстерү. Конкурста илнең 52 хуҗалыгыннан генетик потенциалы югары булган 80 нәселле тана сыер катнашачак. Бу алар өчен менә дигән реклама булачак: үз хуҗалыгыңны тармак профессионалларының киң даирәсенә тәкъдим итү, эшлекле элемтәләр урнаштыру һәм катнашучыларның сөтлелек куәтен дәлилләү мөмкинлеге туачак.

## ШӘХСИ ХУҖАЛЫКЛАРНЫҢ РОЛЕ ҺӘМ АЛАРГА ЯРДӘМ ТУРЫНДА

**– Тармак казанышларында шәхси ярдәмче хуҗалыкларның роле нидән гыйбарәт ?**

– Ул бик зур. Республикада җитештерелә торган бөтен авыл хуҗалыгы продукциясенең өчтән бере бит бу. Өстәвенә, узган ел нәтиҗәләре буенча шәхси ярдәмче хуҗалыкларда продукция җитештерү 3,9 процентка арткан. Шул ук вакытта Россиядә исә уртача 2 процентка кимү күзәтелә. Халык хуҗалыкларында продукция җитештерү күләме буенча Татарстан илдә икенче урында тора, Дагыстан Республикасыннан гына калыша. Шуны да онытмау мөһим: әлеге сектор азык-төлек куркынычсызлыгын тәэмин итүдә генә түгел, бәлки авылдагы яшәү рәвешен саклап калуда да әһәмиятле роль уйный. Татарстанда инде җиде елдан артык «ТР территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме турында» законның гамәлдә булуы бер дә очраклы түгел. ШЯХ чыгымнарының бер өлешен каплау өчен акча республика бюджетыннан бүленә.

**– Шәхси ярдәмче хуҗалыклар дәүләт ярдәменең нинди конкрет формаларыннан файдалана ала?**

– Алар аз түгел. Мәсәлән, сигез һәм аннан артыграк сыерга исәпләнгән сөтчелек юнәлешендәге мини-ферма төзегәндә хуҗалар – 600 мең сумга кадәр субсидиягә, биш һәм артыграк сыерга исәпләнгән мини-ферма төзегәндә исә 300 мең сумга кадәр субсидиягә өметләнә ала. Узган ел мондый субсидияләрне 169 ШЯХ алды – барлыгы 80 миллион сум бирелде. Быел исә әлеге максатка 100 миллион сум акча бүленгән.

Шулай ук нәселле башмак тана һәм беренче тапкыр бозаулаган сыерлар сатып алуга, өч яшьтән өлкәнрәк бияләр, бер яшьтән өлкәнрәк савым сыерлар һәм кәҗәләр асрауга, бәбкә-чебиләр сатып алуга да субсидияләр каралган. Шәхси хуҗалыкларга булышу нәтиҗәләре сөенечле. 2005 елдан бирле беренче тапкыр шәхси ярдәмче хуҗалыкларда сыерлар саны 511 башка арткан. Мондый хуҗалыкларга ярдәм киләчәктә дә дәвам иттереләчәк. Быел ул 536 миллион сум тәшкил итәчәк, бу былтыргыдан 110 миллион сумга күбрәк.

## ЭКСПОРТ, ХӘЛӘЛ ПЕРСПЕКТИВАЛАРЫ ҺӘМ ЧИКЛӘҮЛӘР ТУРЫНДА

**– Авыл хуҗалыгы тармагының экспорт потенциалы ни чама?**

– 2022 ел нәтиҗәләре буенча Татарстан агросәнәгать комплексы продукциясен экспортка чыгару күләме хәзерге бәяләр буенча 445,1 миллион АКШ доллары тәшкил иткән. Безнең аграрийлар җитештергән продукцияне тышкы икътисадый эшчәнлектә катнаша торган 160 оешма дөньяның 54 иленә экспортка чыгара. Экспортның төп өлеше май җитештерү тармагына туры килә, чит илләргә шулай ук ашлык, терлек азыгы һәм азык өстәмәләре, алкоголь продукциясе, май бирә торган культуралар җибәрелә. Былтыр ит һәм сөт продукциясен экспортка чыгару шактый – 147,1 процентка арткан. Соңгы сан безнең продукциянең тышкы базарда көндәшлеккә сәләтле булуына иң яхшы дәлил булып тора. Аграр тармакның экспорт мөмкинлекләре бик зур, аны максималь файдалану бурычы куела.

**– 2019 елда Татарстанда җитештерелгән хәләл продукцияне экспортка чыгару нибары 0,3 миллион долларга тәңгәл булган. Былтыр исә 6,5 миллион доллардан арткан. Моның сәбәбе нидә? Сезнең фараз: бу үсеш киләчәктә дә шундый темпларда сакланырмы?**

– Татарстан хәләл товарларының чит илләргә җитди экспансиясе хакында сөйләргә иртәрәк әле, әмма статистика тотрыклы үсешне күрсәтә. Былтыр хәләл

продукция экспорты күләме аннан алдагы елдан 1,5 миллион долларга артыграк булып чыккан, 2020 елда ул 2,5 миллион доллар тәшкил иткән, 2019 елда, чыннан да, нибары 0,3 миллион долларга тәңгәл булган. Без хәләл юнәлешен соңгы ике-өч елда актив үстерәбез. Быелгы бурыч – 8 миллион долларлык хәләл продукцияне экспортка чыгару. Кая таба барырга, нинди юнәлешләрне үстерергә кирәклеген, кайсы базарларның безнең өчен файдалырак булуын яхшы аңлыйбыз. Беренче чиратта БДБ, гарәп илләре белән хезмәттәшлекне көчәйтергә ниятлибез, анда хәләл туклану продуктларына ихтыяҗ гел югары һәм һаман арта бара. Дөрес сайланган ориентирлар нәтиҗә бирә, әмма бу тынычлану өчен сәбәп була алмый. Базар мөмкинлекләре тулысынча файдаланылмый әле. Россия – Гарәп эшлекле советының 12 нче сессиясе кысаларында әйтелгәнчә, азык-төлек глобаль базарында хәләл туклану продуктлары өлеше 15 процент тәшкил итә. Ә экспортка чыгарыла торган Татарстан агросәнәгать продуктларының тулаем күләмендә исә хәләл ашамлыклар күләме әлегә ике проценттан да кимрәк.

**– Күптән түгел республикага сөт продукциясен эшкәртү җиһазлары җитештерә торган танылган Испания компаниясе вәкилләре килгән иде. Әлеге компаниянең Татарстанда ике сыр ясау заводы бар инде, сүз хезмәттәшлекне дәвам иттерү хакында баргандыр, дип фаразлыйм. Бу аграр тармакка санкцияләр кагылмауны аңлатамы?**

– Кызганыч ки, чикләүләр аграрийларны да читләтеп узмады. Әмма чын партнерларны санкцияләр дә, дус булмаган илләр хөкүмәтләренең басым ясавы да куркытмады. Күп кенә чит ил предприятиеләре Татарстан агросәнәгать комплексы предприятиеләре белән хезмәттәшлекне дәвам итә. Шул исәптән сез әйтеп киткән компания дә.

**– Авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү куәтләре турында. Алар бүгенге җитештерү күләмнәрен канәгатьләндерерлекме?**

– Идел буе федераль округындагы авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү предприятиеләрендәге җитештерүнең тулаем күләменең 18 проценты Татарстан өлешенә туры килә*. Бигрәк тә сөт продуктлары җитештерү югары темпта үсә. Аерым алганда, сыр һәм сыр технологиясе буенча эшләнгән продуктлар җитештерү үсеше – 20 процентка, атланмайныкы 33,7 процентка диярлек артты. Татарстанда макарон эшләнмәләре – якынча 15 процентка, ярмалар 16,1 процентка күбрәк җитештерелә башлады. Күләмнәрне арттыра алабыз – куәтләр җитәрлек. Эшкәртү тармагын тагын да үстерү, яңа технологияләр кертү буенча да мөмкинлекләр аз түгел. Кырларда үстерелгән һәм фермаларда җитештерелгән продукцияне никадәр күбрәк эшкәртсәк, шулкадәр баерак булачакбыз.

* мәгълүмат 2021 ел нәтиҗәләре буенча

# «АГРОМАСТЕР»: ҮТЕМЛЕ БӘЯГӘ ЮГАРЫ СЫЙФАТ

Чәчү комплекслары, туфрак эшкәртү техникасы, авыл хуҗалыгы тагылмалары, Т-360 тракторы... «Агромастер» компаниясе җитештерә торган продукция модельләренең саны 250дән артып китә. Бу продукциянең сыйфаты турында, мөгаен, аны сату географиясе иң яхшы сөйләп бирә торгандыр. «Агромастер» техникасы Россиянең бөтен территориясендә, Казахстанда, Белоруссиядә сатыла. Европа таләпләренә җавап бирә торган сыйфатка ия продукцияне Татарстан компаниясе ни хисабына шундый үтемле бәядән җитештерә соң? Бу хакта – «Агромастер» компаниясенең башкарма директоры Фәрхәд Шәмсиев белән хәбәрчебез әңгәмәсендә.

**– Фәрхәд Рамилевич, авыл хуҗалыгы техникасы базарында көндәшлек шактый зур, шул ук вакытта сезнең продукциягә тотрыклы ихтыяҗ саклана. Моның сере нәрсәдә?**

– Сере юк. Аграрийларга югары җитештерүчәнлеккә ия, озын гомерле, сыйфатлы техника кирәк, ләкин бәясе акылга сыешлы булырга, ә күктән алынмаска тиеш. Һәм заманча сервис хезмәте күрсәтү дә таләп ителә. Без боларның барысын да тәэмин итәбез: сатып алучыларыбыз моңа реклама проспектлары аша гына түгел, үз тәҗрибәсендә – безнең чәчү комплексларын, туфрак эшкәртү техникасын һәм башкаларны куллану процессында да инана.

**– Техникагыз чыннан да Европа дәрәҗәсендәге сыйфатка ия, моны экспертлар да, ул техниканы кулланучылар да таный. Бу югарылыкка ни бәрабәренә ирешә алдыгыз?**

– Без чит илләрнең искергән модельләрен җыю белән шөгыльләнмибез. «Агромастер» маркетинг тикшеренүләре, эшләнмәләрне уйлап табу, конструкцияләүдән алып аларны җитештерүгә, сатуга чыгаруга, гарантия чорында һәм аннан соңгы сервис хезмәте күрсәтүгә кадәр бизнесның тулы циклын гамәлгә ашыра. Һәр этапта эшне тиешле дәрәҗәдә башкармаганда, лаеклы сыйфатка ирешеп булмый. 95% механик эшкәртү куәтле токарьлык һәм координаталы фрезер комплекслары белән башкарыла, алар программалаштырылган идарәле һәм бик югары төгәллеккә ия. Металл автоматлаштырылган лазер комплексларында киселә. Җитештерү процессында роботлаштырылган эретеп ябыштыру комплекслары кулланыла. Барлык эшләрне дә югары квалификацияле белгечләр башкара. Конструкторлык бюробыз яхшы җиһазландырылган һәм бик көчле, яңа техниканы булдыру вакытында, дөньядагы иң яхшы үрнәкләрне исәпкә алына, цифрлы технологияләр, өч үлчәмдә проектлау ысулы файдаланыла.

**– Иген һәм башка культуралар үстерүчеләргә «Агромастер» нинди техникалар тәкъдим итә?**

– Без туфракны минималь эшкәртү өчен культиватор тибындагы киң колачлы чәчү комплекслары, авыл хуҗалыгы культураларының барлык төрләрен, шул исәптән кукуруз, карабодай, рапс, көнбагыш һәм башкар бөртеклеләрне игү өчен, дисклы-культиваторлы һәм дисклы чәчү комплекслары, культиватор, дисклы культиваторлар, дисклы

Фотолар «Агромастер» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

агрегатлар җитештерәбез. Безнең техника ярдәмендә үсемлекчелек продукциясен җитештерү белән игенчелекнең классик технологиясе буенча да, No-till, Mini-till, Strip till* һ.б. кебек заманча технологияләр буенча да шөгыльләнергә мөмкин. Бөтен техника төрле төбәкләрнең машина сынау станцияләрендә сынау уза, төрле климат шартларында тикшерелә.

**– Әгәр компаниянең техникасын Көнбатыш аналоглары белән чагыштырсак...**

– Без бернәрсәдә дә калышмыйбыз. Алай гына да түгел, «Агромастер» техникасы һәркем сатып ала алырлык детальләр кулланып эшләнә, ә алар күп тапкыр арзанрак. Теләсә нинди куәттәге тракторга агрегат кидлеген һәм төрле агротехник алымнарны сайлап алу мөмкинлеге бар. Россиядәге авыл хуҗалыгы тармагының хәзерге төп бурычларыннан берсе – ресурсларны сак тоту һәм югары җитештерүчәнлекне күздә тоткан заманча технологияләргә күчү. Компаниянең миссиясе – һәркем сатып алырлык хак торган, кулланылышы ягыннан катлаулы булмаган, Европа дәрәҗәсендәге авыл хуҗалыгы техникасын җитештерү.

**– Бүген «Агромастер»ның нинди яңа эшләнмәләрен күрергә мөмкин?**

– Илебез аграрийлары тарафынннан Agrator Disk дисклы чәчү комплексы лаеклы бәяләнер, дип ышанам. Техника 12 яки 9 метр колачка ия һәм шактый югары – сәгатенә 15 км га кадәр тизлектә чәчә ала. Моннан тыш, яңа җайланма күчереп йөртү өчен уңайлылыгы белән дә аерылып тора. Тар бункер яхшы күз күремен тәэмин итә. Чәчү комплексының өр-яңа төр җыелып кую системасы бер басудан икенчесенә гомуми файдаланудагы юллар буйлап күчәргә мөмкинлек тудыра.

**– Комплексны инде эштә сынап карадылармы?**

– Чәчү комплексы Ставропольдә, Калмыкиядә сынаулар узды һәм искиткеч нәтиҗәләр күрсәтте. Төп нәтиҗә: агрегат вакытны шактый янга калдырырга мөмкинлек бирә, ә чәчү чорында аның никадәр кыйммәтле ресурс булуын барыбыз да беләбез. Яңа Agrator Disk җиңел җыела һәм шулай ук җиңел генә эшкә әзерлек халәтенә китерелә. Аны төяү һәм чәчүгә әзерләү эшен бер механизатор башкарып чыга. Аерым пневматик бункеры, ике винтлы шнек көйләнгән төягече һәм пневматик чәчкеч системасы булган заманча чәчү комплексы кешенең чәчүлек материал һәм агуланган орлыклар белән турыдан-туры контакты мөмкинлеген юкка чыгара.

Агрегатның берсүзсез өстенлеге – эшнең югары тизлеге: ул, кабатлап әйтәм, тиз-тиз эшләп, бер сәгать эчендә 15–20 га мәйдан чәчәргә мөмкин. Чәчү тизлеге югарырак икән, димәк, ягулык һәм вакыт чыгымнары да азрак. Шул ук вакытта чәчүнең сыйфаты зыян күрми: Zero Max теләсә нинди тизлектә дә чәчүнең тигез алып барылуын тәэмин итә. Agrator Disk бөртекле һәм вак орлыклы культуралар белән эшли, ягъни киң буразналылардан кала, бөтенесе белән дә диярлек. Вак орлыклы культураларны чәчү өчен кирәкле кәтүк агрегатның комплектына кергән.

### AGRATOR DISK АГРЕГАТЫНЫҢ ҮЗЕНЧӘЛЕКЛӘРЕ

- Тар бункер яхшы күз күремен тәэмин итә, яңа төрле җыеп кую системасы гомуми кулланыштагы юлларда тоткарлыксыз хәрәкәт итәргә мөмкинлек бирә.
- Тагылма бункер һәм дисклы чәчкеч составына киң колачлы чәчү комплексы да керә.
- Бик тиз генә транспорт халәтенә китереп була. Күченгәндә югары мобильлеккә һәм уңайлылыкка ия.
- Пневматик чәчеп бару системасы бар.
- Чәчеп бару нормасы бер урыннан көйләнә.
- Кешенең орлык һәм ашламалар белән контакты булмый.
- Трактор гидросистемасы аша хәрәкәткә китерелә торган шнеклы үзтөягече бар.

AGROMASTER
www.pk-agromaster.ru
тел.: 8(85556) 2-39-08
тел.: 8-939-396-83-44
e-mail: agromaster@mail.ru
Татарстан Республикасы,
Мөслим авылы,
Тукай урамы, 33а
Европача сыйфат — Россия бәясеннән!

* но-тилл, мини-тилл, стрип-тилл

# ФЕРМЕРНЫҢ КҮҢЕЛЕ ТЫНЫЧ

Республикабызның агросәнәгать комплексын үстерүдә фермер хуҗалыклары зур хезмәт куя. Татарстанның сөт, ит җитештерү буенча алдынгылар сафында булуында фермерларыбызның өлеше – бәхәссез.

Һичшиксез, крестьян-фермер хуҗалыкларына дәүләт ярдәме мөһим роль уйный, әмма фермерлар үзләре дә кул кушырып утырмый. Эшнең яңа, нәтиҗәле формаларын эзләп, күпләр үз көчләрен берләштерә һәм шул рәвешле искиткеч нәтиҗәләргә ирешә. Мондый берләшүгә бер мисал – «Мировет РТ» компаниясе, ул үз канаты астында берничә фермер хуҗалыгын туплап, аларга үсешнең яңа дәрәҗәсенә чыгарга мөмкинлек бирде.

Җитештерү кооперативлары шактый киң таралган, әмма менә кооперациягә башка күзлектән карап, эшне һәр якка файдалы булырлык итеп оештыру һәркемнең дә кулыннан килми.

«Башта үз алдыбызга эре мөгезле терлекләр белән эшли белгән һәм эшләргә әзер булган фермерларны табу бурычын куйдык, – ди «Мировет РТ» компаниясенең үсеш буенча директоры Ришат Өлфәт улы Зарипов. – Бу төп таләпләребезнең берсе. Хәзер без барлыгы 300 баш терлекле өч фермер хуҗалыгы белән эшлибез, якын арада тагын дүртәү кушылырга тиеш. Без фермерларны бергә эшләргә чакырабыз һәм аларның санын 50 гә җиткерергә планлаштырабыз. Хезмәттәшлек кысаларында нәрсә тәкъдим итәбез соң? Иң элек сүз бозаулар, симертү чоры дәвамында катнаш азык һәм ясалма сөт белән тәэмин итү, сөт таксие, ветеринар ярдәме турында бара. Фермерга өметебез зур – ким дигәндә 100 баш бозауны симертү өчен яхшы шартлар тудыру, бозауларны эчертүнең автоматлаштырылган системасын көйләү, түшәмә материал җәю. Бозауларны вакытында ашату-эчертү, үзләрен дә, торган урыннарын да чиста тоту мөһим, чөнки бозаулар үскән бинада дымлы һәм пычрак булса, алар авырый башлый һәм авырлык җыюдан туктый.

Яңа объектны эшләтеп җибәргәндә, ветеринария табиб-технологы бер атна фермада яши, яшь бозауларны дөрес асрарга һәм дәваларга өйрәтә, файдалы киңәшләрен җиткерә, барлык мөһим дарулар белән тәэмин итә. Кирәк була калса, ветеринар моннан соң да теләсә нинди ашыгыч чакыруга килергә яки читтән торып консультация бирергә әзер. Айга бер тапкыр үтә торган мәҗбүри үлчәү эшендә дә ул шәхсән үзе катнаша, бөтен көтүне җентекләп тикшереп чыга.

Беренче тәҗрибәбез дөрес юнәлештә баруыбызны раслады. Дүрт айлык бозауларыбызның авырлыгы 200-210 килограмм тәшкил итә. Бер ай эчендә алар 40-60 килограммга кадәр арта. Сыйфатлы катнаш азык һәм табигыйнә тиңдәш ясалма сөт куллану бу очракта зур роль уйный, чөнки без берүк вакытта консультатив ярдәм дә күрсәтә торган, сыналган тәэминатчы компанияләр белән эшлибез.

6,5-7 айлык теше бозауларның авырлыгы якынча 280 килограммга җитә, һәм без аларны инде фермерлардан суярга алып китәбез, ә үгезләрне тагын да симертү өчен калдырабыз. Матди керем мәсьәләсенә килгәндә, фермерлар көненә һәр бозаудан 70 сум акча эшли. Әгәр алар барлык шартларыбызны үтәсә, күпләп үлем-китемгә юл куймаса, артымнары яхшы булса, ахырда алар файдасына тулы исәп-хисап ясала.

Фермер өчен иң зур уңайлылык шунда: аның бозауларны, азыкны каян алырга, малны кая озатып җибәрергә, итне ничек сатарга дип башы авыртмый. Сату базарларыбыз яхшы көйләнгән, шуңа күрә фермер бозау үстерү-карау белән генә шөгыльләнә.

Заказ бирүче – фермер – кулланучының үзара элемтәдә эш итүеннән гыйбарәт мондый система кооперациядә катнашучыларның барысына да файдалы булып чыга. Һәр очракта да тәмле яшь бозау итен сатып алучы отышта кала.

Мондый хезмәттәшлек формасының никадәр файдалы булуы турында без фермерларның үзләреннән дә сораштырдык.

Фото «Мировет РТ» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

**Вячеслав Гурнович, «Гурнович КФХ» рәисе, Татарстанның Кайбыч районы Беляево авылы:**

– Мин шәһәр кешесе, Казанда туып үстем. Ләкин кайбер сәбәпләр аркасында, авылга күчендем һәм башта төзелеш белән шөгыльләндем. Ләкин бервакыт ташландык фермалар яныннан узганда, башыма уй килеп китте: «Нигә үзеңне терлекчелектә сынап карамаска?» План яздым да «Гаилә терлекчелек фермалары» программасы буенча грантка гариза бирдем. Шул рәвешле алынган 1 миллион сумга ферма салдым, ә ике елдан соң, 2013 елда, «Россельхозбанк»тан максатчан кредит алып, беренче ун сыерны кайтардым. Соңрак үз акчама тагын 43 тана сатып алып, сөтчелек белән шөгыльләнә башладым. Бернидәр вакыт барысы да яхшы барды, ләкин, ни кызганыч, сөт бәясе кискен төште һәм үгез симертүгә күчәргә туры килде. Ләкин анда да чыгымнар шулкадәр күп булгалады ки, еш кына бөтенләй керемсез эшләдем. Азыкны үземә әзерләргә, җиһазлар сатып алырга һәм аларны ремонтларга, кыйммәтле ягулык-майлау материаллары кулланырга туры килде. Ел ахырында, барлык салымнар түләнгәч, бернинди файда алмаганымны аңладым.

Аннары «Мировет РТ» компаниясе турында ишеттем. Мин алар белән әле күптән түгел генә хезмәттәшлек итсәм дә, никадәр җиңел сулыш ала башлавымны инде хәзер үк тоям.

Хәзер минем көтүдә 120 баш терлек бар. Компания миңа быел февраль аенда ак-зәңгәрсу Бельгия токымы үгезләре белән каплатылган голштин сыерларының 5 көнлек бозауларын бирде. Алар 35-40 килограмм авырлыкта иде, ә хәзер, дүрт айдан соң, инде 250 килограммнан арттылар.

Алар тәкъдим иткән симертү методикасы зур хөрмәткә лаек. Беренчедән, алар чын сөтнең бик яхшы алмашы булган ясалма сөт һәм сыйфатлы катнаш азык белән тәэмин итәләр. Икенчедән, бозаулар беркайчан да, бер минутка да ач калмый. Теләсә кайсы вакытта аларның ризыгы бар. Дөрес старт бик мөһим. Ветеринар көтүне сәламәт тотарга булыша, аның белән тәүлек әйләнәсе элемтәдә торабыз . Әгәр бозауларның берсе авырый диган шик туа икән, мин видео төшерәм дә, хәлне аңлатып, ветеринарга җибәрәм. Ул миңа шунда ук җавап бирә.

Әлбәттә, хәзер авылда кадрлар җитмәү бик сизелә. Яшьләр авыл хуҗалыгында эшләргә теләми, китми калганнарын җәлеп итәргә туры килә. Фермер өчен тагын бер кыенлык – продукцияне сату мәсьәләсе. Шуңа күрә «Мировет РТ» кебек компанияләр белән хезмәттәшлек – сату проблемасын уңышлы хәл итү дә әле ул. Мин бары симертү белән генә шөгыльләнәм, айга ике тапкыр компаниядән һәр баш терлек өчен акча алам, ә алар симертелгән бозауларны сатарга алып китә.

**Алмаз Заһидуллин, «Заһидуллин КФХ» гаилә фермасы башлыгы, Буа районының Иске Суыксу авылы:**

– Мин авылда үстем һәм һәрвакыт малтуар янында эшләргә теләдем. Һөнәрнең дә шуңа туры килгәнен сайладым – ветеринария табибы булырга укыдым. Биш ел элек җитди рәвештә терлекчелек белән шөгыльләнергә карар кылдым. «Яңа эш башлаган фермер» программасы буенча 3 миллион сумлык грант оттым һәм шул акчага инде 80 процентка әзер булган ферманы төзеп бетерү эшенә керештем. Маллар сатып алдым, һәм әнә шулай экренләп эш алга китте.

Мөстәкыйль эшләгәндә, әлбәттә, терлек симертү процессында өзеклекләр килеп чыкмасын өчен, бик күп көч куярга туры килде. «Мировет РТ» компаниясе турында ишеткәч, иң беренче чиратта аларның яңа технологиясе турында белештем. Ул игътибарны төрле оештыру эшләре белән бәйле мәсьәләләргә юнәлтмәскә мөмкинлек бирә. Компания шунда ук югары сыйфатлы бозаулар тәкъдим итә һәм яшь бозауларны симертү өчен сыйфатлы азыгын да бирә.

Хәзер көтүемдә 90 баш мал бар. Иң элек шуны әйтә алам: эшчеләрнең пөхтәлеге, җаваплылыгы һәрвакыт мөһим, әмма көтүнең сәламәтлегенә кагылышлы теләсә нинди вак-төяккә дә намус белән карый торган кешеләр кирәк. Чөнки бозаулар тирәсе пычрак булса, алар шунда ук авыруга бирешә. Бозаулар кечкенә баладан да нәзберегрәк, технология бераз гына бозылса да, ашказаны-эчәк системасы белән бәйле проблемалар башлана.

Мин һәр көн иртән малларга күз-колак булып, карап чыгам. Әгәр берәр бозауның хәлсезрәк икәнен күрсәм, шунда ук дәвалый башлыйм. Мин үзем дә ветеринар булгач, барысын да бик әйбәт беләм ,дип уйлый идем. Тик «Мировет РТ» компаниясенең ветеринары белән якыннан аралашкач, шуны аңладым: гомер буе укысаң да аздыр! Бер атна эчендә ул миңа бик күп нечкәлекләрне аңлатып бирде, сөйләде, күрсәтте.

Сату эше җайга салынганда, ит терлекчелеге белән шөгыльләнү файдалы. Һәм бу яктан караганда, «Мировет РТ» белән хезмәттәшлек миңа 100% туры килә.

Тулы көчеңне биреп эшләгәндә, бер эш тә җиңел түгел. Мин элеккечә иртәдән кичкә кадәр фермада, әмма кооперация күп проблемаларны хәл итә. Фермага симертү өчен бозауларны кертеп урнаштырганчы, компания башта барлык кирәкле азыкны, ясалма сөтне һәм хәтта печәнне дә китерә. Бозаулар бик тиз үсә. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: голштин һәм ак-зәңгәрсу Бельгия токымнарын кушып алынган бозаулар үсеш темплары ягыннан башкалардан күпкә өстенрәк. Шушы сүзләр бөтен нәрсәне әйтеп бирә дә инде. Минем эшне күзәтеп барган бер танышым да бу компаниягә кушылырга тели. Чөнки файдасы көн кебек ачык.

«Мировет РТ» компаниясенең планнары зурдан. Якын арада Татарстанның Теләче районында 3200 башка исәпләнгән ике терлекчелек комплексы төзелә башлаячак. Җитештерү комплекслары автоматлаштырылган булачак, бу исә яңа предприятиедә эшкә яшьләрне җәлеп итәргә мөмкинлек бирәчәк.

Дөрес юнәлештә дөрес адымнар – уңышка таба хәрәкәт әнә шул ул.

**Ришат Өлфәт улы Зарипов, «Мировет РТ» ЖЧҖ – бозау симертү өлкәсендә кооперация. +7 (987) 297-80-62**

# «ВАМИН»:

# «ТӘМЛЕ, ФАЙДАЛЫ, ТАБИГЫЙ РИЗЫКЛАР – ҺӘР ЙОРТКА»

«Вамин» компанияләр төркеме уңышы – Көнбатышның кырыс санкцияләренә карамастан, илебездә җитештерү тармагын куәтле һәм максатчан үстереп булуына ап-ачык үрнәк. Кайчандыр аңыбызда чын сырлар Швейцариянеке генә була ала дигән фикер яши иде. Хәзер без төгәл беләбез – бу алай түгел! «Вамин» сырлары – чын сөттән ясалган, тәмле, Россия кулланучысы тарафыннан лаеклы бәяләнә.

Компаниянең 20 ел эчендә ни рәвешле үзгәрүе, продукциянең югары сыйфатына ничек ирешүе һәм илебезнең кибет киштәләренә «Вамин» брендлы нинди яңа ризыклар чыгуы турында «Вамин» компанияләр төркеме җитәкчесе **Минтимер Минһаҗев** сөйли.

– 2013 елда «Вамин»да җитештерү процесслары үзгәртеп корылды, нәтиҗәдә без үзебезнең бизнес-модельне үзгәрттек. Хәзер төп юнәлешләребез табигый сырлар һәм атланмай җитештерүдән гыйбарәт. Без максат итеп куйган кулланучылар аудиториясе таләпләре нәтиҗәсендә слоганыбыз да үзгәрде. Хәзерге вакытта «Вамин» бренды «Натураль, тәмле һәм файдалы ризыклар – һәр йортка» дигән девиз белән эш йөртә.

Әгәр әле күптән түгел генә, кризис, пандемия, махсус операция аркасында кулланучылар түбән бәяле продукция сегментына табарак авышкан булса, бүген инде халыкның азык-төлек сыйфатын беренче урынга куюы тенденциясе күзәтелә.

Шуңа күрә без продукциябезне сыйфатлы итеп чыгаруга бик җитди карыйбыз. Компаниянең төп миссиясе – югары этика һәм экология стандартларына туры китереп җитештерелгән сыйфатлы сөт продуктлары аша барлык сатып алучыларны, ягъни сезне һәм гаиләгезне кайгырту. Без, бәлки, зур сөт компанияләреннән масштаб ягыннан калышабыздыр да, әмма шулай да сөт индустриясендә алдынгы урыннарны яулау, сыйфат белән дан казану, трендларга башлангыч бирү һәм инновацияләр белән илһамландыру максатына омтылабыз. Җитештерү тармагында да, сату юнәлешендә дә моны тормышка ашырырдай яшь, амбицияле, көчле командабыз бар.

Хәзерге вакытта без базарда иң кирәкле товар категорияләрен чыгарабыз: табигый сыр, атланмай, коры сөт сывороткасы, майсызландырылган коры сөт. Арча, Балтач һәм Аксубайда өч җитештерү мәйданчыгыбыз бар, Питрәчтә үз логистика үзәгебез эшли. Үзебезнең 4000 баш мөгезле эре терлегебез бар дип горурланып әйтәм. Моның белән сирәкләр генә мактана ала. Дөрес, әлегә чималның бер өлешен сатып алырга туры килә, әмма тулысынча ябык цикллы җитештерүне җайга салып, бөтен продукция өчен үз чималыбызны гына файдалану планлаштырыла. Шул максатларда терлек санын арттырабыз.

«Вамин» һәр тәүлек 650 тонна сөт эшкәртә һәм 100 тоннага якын әзер продукция җитештерә. Ул Россиянең барлык төбәкләренә диярлек озатыла. Берничә сату каналыбыз бар. Болар – күпләп сату каналы, анда сырлар зур-зур тәгәрмәчләр рәвешендә китә, тагын әле ваклап сату каналы һәм эшкәртү предприятиеләренә җибәрү каналы да бар.

Безнең белән туңдырма җитештерүчеләр, икмәк-күмәч, кондитер һәм ит эшкәртү предприятиеләре, шулай ук кунакханәләр, рестораннар, кафелар хезмәттәшлек итә. Соңгы вакытта Россиядә генә түгел, Таҗикстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Казахстан кебек күрше илләрдә дә дистрибуцияне актив үстерә башладык. «Вамин» компанияләр төркеме халыкара күргәзмәләр һәм форумнарда актив катнаша. 2023 елның маенда продукциябезне – Кытайдагы SIAL China 2023 Халыкара азык-төлек продуктлары һәм эчемлекләр күргәзмәсендә, ә февральдә Дубайда узган Gulfood 2023 Халыкара азык-төлек сәнәгате күргәзмәсендә тәкъдим иттек.

Өч ел элек ребрендинг ясадык, хәзер «Вамин» логотибы үзгәрде һәм заманчарак күренә, хәер, ул әүвәлгечә үк тиз таныла торган булып калды. Гади кулланучылар белән күп эшләү безгә алардан бәяләмәләр, фикерләр алырга мөмкинлек тудыра.

Промоутерларыбыз сәүдә нокталарында продукциябез турында

Фото «Вамин» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА

сөйли, яңалары белән таныштыра. «Вамин»ның ваклап сату секторында активлашуына кешеләрнең гаҗәпләнүен һәм шатлануын күрәбез, шуңа күрә брендны танытуга игътибарны арттыру безнең өчен бик мөһим. Брендның төп идеясе үзгәрмәде – бөек казанышларга омтылыш, Татарстан Республикасына, туган ягыбызга бирелгәнлек, ә үзәктә – ата-бабаларның гореф-гадәтләренә, традицияләренә хөрмәт белән яшәүче гаилә.

Ассортиментыбыз гаять бай. Без 17 дән артык төрдәге сырлар чыгарабыз. Болар – «Голландский», «Гауда», «Российский», «Тильзитер», «Маасдам», «Пармезан» кебек классик сырлар һәм горурлыгыбыз – үз рецептурабыз нигезендә әзерләнгән премиаль категориядәге «Императорский» сыры. Бу ярымкаты сыр, ләкин җитештерү процессында аңа пармезан ачыткысы өстәлә, бу исә безнең «Императорский» сырына гадәти булмаган тәм бирә. Сырларның 2,5 килограмм, 5 килограмм һәм 15 килограмм авырлыктагылары һәм ваклап төрелгәннәре бар.

Ваклап төрелгән сырлар аеруча популяр, һәм без моны, әлбәттә, исәпкә алабыз. Андый формадагы сигез төрле сыр чыгарабыз – «Эдам», «Голландский», «Гауда», «Мраморный», «Сливочный», «Российский», «Императорский» һәм «Фермерский».

Без чыгара торган атланмай турында да искә алу урынлы, чөнки ул төп юнәлешләребезнең берсе. Хәзерге вакытта «Мой милок» һәм «Вамин» брендлары линейкасында 72,5 процент майлылыктагы атланмайлар җитештерәбез. Май дүрт рәвештә тәкъдим ителә – 500 һәм 1000 граммлы пластик контейнерларда, 180 һәм 500 граммлык фольгалы стандарт төргәкләрдә. Илнең төрле төбәкләрендә кешеләрнең зәвыгы шактый аерыла, шуңа күрә без май өлеше күбрәк булган атланмай җитештерүне җайга салырга планлаштырабыз. Мәскәүлеләр, самаралылар яки Ленинград өлкәсендә яшәүчеләр атланмайның майлырагын ярата төшә, ә без, әлбәттә, барлык клиентларыбызның да теләген канәгатьләндерергә телибез.

Продукциябезнең югары сыйфатын тәэмин итү, барлык тенденцияләрне, трендларны, сатып алучыларның ихтыяҗларын тою өчен, без күп тикшеренүләр уздырабыз, базарга даими анализ ясыйбыз. Шул рәвешле, яңа ихтыяҗларны искә алып, «Вамин» линейкасында тагын өч яңа продукт чыгарырга карар кылынды. Бу – югарыда телгә алынган «Императорский» сыры, шулай ук берничә ай элек җитештерелә башлаган «Российский» һәм «Сливочный» сырлары. Без карарыбызның дөрес булуын инде хәзер үк күрәбез, чөнки сәүдә челтәрләре бу сырларны бик теләп үз ассортиментларына кертә. Бераз онытылып калган «Мой милок» сәүдә маркасына да яңа сулыш өрдек. Әгәр «Вамин» уртача керемле яки шуннан югарырак сегменттагы сатып алучыга исәпләнгән булса, «Мой милок» күбрәк эконом сегментка карый.

«Мой милок» сәүдә маркалы сыр һәм аның сыйфаты «Вамин» сырларыныкы белән бер үк. Бәя термоэтикеткалы, үтә күренмәле 300 граммлык төргәк хисабына төшерелә. 3-4 кешелек гаилә өчен бу – уңайлы формат. Тәҗрибә 300 граммлык төргәккә аеруча ихтыяҗ зур булуын күрсәтә.

«Мой милок» «Находка» кибетләре челтәрендә инде хәзер үк сатыла. «Мой милок» маркалы «Россия» һәм «Сливочный» сырларыннан тыш, партнёрлар «Голландский» һәм «Тильзитер» да сатып алырга теләк белдерде, димәк, бу сырлар да тиздән сатуга чыгачак.

Сырларыбызның бөтенесе дә белгечләребезнең җитди контролен уза. Моңа кадәр сырларны сәүдә ноктапарында гади кулланучылар татып карый, фокус-төркемнәрдә дегустацияләр үтә, анда продуктны аерым бер максатчан аудитория бәяли.

Димәк, бу да рецептураны һәм әзер продуктның характеристикасын яхшырту өчен гаять мөһим ысул булып тора.

Алынган нәтиҗәләр нигезендә, белгечләр, технологларыбыз, лаборатория начальнигы, җитештерү директорлары тарафыннан югары квалификацияле бәяләүне күздә тоткан йомгаклау дегустациясе уздырыла. Кайда нәрсәне яхшыртырга кирәклеге турында карарлар шунда кабул ителә. менә шулай итеп без йөзебезгә кызыллык китермәслек сыйфатка ирешәбез.

# «ТӘҮЛЕК БУЕ ЭШЛИБЕЗ!»

Руфия Фазылова

**Арча районындагы «Кырлай» агрофирмасын республикада яхшы беләләр. Гаҗәп тә түгел: Татарстанда җитештерелә торган бәрәңгенең 60 процентын биредә үстерәләр. Биредә шулай ук сөтчелек юнәлеше дә көчле – май аенда яңа мегафермалары эшли башлаган.**

**Авыл хуҗалыгы тармагы заманга ничек яраклаша? «Кырлай» агрофирмасы мисалында әнә шул сорауга җавап эзләдек.**

## ӘТИ ЮЛЫННАН…

Агрофирма карамагында бүген 10 732 гектар җир бар. Шуның 70 проценты – агрофирманың шәхси җирләре, калганы халыкның пай җирләре. (Арча районының ун авылы алар карамагында.) Димәк, бу авылларда буш җирләр юк диган сүз, ә халкы эш белән тәэмин ителгән. Хуҗалыкта бүген 180 кеше көч куя, ә сезон вакытында бу сан бермә-бер арта дияргә була. Читтән егермеләп «КАМАЗ» машинасын гына җәлеп итәләр. Көзен хатын-кызларга да эш җитәрлек була, ләкин ул турыда соңрак.

Башта «Кырлай» агрофирмасының тарихына тукталасы килә. 2003 елда аны РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре, «Сервис-Агро» директоры Габделхәй Кәримов оештыра. Ни кызганыч, Голландия, Германияләргә барып, авыл хуҗалыгы тармагын өйрәнгән тынгысыз җитәкче, ТР Дәүләт Советы депутаты булган Габделхәй Йосыф улы кинәт вафат була. Һәм әти кешенең эшен балалары дәвам итәргә алына.

– Әти исән чагында ук Арчага күченеп кайттык, гаиләм дә хәзер биредә яши, – диде Марат Кәримов. –

Фотоларны «Кырлай» компаниясе тәкъдим итте. РЕКЛАМА

Шәһәрдә туып үскән егет булсам да, кечкенәдән әти-әни белән Арча районына кайтып йөрдек. Әти бик кешелекле иде, без аның тәрбиясен алган балалар. Казан дәүләт авыл хуҗалыгы институтында укыганда ук авыл хуҗалыгы тармагын өйрәндем.

«Кырлай» агрофирмасына Марат Габделхәй улы 2018 елда килә. Аңлашыла, депутат буларак әтисенең вакыты тыгыз, ә авыл хуҗалыгы белән читтән торып кына идарә итеп булмый. Менә шуның өчен дә югары белем алган улы Маратка ата кеше җитди эш тапшыра – агрофирманың эшен дәвам итү, үстерү...

– Август ае, урып-җыю эшләре башланган иде, – дип дәвам итте сүзен Марат Габделхәй улы. – Иң беренче кырлар белән танышып чыктым. Менә шунда җир эшенә карата тагын бер кат ихтирам, мәхәббәт уянды. Гел хәрәкәттә инде: 2017–2020 елларга каралган капиталь төзекләндерү программасы буенча Иске Иябаш, Бирәзә авылларында 200 башка исәпләнгән сыер фермаларын яңарттык. Ә Яңа Кырлайда бәрәңге саклау базасын төзекләндердек. Әле менә Иске Иябаш авылында 1800 башка исәпләнгән мегаферма төзибез. Дөресрәге, аның беренче блогы узган ел май аенда кулланылышка тапшырылды инде. Анда бүген 600 баш сыер бар. Тәүлегенә 24 тонна сөт савабыз. Мегаферманың икенче блогын исә киләсе елга эшләп бетерергә планлаштырабыз. Бездә эш тәүлек буе туктамый, бигрәк тә сезон вакытында.

## «КОРЫЛЫКЛЫ ЕЛНЫ ДА УҢЫШСЫЗ КАЛМЫЙБЫЗ»

«Кырлай» хуҗалыгында 10 000 гектардан артык җир бар, дидем. Шуның 1 350 гектарында бәрәңге, кишер, кызыл чөгендер үсә, калганына исә иген, печән чәчелгән. Бәрәңге уңышын җыярга алар беренчеләрдән булып чыга, чөнки бик иртә өлгерә торган сортлар бар икән. Мең гектар җирдән узган ел 250 центнердан артык икенче икмәк җыеп алганнар. Заман таләпләренә яраклашып, биредә бәрәңгене, вакуумлап төреп, сатуга да чыгаралар.

– Кызганычка, быел бәрәңгегә сорау аз, – диде «Кырлай» агрофирмасының баш агрономы Рәмис Абдрахманов. – Узган ел «КАМАЗ»лар чират торды. Икенче икмәкнең бәясе дә кыйммәт иде – кырык сумнан артып китте. Ә быел исә алты сумга кадәр төште. Ә менә иген белән оттык: урып-җыю чоры башланганчы ук, бодайның килосын – унике, арышныкын тугыз сумнан саттык. Узган ел өчен ул начар булмады, игенгә бәя бик түбән иде бит. Авыл хуҗалыгы тармагында шулай инде, кайда отасыңны, кайда оттырасыңны белмисең.

Әйткәнемчә, Татарстанда җитештерелә торган бәрәңгенең 60 процентын «Кырлай» хуҗалыгында үстерәләр. Моның өчен барысы да җайлаштырылган: 32 мең тонна яшелчә сыя торган базлары бар. Басулар су сибү агрегатлары белән җиһазландырылган. Соңгы елларда яңгырлар бик кинәндерми, су сибәргә туры килә.

– Су сибү агрегатлары төрле, – диде баш агроном. – Совет чорындагы кебекләре дә, чит илдән кайтарылганнары да бар. Әлбәттә, соңгылары бик көчле: бер урыннан икенче урынга күчереп йөртеп була. Яшелчә үсә торган 1 350 гектар җирнең 800-900 гектарына әнә шулай су сиптерә алабыз. Шулай булгач, корылыклы елны да уңышсыз калмыйбыз.

Бәрәңге, кишер, чөгендерне урнаштыруда әлегә кадәр проблемалар чыкмаган: күпләп сатып алучылары бар, ярминкәләрдә дә китә. Зур баз булгач, язга кадәр саклана. Шулай да иген белән чагыштырганда, яшелчә культураларын үстергәндә аерым бер куркынычы бар икән: иген сатылмаса да, еллар буе амбарда саклана, ә яшелчә череп юкка чыга. Әнә шуның өчен дә «Кырлай» хуҗалыгында берьюлы берничә тармакны алып баралар.

Агрофирманың тагын бер тәҗрибәсен әйтми кала алмыйм: берничә ел элек биредә эшчеләр өчен биш йорт салганнар. Бөтен уңайлыклары булган заманча торак ул. Аларда агрофирманың эшчеләре яши, нигездә – яшь гаиләләр. Эшчеләр өчен тагын йортлар салу нияте бар икән, чөнки җитәкчелек яхшы аңлый – яшь гаиләләрне авылда калдыруның бер чарасы ул.

...Тукаебызның яраткан авылы – «Кырлай» исемен йөрткән агрофирманың әнә шулайныклы адымнар белән алга баруына ихластан сөендек. Әтисе һөнәрен дәвам иткән Марат Кәримов кебек яшьләр тагын күбрәк булсын иде. Тәҗрибә күрсәткәнчә, җир эшен яратсаң, шәһәрдә туу авылда яшәү өчен киртә түгел! Т

# АЛТЫНЛЫ ТӘМЛЕ МАЙ

Беренче тапкыр 2022 елда «Россия – Ислам дөньясы» XIII Халыкара саммиты күргәзмәсендә тәкъдим ителгән «Хан алтыны» үсемлек мае көннән-көн популярлык яулый бара. Базарга чыгуларына бер генә ел булса да, аны җитештерүчеләр продуктның тәме һәм югары эстетикасы турында күп санлы бәяләмәләр алган инде. Майның тагын бер өстенлеге – ул Татарстанда эшләнгән һәм шунда җитештерелә. Дөньяда бу майның тиңе юк.

Сүз премиум линейкага караган искиткеч продукт турында бара, аның составында азык-төлек алтыны бар: 150 мл га – бер карат алтын. Идея авторы – Татарстанда уңышлы эшмәкәр буларак танылган Эльза Тихонова, ул берьюлы берничә юнәлештә эш алып бара. «Бервакыт, күпләп сату бизнесы белән шөгыльләнгәндә, без компания ассортиментына көнбагыш мае өстәдек, аңа һәрвакыт ихтыяҗ югары. Мин әлеге файдалы продуктка үзенә күрә кыйммәт өстәргә, аның иң кадерле кешеләргә горурланып бүләк итә алырлык булуын теләдем, – дип искә ала эшмәкәр. – Беренче белемем буенча мин технолог, химияне бик яратам һәм, башыма мондый идея килгәч, экспериментлар ясый башладым. Моңа яраклы мәкаләләр эзләдем, тик андыйлар табылмады, һәм шул вакытта ниятемне үз көчем белән тормышка ашыру карарына килдем».

2019 елда берничә үрнәк эшләнеп, экспертизага җибәрелде. Лаборатория тикшеренүләрен узып, тиешле документларны алганнан соң, «Хан алтыны» мае Казанда уза торган иң зур вакыйга вакытында беренче тапкыр халыкка чыкты.

«Мин майны Согуд Гарәбстаны, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре һәм башка илләрдән килгән кунаклар катнашында KazanSummit күргәзмәсендә тәкъдим итә алдым. Продукт белән күпләр кызыксынды. Әлеге чарада катнашучылар билгеләп үткәнчә, бу майда нindидер серлелек, Шәрык төсмере, көч һәм шул ук вакытта матурлык һәм баланс та бар. Сәүдә-сәнәгать палатасы делегациясе составында Бакуга сәфәр вакытында, Азәрбайҗанда, майның беренче үрнәген Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнехановка бүләк иттем. Без Согуд Гарәбстаны вәкилләреннән, сәүдәне үстерү, логистиканы җайга салу максатыннан, алар территориясендә завод төзү турында тәкъдим алдык», – дип сөйли Эльза Тихонова.

Ул кулдан килгән кадәр күбрәк кешегә продуктның үзлекләрен бәяләү мөмкинлеген тудырырга омтыла. Ә бу үзлекләр бихисап: «Хан алтыны» маен куллану тире структурасын һәм аның сузылучанлыгын яхшырта, барлык әгъзаларның һәм системаларның эшчәнлегенә булышлык итә, матдәләр алмашын яхшырта, матур һәм яшь булып калырга мөмкинлек бирә.

Продуктның нигезен салкын ысул белән беренче тапкыр сыгып алынган көнбагыш мае тәшкил иткәнлектән, ул көчле антиоксидант үзлекләренә ия Е витаминының бер төре – кыйммәтле токотриеноллар чыганагы булып тора. Тиңсез үзлеге – составында азык алтыны ионнары булу. Шул ук вакытта аны көн саен, бернинди чикләүләрсез кулланырга мөмкин.

Өстәвенә, алтын май иң кадерле кешеләргә бүләк итәсе килә торган сәнгать әсәре дә әле, ул үзенең энергитикасы, файдасы, матурлыгы белән хәтта бик күпне күргән кешенең күңелен дә яулаячак. Сүз уңаеннан, май кабындагы логотип Болгар музей-тыюлыгында саклана торган тарихи тәңкә нигезендә эшләнгән. Һәркем әлеге гади нәрсәдә гаҗәеп яңалык ачачак. Нәкъ менә шул сүзләр әлеге брендның шигаре булып тора да.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: тикшерү эше дәвам итә һәм анда алынган нәтиҗәләр нигезендә тиздән майның файдалы үзлекләре исемлеге тулыландырылачак. Эшмәкәр Эльза Тихонова Татарстанда үсемлек маен куллану культурасының үзгәрүенә сөенә, шул исәптән «Хан алтыны» брендының моңа өлеш кертүенә дә. Бу исә аның дәрәҗәсен күтәрә, кыйммәтен арттыра.


+79274457555

goldoil1@mail.ru

Купить-продукты.рф

Фото «Грин Поинт» компаниясеннән алынды. РЕКЛАМА


www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татарстан авыллары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая
грамотность

Реклама 16+

ТАТ МЕДИА

# ЯЗЫЛУЧЫЛАРГА СКУТЕР, ТЕЛЕВИЗОР

һӘМ БАШКА БҮЛӘКЛӘР

БҮЛӘКЛӘРНЕ УЙНАТУ: 17 АВГУСТ 2023 ЕЛ

**1 ЯЗЫЛ**

«ТАТМЕДИА» АҖнең бер газета һәм бер журналына язып (акциядә катнашучы басмалар белән tatmedia.ru сайтында танышып була)

**2 ҖИБӘР**

«Акция» билгесен куеп, язылу квитанцияләренең копиясен безгә 2023 елның 11 августына кадәр җибәр (телефон номерыгызны язарга онытмагыз!). Адрес: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 яки podpiska@tatmedia.ru

**3 ОТ**

Телевизор, газонокосилка, вертикаль пылесос һәм башка бүләкләр от. Иң зур бүләк – скутер! Бүләкләрне уйнату 2023 елның 17 августында узачак

Әлеге чараны оештыручы, кагыйдәләре, бүләкләр саны, уйнату вакыты һәм урыны буенча мәгълүматны tatmedia.ru. сайтында белә аласыз. Акция 2023 елның 16 маеннан 2023 елның 20 сентябренә кадәр уздырыла. Гаризалар 11.08.2023 кадәр кабул ителә. Реклама. Яшь чикләве 16+. Бүләкләр рәсемдәгедән аерылырга мөмкин.

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

# Бу санда тәкъдим итәбез:

Күренекле затлар **нинди** милли киемнәр кия

Татар костюмы тарихын **кайда** торгызалар

«Татарстан»ны мәңгелек туңлык иле **нәрсә** белән шаккатырды

**Ни өчен** Яңа Чишмә – җирдәге иң яхшы урын

Шәледә бәрәңгене **ничек** өяләр

# ХАЛЫК БӘЙРӘМНӘРЕ – МИЛЛИ КИЕМНӘР ЧАГЫЛЫШЫ

Халык бәйрәмнәре – милли киемнәр кию өчен менә дигән форсат. Үз халкыңның милли киеменә үзең дә сокланасың, башкалар да битараф кала алмый! Ә инде икенче милләтнең милли киемен киеп йөрү бигрәк тә кызык – үзеңне мари, удмурт, грузин, якут һ.б. итеп хис итәсең. Милли бәйрәмнәрдә ешрак кунак булган саен, матур киемнәреңнең дә саны арта бара. Халык бәйрәмнәре милли гореф-гадәтләрне, шул исәптән киемгә моданы торгызу өчен бер дигән мөмкинлек. Соңгы елларда модада әлеге юнәлеш шактый сизелә башлады. Бүгенге фотопроектыбыз да милли киемнәргә багышланган. Карагыз, сокланыгыз, безгә кушылыгыз! Бигрәк үзенчәлекле, матур һәм затлы бит!

Александр Ефремов, Ната Смирнова фотолары, rais.tatarstan.ru, Лилия Галимованың шәхси архивы

Татарстан Республикасы Рәисе
**Рөстәм Миңнеханов,**
Уяв бәйрәмендә чуваш милли киеменнән.

Ә менә бу костюмны аңа Семык бәйрәмендә Татарстанда яшәүче марилар бүләк итте.

ТР Дәүләт Советы Рәисе
**Фәрит Мөхәммәтшинга**
һәм Кукмара районы башлыгы
**Сергей Димитриевка**
куе зәңгәр төстәге удмурт милли киеме бик килешә.
Моны Нырья авылында узган
Гырон быдтон бәйрәмендә барысы да күрде.

ТР Рәисе матбугат хезмәте җитәкчесе

**Лилия Галимова**

киемнәрен татар милли бизәкләре төшерелгән аксессуарлар белән бизәргә ярата.

ТР Премьер-министры урынбасары

**Ләйлә Фазлыевага**

Сөембикә ханбикә киеме килешеп тора.

Татарстан үзбәкләре җитәкчесе

**Абдуманоб Абдулсаттаровның**

милли киеменнән, могаен, һәркем көнләшәдер.



Татарстан удмуртлары җитәкчесе

**Андрей Герасимов**

һәр Гырон быдтон саен милли чигешләр белән бизәлгән яңа кием кия.

Татарстанда яшәүче казахларның җитәкчесе

**Сәгыйть Жаксыбаевның**

милли киеменә бөтен кеше соклана.

«Мисс Татарстан 2022» титулы иясе

**Анна Атаманованың**

татар милли стилендәге киеме бигрәк матур.



Чуваш гүзәле

**Алия Карусеваның**

матурлыгына милли кием үзенчәлекле ямь өсти.

# КАЛФАК, ЧАПАН, ХӘСИТӘ...

Сафа Гәрәев

Вакыт кырыс. Кайчандыр әби-бабаларыбыз яратып кигән милли киемнәрне хәзер сандык төбеннән чыгарып карап булмый. Әмма «Татарстан», Казан Кремлендәге Кабул итү урыннарында оештырылган «Татар киеме – традицияләр һәм трансформация» күргәзмәсенә барып, борынгы киемнәрне күреп кайтты.

Баш киеме-очлым, тезгә кадәр озын камзул, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән авыр изү-хәситә (аның өчен асылташ-тәңкәләрне кыз бала тууга ук җыя башлаганнар). Мондый киемнәргә соклангында, кайчандыр Казан туташ-ханымнарының шундый авыр бизәнгечләрне тагып йөргәненә ышанып та булмый. Шул ук вакытта моны кайчандыр күргәнеңне хәтерлисең. Геннар дәрәҗәсендә сакланып калган хәтерме соң бу? Юк, барысы да бик гади: XVII гасырда яшәгән билгесез рәссам Сөембикә ханбикәне шуңа охшаш киемнәрдән сурәтләгән икән бит. Менә шушы картинаны кайчандыр күргәнгә, әллә нинди сәер хис туа да инде.

Борынгы казылмалардан ниндидер предметларны торгызган археолог кебек үк, ерак үткәндәге бай татар хатыны костюмын реконструкцияләгән рәссамны да бәлки нәкъ менә шул картина илһамга рухландыргандыр да әле. Сүз дә юк, яңартылган әлеге костюм сокландыра. Әмма икенчесе күңелгә тагын якынрак, анысы – узган гасыр башындагы авыл кызының киеме: күлмәк, чигелгән ап-ак алъяпкыч, көмеш чулпы кушып үрелгән чәч толымнары... Анысы бөтенләй башка төрле хисләр уята: бик якын, үзеңнеке, самими. Менә шунысын күргәндә геннар дәрәҗәсендә сакланып калган хәтер уянадыр кебек тоела. Чөнки безнең күпчелегебез аксөякләр нәселеннән түгел бит, тамырларыбыз авылга барып тоташа.

Автор фотолары

Бәлки, нәкъ менә шуңа бу реконструкциянең, рәссамның иҗат фантазиясе генә булмыйча, бик төгәл күчермә булуына ышанасы килә дер дә. Һәрхәлдә, минем йөз яшькә кадәр диярлек яшәгән әбием шундый костюмнан әле күптән түгел генә – узган гасырның җитмешенче елларында гына йөри иде. Ә ул кыз чагында чәч тулымына кушып үргән Әби патша (Екатерина) тәңкәсе безнең гаиләдә һаман саклана әле...

Хәер, әлеге күргәзмәдә һәр кеше күңелендә әллә нинди кадерле истәлекләр уяткан үз предметын күреп алгандыр мөгаен. Кемдер борынгы гаилә фотографиясендә сакланган калфакны «тапкандыр», кемдер татар хатын-кызларына буыннан-буынга тапшырыла килгән бизәнгечнең нәкъ менә чулпы булуын биредә тәүге тапкыр белеп алгандыр. Ә менә кайберәүләр XIX гасыр азагы шәһәрендә популяр «буржуаз» һәм европача татар киеменең традицион түбәтәй белән ничек ярашып торуына гаҗәпләнгәндер.

Тагын шунысы да таң калдыра: Казан татарларының тарихи киемнәрен яңартып иҗат иткәндә, хәзерге Татарстан осталары XIX гасыр азагы – XX гасыр башындагы чын материалларны (кытай ефәге, итальян винтаж тукымасы һ.б.) кулланган. Ихтимал, шуңа күрә дә торгызылган борынгы гүзәллек белән танышу шундый самими һәм һәркем өчен дә бик кадерле, якын булып чыккандыр. Әлеге күргәзмә даими эшләсен иде. Һәм тагын да кызыклырак булсын.

Чыннан да, яңа тегелгән костюмнар янәшәсенә ни өчен музейларда сакланган чыннарын да элеп куймаска әле? Ихтимал, алар беразтаушалгандыр, әмма бу тагын да көчлерәк тәэсир итә бит: үз заманының төсен саклаган әлеге киемнәр әллә нинди сихри куәткә ия булырга мөмкин. Костюмнар ярдәмендә аерым композицияләр төзергә дә була. Мәсәлән, традицион кием кигән татар гаиләсе чәй эчеп утыра. Әйе, бу очракта башсыз манекеннар түгел, бәлки, балавыз сыннар кирәк булачак. Күргәзмә исә тагын да күбрәк тамашачыны җәлеп итәчәк – Дубайдагы шул тәртиптә эшли торган музей моңа иң шәп дәлил булып тора.

Сүз уңаеннан, бер ел элек, яңартылган татар костюмнарын Кабул итү урыннары бинасында беренче тапкыр күрсәткәндә, бик матур дефиле дә оештырылган – «Милли костюмнар театры» чыгыш ясаган иде. Шулчакта биредә театрлаштырылган тамашалар үткәрелде, туристлар өчен һәр көн иртә-кич милли костюмнар, милли мода тәкъдим ителде.

Мин кайчан да булса болар барысы да тормышка ашырылыр, дип ышанам. Милли киемдәге балавыз сыннардан композицияләр дә. Экспозициядәге яңартылган костюмнар янәшәсендә раритет милли костюмнар да. Театрлаштырылган тамашалар да, көндәлек иртәнге һәм кичке дефиле дә. Теләге булган һәркемгә татар милли киемен киеп карау һәм фотога төшү мөмкинлеге дә. Безнең милли киемнәребез моңа бик лаек бит!

# ҖӘЙГЕ КОЯШ ТОРГЫНЛЫГЫ КӨННӘРЕ

Александр Ефремов фотолары

**Милли киемле иң җете бәйрәм Якутиядә үткәрелә – Ысыах ул. Быел анда 235 мең кеше катнашкан. Ә бит Саха (Якутия) Республикасында нибары 1 миллион кеше яши (миллионынчысы – Саина исемле кыз быел 23 июньдә туган, һәм бу шатлыклы вакыйганы бөтен якут халкы бәйрәм иткән). Логистиканы да исәпкә алу мөһим: биредә бер районнан икенчесенә кадәр ара кайвакыт Казан белән Самара арасыннан да ераграк була. Шулай булса да, кояшны каршылау һәм аның энергиясен бер елга, озын һәм салкын кышка җитәрлек итеп туплап калу өчен, республика халкының яртысы диярлек, хәтта иң ерак һәм юлсыз районнардан да, кирәкле көн һәм сәгатькә бәйрәм итү урыны Ус Хатынга җыела.**

Биредә кояшны иң яхшы киемнән каршылыйлар, иң шәбе исә, әлбәттә, милли кием. Ысыахка якутлар алдан ук әзерләнә: иң шәп осталардан кием тектерә, бизәнү әйберләре сатып ала. Нәтиҗәдә купшы киемле якут ирләре, хатын-кызлары һәм балалары үзләренең матурлыгы белән кояштан гына калыша.

Бирегә төрле шәһәрләрдән килүче кунаклар әйтүенчә, бу көнне ирләр – принцка, Шарлотта Бронте романындагы Джейн Эйрныкы кебек эшләпәле хатын-кызлар исә Георг III патшалык иткән чордагы инглиз бикәләренә охшаган була.

Гәрчә бәйрәм ике көнгә сузылса да, эш бер Ысыах белән генә тәмамланмый әле. Кулыннан фотоаппарат-диктофонын төшермичә һәм аягын җәлләмичә әлеге бәйрәмне яктыртучылар,

бераз ял иткәннән соң, Якут матбугаты көне – 1 июльдә шәхси журналистлар Ысыахын уздыра. Һәм кояш бу көнне алар өчен тагын бер тапкыр чыга, әлбәттә.

Үзенең журналист коллегалары белән кояшны каршылау өчен «Татарстан» 4378 километр ара үтте. Бер уңайдан биредәге каләм әһелләренең шундый матур милли киемнәрне ничек уйлап табуы һәм тектерүе белән дә кызыксынырга булды. Чөнки безнең дә кайвакыт бер-ике көнгә генә булса да принцка яки Джейн Эйрга әвереләсе һәм үзебезне мәңгелек туңлыктан курыкмаучы һәм табигать белән бер телдә сөйләшүче бәхетле якут итеп тоясы килә бит – хәтта галимнәр дә аларның кояш нәселеннән булуын дәлилләгән әнә.

# МИЛЛИ МАТУРЛЫК СӘНГАТЕ

«Симэх» Халык гамәли сәнгате һәм һөнәрләре милли үзәгендә бөтен нәрсәне дә эшли беләләр: милли кием тегү, келәм туку, тукыма, күн, драптан – гомумән, теләсә нинди калдык-постыктан корама ясау... Җеп, шнур, мех, ат кылыннан – гомумән, теләсә нәрсәдән милли бизәкләр чигү... Курчак, шкатулка, сумка, янчык – гомумән, әллә ниләр ясау... Өстәвенә, башкаларны да боларны ясарга һәм аннары дөрес итеп кияргә дә өйрәтәләр әле.

## «КАЙЧЫ БЕЛӘН КАМЛАУЧЫ»

Саха (Якутия) Республикасының халык остасы Ульяна Миронова безгә үз эшләрен – кеш койрыгы, тиен түше, нәрсәнеңдер борыны кебек төрле мех кисәкләреннән тупланган «Кышкы төш» панносын, тотем хайваннар сурәтләнгән келәмнәрне күрсәтә, милли бизәк үзенчәлекләрен аңлата һәм безнең соклануны тоеп елмая... Мондый «мозаика»ны кеше акылы уйлап табуын һәм кеше кулы эшләвен тамашачылар күз алдына да китерә алмый. Әмма Ульяна шуңа да оста бит инде ул – осталыгы белән шаккатырырга тиеш.

– Бу сәнгать буыннан буынга, геннар буенча тапшырыла, – ди ул. – Безнең нәселдә барысы да оста куллы булган. Бабамның әтисе байлар өчен теккән. Элек безнең Якутиядә осталар шаманга тиңләнгән. Оста кулларны «кайчы белән камлаучы» дип йөрткәннәр. Аларны ихтирам иткәннәр, хөрмәтләгәннәр. Заказчыда айлар буе яшәп, алар бөтен гаилә өчен кием теккән. Без бу һөнәрдән башка яши алмыйбыз. Уйлап тапмыйча тора алмаганга, уйлап табабыз. Кул үзеннән-үзе шул эшкә тартыла, шундук башта образлар туа һәм бизәкләр ясала.

Кәләш, кияү йортына килгәндә, бирнә белән килергә тиеш булган, аңа үзенең киемнәре генә түгел, мехлар да, келәмнәр дә, өйне уңайлырак итәчәк төрле бизәкләр дә кергән. Бездә бик салкын булганга, өйне бизәү өчен дивар, идән, ишек келәмнәре – барысы да мехтан, хәтта урын-җир дә мехтан ясала, күз алдыгызга китерәсезме?

## ХАТЫН-КЫЗ ЧЫҢЛАП ТОРЫРГА ТИЕШ

– Хатын-кызның бизәнү әйберләре бик күп булырга тиеш – кияү йортына килгәндә, кәләштә ун килограммга кадәр алка-беләзек-муенса булган! – ди Саха (Якутия) Республикасының халык остасы Людмила Жиркова. – Хатын-кызны чыңлавыннан таныйлар, йөргәндә аның бизәнгечләре чыңлый һәм явыз рухларны куа.

Һәм оста үзенең милли стильдә эшләнгән кием коллекциясе белән хозурланырга чакыра, аларны эшкә дә, кешелеккә дә киеп була... Людмила Петровна үз күлмәкләрен, костюм һәм пальтоларын киеп йөри. Бигрәк тә бер пальтосына кызыктык.

– Мондый пальто белән атка да атланырга җайлы, аяк та җылыда, кулдан бияләйне дә тиз генә салып була, бөтен кирәкле әйбер (уймак, кайчы, көмеш таякчык) та һәрвакыт кул астында, – дип могҗизалы пальтоның бөтен мөмкинлекләрен күрсәтә безгә Людмила Петровна, шундый ук гаҗәеп башлыгы да бар икән әле.

Үз күзләребез белән күрсен өчен, «Симэх» галереясының халык осталары «Татарстан»га якут модасы күрсәтүне оештырды. «Татарстан» моңа фотосессия белән җавап бирде. Нәтиҗәсе – күз алдыгызда.

# ТАТАРСТАНГА СӘЛАМ!

Таныш булыгыз: Айталина һәм Дмитрий Петровлар – үрнәк якут гаиләсе. Ни өченме? Беренчедән, бик матурлар. Икенчедән, яшьләр. Өченчедән, күп балалы: ике яшьлек Мичийэ һәм биш айлык Нарыйа гына түгел әле аларның сабыйлары. Алардан зуррак өч уллары – Айаал, Айтал һәм Мичил, каникул булганга, авылдагы әбиләрендә кунакта икән.

Мондый гаиләләр – Якутиянең терәге һәм өмете: алар ватаннарын ярата, гореф-гадәтләрне санлап яши, балаларына ана телен өйрәтә һәм... Татарстанга сәлам юллый – анда Дмитрийның татар әбисе туган.

Айталина белән Дмитрий университетта, китапханәдә танышкан. Берсе – геология-разведка, икенчесе энергетика факультетында укыган. Бер-берсенә гашыйк булганнар һәм менә инде 13 ел бергә. Туйны якутча үткәргәннәр, шул вакыттан бирле гаиләдә бер традиция яши – һәр елны бөтен Петровларга осталардан яңа милли костюм тектерәләр. Дмитрий исә хәләленә милли бизәнү әйберләренең яңа комплектын бүләк итә.

Алар әле төрле конкурсларда да даими катнашалар. Күптән түгел республика күләмендә уздырыла торган «Якутиянең яшь гаиләсе» бәйгесендә җиңгәннәр һәм 300 мең сум акча отканнар.

Петровларга Якутиядә яшәү ошый, кайвакыт, 54 градуска кадәр суыткач кына, җылы якка күченәселәре килеп китә. Әмма мондый суыклар, аңа бәйле уйлар еш булмый. Һәм Петровлар җылы якка ялга барсалар да, бер атнадан ук өйләрен, табигатьләрен һәм мәңгелек тунлыкны сагына башлыйлар. Туган як шундый инде ул – үзенекеләрне беркая да җибәрәсе килми.





ДӨНЬЯДА ИҢ ШӘП УРЫН

Фото: Алсу Шакирова

# ЯҢА ЧИШМӘ: КЫРЫКТА ТОРМЫШ БАШЛАНА ГЫНА ӘЛЕ!

Быел Яңа Чишмә районына 40 ел тулды. Республикабызның иң яшь районнарыннан берсе ул. Хорафатларга ышанучан кешеләр мондый юбилейны билгеләмәскә өндәсә дә, күпчелек, 40 та гомер әле башлана гына, дип саный! Кемнең хаклы булуын ачыклар өчен, район башлыгы Вячеслав Козлов янына кунакка барабыз.

## АБОРИГЕННАРҺӘРВАКЫТ ӘЙЛӘНЕП КАЙТА

– Мин районның аборигены, – ди Вячеслав Михайлович. – Биредә тудым, гомерем буе биредә яшим һәм эшлим һәм беркая да китәргә җыенмыйм. Шунлыктан район оешуга бәйле бөтен хәлләр минем күз алдымда булды, мин әлеге процесста турыдан-туры катнаштым.

Тик мин туганда һәм укыганда Яңа Чишмә Чистай районына керә иде әле. Чөнки 1963 елда аны таркатып, территориясен Әлмәт һәм Чистай районнарына куштылар. Әмма үзәктән ерак булу үсешкә комачаулый, район һаман хәерчеләнә бара, халык сәнәгать гөрләп үскән, эш һәм инфраструктура, яхшырак яшәү шартлары булган Әлмәт, Түбән Камага күченеп китә иде. Һәм үз районнары өчен җаннары әрнегән җитәкчеләр төркеме аның кабат торгызылуына иреште – 1983 елның 26 апрелендә РСФСР Югары Советы карары белән Яңа Чишмә районы мөстәкыйль административ-территориаль берәмлек дип игълан ителде. Әгәр ул чакта район оештырылмаган булса, хәзерге торак пунктларның яртысы картадан юкка чыгар иде инде. Алар болай да күп түгел. Хәзер бездә 15 авыл җирлеге исәпләнә, алар 30 торак пунктны берләштерә, барлыгы 14 меңгә якын кеше яши. Ә революциягә кадәр, мәсәлән, бу территориядә 54 мең кеше яшәгән.

## БЕР ҮК СУГА – ИКЕ ТАПКЫР

Районны аякка бастыруда күп кеше катнаша. Ул чакта Министрлар Кабинеты Рәисе булган Минтимер Шәймиев җитәкләгән оештыру комитеты төзелә. Татарстанның бөтен районы булыша – йортлар, юллар салалар, инфраструктура булдыралар...

Районның беренче җитәкчесе булган Алексей Николаевич Козлов инде мәрхүм. Аннары Гариф Хафизов, Виталий Макаров, Рөстәм Хамматов, тагын Виталий Макаров, Николай Владимиров, Александр Губкин җитәкчелек итте...

Шулай килеп чыкты ки, мин районда ике тапкыр җитәкче булдым, шул арада 10 ел Чистайда эшләп алдым. 2010 елда туган Яңа Чишмәмә кабат әйләнеп кайттым һәм рәхәтләнеп хезмәт куям.

## ГАДИ АВЫЛ ИДЕ...

– Район торгызылган мәлдә хуҗалыкларны, оешмаларны җитәкләүчеләргә мин бик рәхмәтле. Ул чакта гади бер авыл иде бит Яңа Чишмә. Ашханәләр дә, кунакханәләр дә, тамак ялгар урыннар да юк. Ашагыз әйдә, – дип бөккән белән сыйлый безне Вячеслав Михайлович. – Мондый тәмле бөккәннәрне сез шәһәрдә беркайда да таба алмыйсыз. Бездә генә шулай тәмле пешерәләр.

1

Район башлыгы «Татарстан» делегациясен машинасына төяде дә экскурсиягә алып китте.

2

– Хәзер бу пионер лагере. Биредә Әлки, Алексеевск, Спас, Нурлат районнары малайлары җәй буе яши.

Һәм, бөккәннәрнең «Татарстан» вәкилләре күңеленә хуш килүен күреп, дәвам итә:

– Яңа Чишмә район үзәгенә әйләнгәч, анда партия өлкә комитетының беренче секретаре Гомәр Усманов катнашында министрлык киңәшмәләре дә үткәрелә башлады. Кунак сөючән яңачишмәлеләр килүчеләрне кунарга өйләренә алып китә иде – ә кунаклар арасында ТАССР Министрлар Советы Рәисенең беренче урынбасары Шәймиев тә, Премьер-министр Сабиров та, КПСС өлкә комитеты, Авыл хуҗалыгы министрлыгы хезмәткәрләре дә булгалый...

Бүген бу хәлләр инде әллә кайчан булгандай тоела, тик нибары кырык ел гына үтте бит әле. Хәзер район территориясендә нефть чыгарыла – җиде нефть компаниясе елына 1 миллион 300 мең тоннадан артык кара алтын суырта. Авыл хуҗалыгы нигездә ике зур агрофирмадан гыйбарәт: 27 мең гектардан артык җир эшкәртә торган «Агро-Раздолье» ҖЧҖ һәм «Агро-Основа» ҖЧҖ. Крестьян һәм фермер хуҗалыклары да алардан калышмый...

## ОЧАРГА РӨХСӘТ ИТМӘДЕЛӘР

Район башлыгы «Татарстан» делегациясен машинасына төяде дә, экскурсиягә алып китте. Татарстан районнары өчен инде гадәтигә әйләнгән инфраструктураны карап йөрибез: йөзү бассейны, сәнгать мәктәбе, балалар иҗаты йорты, парк...

– Сүз уңаеннан, безнең бассейн инде 2012 елдан бирле эшли, – дип искәртә Вячеслав Михайлович. – Ул чакта әле шәһәрләрдә дә мондый бассейннар юк иде! Әмма яшьләр барыбер элеккечә үк авылдан китү ягын каера. Ел саен мәктәпне тәмамлаучы 400 дән артыграк егет-кыз югары уку йортларына укырга китә, шулардан нибары 5-7се генә авылга кире кайта...

Кайчандыр мин үзем дә китмәкче идем. Төгәлрәге, очмакчы идем. Мәктәптә дустым белән хәрби очучы булырга хыялландык. Һәм булыр да идек. Әмма язмыш башкача хәл итте. Ул заманда колхоз рәисе рөхсәтеннән башка һәм паспортсыз авылдан китеп булмый иде, бигрәк тә эти-әниең колхозда эшләсә. Гәрчә крепостнойлык 1861 елда ук бетерелсә дә, – дип көлә башлык. – Без Чистай военкоматы аша документларыбызны Рязань очучылар училищесына бирдек, сөйләшү үттек. Мәктәптә яхшы укыдык, имтиханнарны һичшиксез бирер идек, сәламәтлек тә яхшы, тик... Колхоз рәисе Поли-

карпов мине әти-әнием белән авыл советына чакырды һәм мин училищега җибәргән бөтен документларымны кире бирде. Ул партиянең район комитеты бюросы әгъзасы һәм болай эшләргә вәкаләтле иде.

Һәм мин колхоз юлламасы белән Чистай авыл хуҗалыгы техникумына киттем. Аннары армия, авыл хуҗалыгы институты. Колхозда эшләдем, аннары чиновник булдым.

## АВЫЛ БЕЛӘН ШӘҺӘР АРАСЫНДА

**– Ә сез шулай булдыра алыр идегезме? Хәрби очучы булырга җыенучыларның канатларын кисәр идегезме?**

– Бу турыда беркайчан да уйланганым булмады. Хыял тормышка ашарга тиеш, дип саныйм. Әмма хәзер заманы башка. Бүген студентлар белән очрашабыз – аларның 80 проценты сайланган белгечлеге буенча эшләми. Ә ни өчен? Чөнки кемдер югары уку йортын дустына ияреп кенә сайлый, кемдер БДИдан курка, кайвакыт исә ата-ана үзе мәҗбүр итә – безнең язмышны кабатлама, шәһәргә кит, анда мөмкинлекләр күбрәк, ди. Әле бит соңгы 8-10 елда гына республикада төзекләндерүгә, яшьләрнең ялын оештыруга, авылда шартлар тудыруга игътибар бирелә башлады. Кызганыч ки, элек болай булмады. Авыл белән шәһәр арасында аерма бик зур иде. Һәм бүген Рөстәм Нургали улы Миңнеханов әлеге аерманы юкка чыгару өчен гаять зур тырышлык куя – һәр районда халыкның тормышын яхшыртырлык бөтен нәрсә төзелә, шәһәргә китәсе килмәслек булсын өчен бөтен шартлар тудырыла.

Үзеңә тиң парны табу да бик мөһим. Бездә югары белем алганнан соң эшләүче уңган кызлар күп иде, әмма парларын таба алмадылар. Чаллыга киткәннәр иде – тиз арада гаилә корып, шунда калдылар да. Билгеле, шәһәрләрдә кияүләр дә, эш урыннары да авылдагыдан күбрәк.

## ИРЕК СӨЮЧӘН ХАЛЫК ВАТАНЫ БУ

– Гәрчә мин үзебезнең кияүләрне яхшырак, дип саныйм, – дип елмая башлык. – Һәм гомумән, яңачишмәлеләр үзгә халык. Тарихка күз салсак, безнең район территориясендә беркайчан да крепостной хокук булмаган. XVII гасырда биредә бистәләр барлыкка килгән, анда патша кешеләре – Русь дәүлә-

КҮЗ САЛ: СИН ЯШӘГӘН ДӨНЬЯ НИЧЕК МАТУР!

3

Үзеңә тиң парны табу да бик мөһим.

4

– Сүз уңаеннан, безнең бассейн инде 2012 елдан бирле эшли, – дип искәртә Вячеслав Михайлович. – Ул чакта әле шәһәрләрдә дә мондый бассейннар юк иде!

те чикләрен саклаучылар яшәгән. Аларга җир бик юмарт бирелгән, салымнан исә азат ителгәннәр. Аучылык, игенчелек, терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр, Чишмә елгасында балык тотканнар. Бигрәк тә чуртан дан казанган – аны патша табынына илтә торган булганнар. Чуртан балыгы бүген дә Яңа Чишмә гербын бизәп тора.

Биредә алып гәүдәле, үтә тәвәккәл, туры сүзле, гаделлек сөюче – бер сүз белән әйткәндә, ирек сөючән кешеләр яшәгән. Алар бүген дә шундый. Алар яшәгән урыннар да шул ук – бистәләр. Тарихи атамалары да сакланып калган – Слобода Архангельская, Екатерининская, Волчья, Петропавловская, Черёмуховая... Революциягә кадәр әлеге бистәләрдә 5900 кеше гомер кичергән. Һәркайсында зур чиркәү төзелгән, гыйбадәткә халык күп йөргән.

Һәр бистәнең үз мәдәнияте, үз гореф-гадәтләре, үз бәйрәмнәре бар. Хәзер без бу бәйрәмнәрне яңартабыз – аларны һәр бистәдә үткәрәбез.

## КӨЧ ТУПЛАУ УРЫНЫ

Вячеслав Михайлович безне үзенең яраткан урыны – Поп урманына алып китте.

– Хәзер бу Сабан туе урыны. Һәм пионер лагере. Биредә Әлки, Алексеевск, Спас, Нурлат районнары малайлары җәй буе яши. Бу – авыр тормыш халәтенә юлыккан балалар. Шаяннар, тәртип бозарга яратучылар, – дип елмая экскурсия үткәрүчебез. – Алар өчен биредә ел саен хәрби-кыр җыены үткәрелә. Монда алар тынычлана – искиткеч урын бу, сандугачлар сайрый, черки дә юк.

Җанымны ял иттерергә, сандугач сайравын тыңларга бу гүзәл урынга мин үзем дә еш килəм.

## БАШЛЫКНЫ НИ БОРЧЫЙ?

**– Сез инде районны күп еллар буе җитәклисез. Башлык булу авырмы?**

– Төрлесе була инде. Халыкка бишәр ай буе хезмәт хакы түли алмаган чаклар да булды. Эш хакын киез итек белән дә, аракы белән дә, ашлык белән бирергә туры килде ул вакытта. Ликер-аракы заводының бюджетта үз өлеше бар иде – аны аракы белән алып, үзебез саттык һәм халыкка акча бирдек.

Һәрбер чорның үз үзенчәлеге бар. Элек башлыкның вәкаләтләре күбрәк иде. Хәзер күпкә азрак, һәм бу кыенлыклар да тудыргалый.

Иң катлаулысы – булышырга теләп тә бернишли алмау, кул бәйле булу – бу үз эшеңнән канәгатьсезлек хисе тудыра.

Муниципаль хакимият халыкка якынрак ул. Без биек таш койма артына яшеренмибез, безне полиция дә сакламый. Без янәшәдә, кул сузымында гына.

Үземнең чиновниклык гомеремдә мин сәяси строй алмашынуны да, Россия һәм республика җитәкчелеге алышынуны да күрдем – чагыштырыр нәрсәләрем күп. Мин изге түгел, тик мин биредә яшим, районымны һәм аның халкын яратам.

Һәм моннан беркая да китмәячәкмен. Пенсиягә чыкач та. Шәһәр ыгы-зыгысын яратмыйм. Минем балаларым, оныкларым, яшелчә бакчам бар... Җәмәгатем белән 200 төп помидор, 80 төп кыяр утыртабыз.

Суган, кәбестә, бәрәңге, тавыклар – барысы да үзебезнеке, бернәрсәне дә сатып алмыйбыз.

## ҖИРСҮ ХИСЕ

Беләсезме, дөнья читенә китеп, йөз тапкыр яхшырак, баерак, күңеллерәк яшәп булыр иде... Әмма шундый бер хис бар – кече ватанга тартылу, җирсү тойгысы. Ул барыбер җиңәчәк һәм гомерең буе туган якка тартып торачак.

Мин сезгә юкка чыккан бер авыл хакында сөйлим хәзер. Революциядән соң ук Яңа Чишмә территориясеннән 13 авыл бөтенләй юкка чыккан. Зорька авылы урынында бер каен үсә. Шул авылдан чыгучылар тәкъдиме белән, аның янына хач куелды. Ел саен шул каен янына Дондагы Ростовтан, Тольяттидан, башка җирләрдән сагынып кайтучылар шактый... Бервакыт ике ир-ат кайтты. Аларның йорты шул каен янында булган. Каенны кочаклап елыйлар гына бит. Ихластан. Җирсү хисе менә шул була инде ул.

## АЛТЫН АЧКЫЧ

Ностальгия кәефе балалар бакчасына кергәч шундук юкка чыкты. Бу бик матур, пөхтә, затлы бакчада сабыйлар күп – димәк, Яңа Чишмәдә яңа буынның киләчәге өметле әле. Мондый бакчадагы экияттәгедәй балачактан соң алар үз сабыйларын башка җиргә алып китәргә теләмәстер мөгаен. Инде мәктәпкә киткән һәм хатасыз диярлек язарга өйрәнгән балалар интернетта үзләренең бакчасын мактап туялмый:

*«Минем бакчам. Тәрбиячеләр бик яхшы иде».*

*«Мин дә анда эшләячәкмен».*

*«Бакчадагы кебек ботка ашыйсым килә».*

«Алтын ачкыч»тан ата-аналар да бик канәгать:

*«Европадагы кебек. Бөтен нәрсә яңа. Иминлек иң югары дәрәҗәдә».*

*«Иң шәп бакчалардан берсе!»*

Безнең үзебезнең дә әлеге балалар бакчасында каласыбыз килде, әмма караватлары гына кечкенәрәк – сыймабыз дип курыктык.

5 Безнең үзебезнең дә әлеге балалар бакчасында каласыбыз килде, әмма караватлары гына кечкенәрәк – сыймабыз дип курыктык.

6 Бакчадагы уңайлылык һәм гүзәллек өчен мөдир Любовь Васильевна Михеева җаваплы.

7 «Алтын ачкыч» бакчасында булачак ЮХИДИ инспекторлары тәрбияләнә.

8 – Татарстанда яшисең – «Татарстан»ны укы!

# МӘСКӘҮ ХАЛКЫН ЯБЫКТЫРУ УРЫНЫ

Николай Крушинин

MINGER
MED SPA

«МиңгәрМед» ҖЧҖ баш табибы Светлана Хәйруллина бик гади нәрсәнең дә ни өчен катлаулы булып тоелуы һәм, бер кешегә ярдәм итеп, халыкның аңын глобаль үзгәртү хакында фикер йөртә.

«Ябыгыр өчен нәрсә ашарга икән?» – дип шаяртырга маташа ябыгучы татарстанлылар. Ә менә мәскәүләр бу сорауга җавапны күптән белә инде, шуңа күрә сыйлану һәм ябыгыр өчен Миңгәргә килә. Андагы махсус детокс-программа организмны чистарту аша тиз арада көтелгән нәтиҗәгә ирешү мөмкинлеген бирә.

## ОРГАНИЗМГА АШЫГЫЧ ЯРДӘМ

**– Светлана Геннадиевна, организмны ничә көндә чистартып була?**

– Сигез көндә. Нәкъ менә шул вакыт эчендә без беренче нәтиҗәләрне күрә алабыз. Безнең организм – сәгать кебек төгәл эшли һәм үзеннән-үзе чистара торган уникаль система ул. Аңа комачауламаган очракта. Әмма без комачаулыйбыз. Ни өчен? Чөнки яшәгән дөньябыз да, үзебез дә идеаль түгел. Экология, дөрес тукланмау, даими хәрәкәт булмау, зыянлы гадәтләр, стресслар һәм башка күп нәрсә эчке системалар эшендәге балансны юкка чыгара, шунлыктан иммунитет зәгыйфьләнә, хроник чирләр, артык авырлык барлыкка килә. Организмга үзендә тупланган зыянлы матдәләрдән котылу һәм чистарту процессларын активлаштыруда аеруча куркынычсыз ысуллар белән ярдәм итәргә кирәк.

Детоксны организмга ашыгыч ярдәм дип атап була – кыска вакытлы комплекслы тәэсир итү бик яхшы нәтиҗә бирә.

Ач торганда, эчәклек экстремаль чистартыла һәм хроник чирләр кискенләшә, организмда аксымнар, макро- һәм микроэлементлар кытлыгы башлана. Ә безнең детокс-программа ач тору түгел ул. Без организмны чистарту процессында катнаша торган барлык әгъзалар һәм системаларга – бавыр, бөер, эчәклек, үпкә, кан, лимфа һәм тирегә – комплекслы тәэсир итәбез.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



## БӨТЕН КАТЛАУЛЫ НӘРСӘ – ГАДИ

**– Сигез көндә генә барлык бу әгъзаларга ни рәвешле тәэсир итеп була?**

– Чынлап та, бөтен катлаулы нәрсә бик гади бит ул. Бары тик:

– балансланган туклану системасын булдырырга (режим; аксымнар, майлар һәм углеводларның дөрес нисбәтен саклау; гади углеводлар, трансмайлар, төрле чит катнашмалардан арындырылган продуктлар, лактоза һәм глютен кулланмау);

– физик яктан актив булырга кирәк, чөнки бу кан әйләнешен яхшырта һәм барлык әгъзаларга йогынты ясый.

Әлбәттә, алда санап кителгәннәрнең барысын да өйдә мөстәкыйль эшләп тә була. Әмма балансланган туклану системасын, кешенең үзенчәлекләрен, хезмәт тәртибен, яшәү рәвешен исәпкә алып, табиб төзеп бирергә тиеш.

Әлеге балансланган тукылануга һәм физик йөкләмәләргә без чистарту процессында катнашучы әгъза һәм системалар эшен яхшырта торган дәва процедураларын да өстибез. Мәсәлән, үт чыгару юлларын дуоденаль зонд ярдәмендә чистартабыз...

**–...Бигрәк куркыныч яңгырый.**

– Чынлыкта исә әлеге процедураны үткәрү зарур. Үт чыгару юлларын киңәйтү һәм үт бүленүне яхшырту өчен, кунакка дуоденаль зонд аша дару препаратлары, ялкынсынуга һәм паразитларга каршы торуны тәэмин итә торган үлән төнәтмәләре кертелә. Процедура сорбент эчү һәм үлән төнәтмәле клизма белән тәмамлана.

Спелеокамера безгә үпкәне дә комплекслы чистарыну системасына кертергә булыша, ә аппарат методларының тулы бер комплексы лимфа, кан һәм бөерләрне чистартуны башлый. Бу виброкомпрессион йогынты да, прессотерапия дә, бәрмә дулкын тәэсире дә, мускулларны магнит белән стимуллаштыру да.

Нәтиҗәне тагын да яхшырту өчен, IV-терапияне кушабыз: венага гепатопротекторлар, антиоксидантлар, углеводлар һәм липидлар алмашына йогынты ясаучы препаратлар кадыйбыз, алар детокс программасын көчәйтә.

**– Ә бик рәхәт нәрсәләр дә бармы соң?**

– Барысы да бик рәхәт бездә: җирле фермерлар продуктларыннан тәмле һәм файдалы ризык, тәнне заманча аппаратлар белән коррекцияләү, тирене яхшырта торган СПА-процедуралар.



«МиңгәрМед»ҖЧҖ фотолары. РЕКЛАМА

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА



**Безнең кыска вакытлы бурычыбыз авырлыкны киметү булса, глобаль бурычыбыз – кешеләрнең аңына тәэсир итү, дөрес гадәтләр формалаштыру.**

## ДЕТОКС һӘМ...

**– Детокс программасы ябыгу өчен генә кулланыламы?**

– «МиңгәрМедСПА»да «Детокс һәм ябыгу», «Детокс һәм хатын-кызлар сәламәтлеге», «Детокс һәм ир-атлар сәламәтлеге» программалары гамәлдә. Якын арада «Детокс һәм сәламәт йөрәк», көзгә таба «Детокс һәм сәламәт иммунитет», ел азагына «Детокс һәм сәламәт арка», «Детокс һәм сәламәт буыннар» программалары эшләп китәчәк. Әлеге программаларның һәркайсының нигезендә комплекслы детокс ята: дөрес туклану, физик активлык. Программаның мәҗбүри өлеше – лаборатория диагностикасы – 50 дән артык күрсәткечне үз эченә ала: әгъзалар һәм системаларны ультратавыш белән тикшерүдән, биоэмпиданс спектрометриядән, ЭКГ һәм артериаль кан басымын тәүлеклек мониторинглаудан, аппаратларда дәвалаудан гыйбарәт инструменталь диагностика да, дару препаратларын венага салу да кирә монда. Һәм, әлбәттә инде, СПА-процедуралар.

## КЫСКА ВАКЫТЛЫДАН – ГЛОБАЛЬ БУРЫЧКА

**– Табиб күзәтүендә сигез көнлек чистарыну процессы тәмамлангач, нишләргә? Файдалы гадәтләрдән кире зыянлыларына ничек әйләнеп кайтмаска? Программа узганнан соңгы нәтиҗәне ничек сакларга?**

– Безнең кыска вакытлы бурычыбыз авырлыкны киметү булса, глобаль бурычыбыз – кешеләрнең аңына тәэсир итү, дөрес гадәтләр формалаштыру. Кеше өенә яңарып, яшәреп кенә кайтмый, ул һәркем өчен үрнәккә дә әйләнә: үз организмыңа ярдәм итсәң, менә нинди нәтиҗәгә ирешү мөмкин. Дөрес яшәү рәвеше менә шундый эффектка ия. Формалашкан яңа гадәтләр аларның гаиләсенә, балалары һәм оныкларына да йогынты ясаячак. Димәк, сәламәт кешеләр күбрәк булачак.

### КЕМГӘ ЗАРАРЛЫ?

Балансланган туклану системасыннан тыш, детокс – организм өчен үзенчәлекле стресс та ул. Шунлыктан, сәламәтлеккә зыян китермәс өчен, мондый программа үтү тыелган кешеләр дә бар:

– йөклелек һәм имезү чоры;
– артык ябыклык;
– хроник чирләр кискенләшү чоры яки каты авырудан соң тернәкләнү чоры;
– 18 яше тулмаганнар;
– 70 яшьтән өлкәнрәкләр.

Чистарыну программалары белгеч күзәтүендә генә үткәрелә. Һәм теләсә нинди тайпылышлар – мәсәлән, баш әйләнү, йокысызлык, ашкайнатудагы проблемалар турында шундук табибка әйтергә кирәк. Ул моның сәбәбен табачак һәм йә программаны үзгәртеп көйләячәк, йә туктатачак.

ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

Үсеп килүче буынга үзеңнең шәхси мисалың белән генә йогынты ясап була – бу бәхәссез факт.

Сүз дә юк, гадәт формалашу процессы күпмедер вакыт таләп итә. Шунлыктан без башлангыч этапта детокс курсын 3-6 айга бер тапкыр үтәргә киңәш итәбез. Кирәкле нәтиҗәгә ирешкәч, елына бер тапкыр да җитәчәк.

## НИ ӨЧЕН МИҢГӘР?

**– Ни өчен мәскәүләр Миңгәрне сайлый? Аларның якын-тирәсендә дә моңа охшаш отель һәм хезмәтләр бар бит...**

– Ихтимал, шуңадыр – Миңгәр бик матур бит: 2000 гектар ылыслы урман, 15 күл. Мондый гүзәл мохиттә дөрес гадәтләрне формалаштыру гадирәк тә, рәхәтрәк тә. Миңгәр – югары дәрәҗә ул: биш йолдызлы уникаль медицина СПА-комплексы. Биредә сервис күрсәтү сыйфаты һәм ресторандагы менюдан алып бүлмәләрнең дизайнына кадәр барысы да иң югары дәрәҗәдә. Ә безнең детокс-программалар исә киләчәктәге сыйфатлы һәм тулы канлы тормышны гарантияли. Үз сәламәтлеген кайгыртучылар иң шәп җирне сайлый инде. Ⓣ



ИМЕЮТСЯ ПРОТИВОПОКАЗАНИЯ. НЕОБХОДИМА КОНСУЛЬТАЦИЯ СПЕЦИАЛИСТА

# БӘРӘҢГЕНЕ ҖЫРЛАП ӨЯЛӘР!

Руфия Фазылова

Халкыбызның телен әйтәм, бигрәк матур һәм төрле. Менә бәрәңгене генә алыйк: аны өяләр, яралар, күтәрәләр... Эш кораллары да төрле бит: кул сукасы, ат сукасы, китмән... Һәм болар барысы да бәрәңге төбен туфрак белән күмү өчен кирәк.

Бүген менә шул иске яңа шөгыль турында сөйләшергә булдык.

## ЧЫБЫРКЫ НИГӘ КИРӘК?

Һаман да кул сукасы белән эш иткән яклар бар. Лаеш районының кайбер авылларында хатын-кызлар үзләре бәрәңгене шулай күтәрә икән: икесе алдан тартып бара, артка янә бер кеше баса. Питрәч районының Шәле авылында да әлеге борынгы шөгыльне онытмаганнар булып чыкты. Биредә яшәүче Зәйтүнә апа Гыйльмиева безне кул сукасы белән эшләргә дә өйрәтте, аның кызыклы тарихын да сөйләде.

Тимер суканы ничек хатын-кызлар сөйрәп йөри икән дип аптыраган идек, ул авыр түгел икән. Аның белән бер генә хатын-кыз да эшли ала. Тик суканы алдан тартып баручы булса җайлырак.

Иң беренче эш коралы турында сорашабыз:

– Бу күрше Әмир абый ясаган сука, – диде Зәйтүнә апа. – Ул бик оста тимерче иде, мәрхүм булды инде.

Әмир абый мондый сукаларны күп ясаган. Үзе дә шундый эш коралы белән эшләп үскәнгә, аның бөтен нечкәлекләрен белгән. Кул сукасы атныкыннан кечкенәлеге белән генә аерыла: шулай ук ике яклап тотасың, уртада ергычы бар. Сука башына беркетеп куелган кечкенә чыбыркы игътибарны җәлеп итте.

– Ә бу ни өчен кирәк? – дибез.

– Алдан барган кеше тизлекне арттырсын өчен, – дип көлде Зәйтүнә апа.– Бу чыбыркыга йөз ел бар инде, бабайлардан калган. Күргәнебезчә, кыска ул, кул сукасында шулай йөргән.

– Чынлап та алдан барган кешегә суккан-нармы? – дибез гаҗәпләнеп.

Фото: Илмир Хәбибуллин

– Юктыр инде. Фасон өчен генә куелгандыр. Ә бәлки сугып та куйганнардыр, кем белгән. Элек бит һәр өйдә тал чыбыгы да торган. Тыңламаган балаларга хәзер берне тамызып алганнар. Шулай булгач бик мөмкин. Сука белән бәрәңгене утыртып, өеп була. Бик җайлы эш коралы ул. Мактанып әйтмим, мин аны үзем генә дә башкарам.

## «ӘТИНЕ КАРЫЙБЫЗ...»

Зәйтүнә апа арттырмый: бәрәңге сызарга, тагын әллә ниләр эшләргә мөмкин ул. Алтмыш биш яшь дигәч, аптырап киткән идек. Яшәү дәрте ташып тора торган ханымга үз яшен биреп булмый. Кырык елдан артык җәмәгать туклану системасында хезмәт иткән: гади пешекчедән башлап хуҗалык эшләре мөдире, ашханә җитәкчесенә кадәр үскән. Соңгы җиде елын туган авылы Шәледә яшиләр икән.

– Әтиебезгә сигез айдан 100 яшь тула, – диде Зәйтүнә апа. – Бөек Ватан сугышы ветераны ул. Әни күптән вафат инде. Әти ялгызы яши алмый башлагач, хәләл җефетем белән күченеп кайттык. Аллаһка шөкер, әти үз аягында, тик быел урамга чыгып йөрми инде. Картайды. Бу төп нигезебез. Җәен әнә шулай бакча үстерәбез, рәхәт. Менә кышларны авыррак кичерәм – шәһәр ыгы-зыгысы җитми миңа.

Өйдә генә тормас өчен, Зәйтүнә апа җанына шифа тапкан – Шәленең «Зөбәрҗәт» халык фольклор ансамбленә йөри. Репетицияләргә барырга ашкынып тора. Ансамбль белән кайларда гына чыгыш ясамаганнар!

– Гомерем буе артист булырга хыялландым, – ди хуҗабикә. – Җыр-моңны, шигърияне яратам. Тугызынчы сыйныфтан соң Казан театр училищесына укырга да кереп кайткан идем, әти рөхсәт итмәде. Аның сүзенә каршы килмәдем...

Зәйтүнә апа бәрәңгене дә җырлап кына сызды. Ике яктан суканы тотты да шаулап үсеп утырган бәрәңге буразнасы арасына кереп китте. Бер кат шулай күтәргән булган инде. Безгә күрсәтер өчен Зәйтүнә апа янә кулына сука алды.

Инде әйтелгәнчә, сука белән эш иткәндә өч яки ике кеше булса җайлырак. Алдан тартып барсалар, арттагы кешегә җиңелрәк икән. Шуның өчен дә Зәйтүнә апа кызларны алга бастырды. Суканың ергычы янына ике аркан бәйләнгән. Әнә шул арканнардан тартып барасың икән.

Читтән карап торырга бик күңелле! Иң мөһиме – тиз. Ярты сәгать дигәндә биш сутый бәрәңге бакчасын сызып чыктылар. (Мисал өчен, безнең Апас якларында әле дә бәрәңгене китмән белән күтәрәләр. Бер генә кеше булса, әллә ничә көнгә сузыла торган эш.)

– Бик рәхәт булды сезнең белән, – дип көлде Зәйтүнә апа. – Балачакка кайтып килдем. Әнә шулай бертуганнарым белән бәрәңге сыза идек. Сука бөтен кешедә булмый – йорттан йортка йөрде. Хуҗа кешедән алдан ук сорап куясың. Ул чакта бәрәңге күп утырта иде халык. Хәзер генә берничә сутыйга калды. Без дә хәзер бакчага күп итеп кабак чәчәбез. Кыш буе ашыйбыз, кош-кортларга бирергә дә яхшы.

...Шәле – республикабызның иң зур авылларыннан берсе. Казаннан кырык чакрым ераклыкта урнашкан. Аның уңган халкы турында казанлылар яхшы белә – Шәле халкы гомергә катык, сөт, корт, яшелчә, ит сатарга шәһәргә килгән. (Зәйтүнә апаның мәрхүм әнисе дә җитмеш яшенә кадәр шулай Казан юлын таптаган.) Бүген дә халык зур тырышлык белән яши бирәдә. Мал да тоталар, яшелчәсен дә үстерәләр. Тик аннан бигрәк, Шәленең яңа урамнары, ике катлы йортлары сокландырды безне. Кайчандыр бәрәңге бакчалары булган кырда бүген берсеннән-берсе матур йортлар калкып чыккан. Казан якын булгач, шәһәргә йөреп эшләүчеләр күп икән. Үз эшләрен башлаучылар да байтак. Ни әйтсәң дә, мондагы халыкның тырышлыгы канда шул...

Язманың видеоварианты да бар.

Гаилә көнә

# «ТАТАР БЕРКАЙЧАН ҮЗ МИЛЛӘТЕН ЯШЕРМИ!»

Руфия Фазылова

Тынгысыз кешеләр була, Миләүшә Хафизовна шундыйлардан. Бер сәгатьлек әңгәмә барышында әллә ничә тапкыр телефоны шалтырады. Кемгәдер хастаханә белән проблеманы хәл итәргә кирәк, икенчеләрдә бүтән гозер. Туганнары, дуслары гына түгел, танышларның танышлары да мөрәҗәгать итә икән. Һәм иң кызыгы – Миләүшә Хафизовна һәркайсын тыңлый, матур итеп җавап бирә. Бүгенге ыгы-зыгылы заманда бөтен кешегә ярдәм итәргә вакыт, энергия кайдан ала соң ул? Бу сорауга аның үз фәлсәфәсе: «Әби әйтә иде: «Кызым, Аллаһы Тәгалә башкаларга ярдәм итә алу мөмкинлеген бөтен кешегә дә бирми. Иң бәхетле, иң яраткан бәндәсенә генә андый мөмкинлек тудыра». Шуның өчен исәнлек, көч булганда, ярдәм итәргә язсын...»

Гаилә көне алдыннан «Бөтенроссия татар гаиләсе» фонды директоры, югары категорияле табибә, РФнең сәламәтлек саклау отличнигы, Республика тире-венерология авырулары диспансерының бүлек мөдире Гайфуллина Миләүшә Хафиз кызы белән очрашып, милли дә, тормышчан да әңгәмә кордык.

Фото: Александр Ефремов

**– Миләүшә ханым, сүзне гаиләгездән башлыйсы килә. Сез табиблар династиясе дисәм дөрес булыр. Хәләл җефетегез, улыгыз, кызыгыз да табиб. Гаиләдә татарча аралашасыз дип беләм. Балаларны ана телендә сөйләштерү авыр булдымы?**

– Авыр булмады. Өйдә татар мохите иде: хәләл җефетем Нурислам белән өйдә бары тик татарча сөйләштек. Әнием татар теле һәм әдәбияты укытучысы, ана теленә мәхәббәт, хөрмәтне ул тәрбияләгәндер. Кечкенәдән шигырьләр ятлата иде. Хәзер дә ятлыйм: чыгышларымда җаена туры китереп гел шигырь сөйлим.

Чистай районының Татар Сарсазы авылы кызы мин. Бик абруйлы гаиләдә үстем. Әби дә безнең белән яшәде. Әбием коммунистлар заманында да диндә булды: өчәр ай ураза тота, Коръән тутыра иде. Әти колхоз рәисе, әни укытучы булса да (икесе дә коммунист бит), бисмилла әйтмичә, ашарга утырмадылар. Төп йорт булгач, җыелышып туганнар кайта иде. Кыскасы, чын татар гаиләсе иде безнең. Ә мин исә шул кыйммәтләрне балаларга сеңдерергә тырыштым. Безнең балалар рус мәктәбендә белем алды. Ләкин татарча камил белүләренә бу берничек тә комачауламады.

Балаларда милләтенә карата хөрмәт тәрбияләргә кирәк. Безнең белән күрше булып яшәүче кайбер милләтләр арасында үзләренең чыгышларыннан оялучылар очрый. «Татар гаиләсе» фонды җитәкчесе буларак, күп җирләрдә булырга, төрле гаиләләр белән аралашырга туры килә. Үзләренең милләтен яшергән гаиләләрне күреп кызганам. Ә менә безнең татар халкы беркайчан үз милләтен яшерми. «Мин татар, тик телне белмим шул», – дип үкенеч белән әйтәләр.

**– Сезнең кебек гади авыл баласына абруйлы КДМИга укырга керү, анда белем алу өчен зур киртәләр узарга туры килдеме?**

– Авыр булды дип әйтә алмыйм. Безнең төркемдә барысы да диярлек авыл баласы иде, белем дәрәҗәләребез, тормышка карашларыбыз да бертөрле. Барыбыз да матур итеп татарча сөйләштек. Укытучыларыбыз да безгә карата бик хәерхаһ булды.

Мин беркайчан үземнең акцентымнан оялмадым. Хәтерлим, берсендә кызым белән балалар бакчасыннан кайтып барабыз. «Әни, син бит русча дөрес сөйләшмисең», – диде кызым. «Кызым, син борчылма. Иң мөһиме – мин туган телемне беләм, ике телдә сөйләшәм. Моның белән син, киресенчә, горурланырга тиешсең», – дидем.

**– Бүген балалар бакчасында саф татарча сөйләшә торган сабыйларны сирәк күрәсең. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз? Гаепне кемнән эзләргә?**

– Бу бик күп татар гаиләсенең проблемасы. Яшермим, бездә дә бар. Ни кызганыч, дүрт оныгым саф татарча сөйләшә дип әйтә алмыйм. Әлбәттә, тырышабыз, татарча шигырьләр өйрәтәбез, ана телебездә аралашабыз. Ләкин, тәҗрибә күрсәткәнчә, бу гына җитми икән. Балаларга татарчаны бакча, мәктәп тә яхшылап бирергә тиеш. Шунсыз камил дәрәҗәдә телне белү мөмкин түгел.

Телне яхшы белү өчен мохит булырга тиеш, кызганыч, ул юк. Тагын бер проблема – бүген дәү әни, дәү этиләр оныкларны күрми. Ә безнең балалар авылда үсте. Улыбыз белән кызыбыз җәй буе авылда яшәде. Тик безнең оныклар белән утырырга вакытыбыз юк, чөнки дөнья куабыз. Болар барысы да яшь буынның ана телен белмәвенә китерә.

**– Бала тәрбияләү турында сүз чыккан икән, бала культы барлыкка килүгә ничек карыйсыз? Бу начармы, әллә, киресенчә, яхшымы?**

– Начар түгел дип саныйм. Балаларны яратырга кирәк. Менә яһүдләрне алыйк. Ул-кызларын шуның кадәр зурлыйлар, күкләргә күтәрәләр. Ул баланың инде белеме дә уртача гына, аның сәләте дә әллә нәрсә мактанырлык булмый, ә ата-ана баласын үстерә. Ул аңа скрипка алып бирә, аны төрле конкурсларга йөртә, кеше арасына кертә... Лауреат итәләр, син дип, мактап кына торалар. Ә менә безнең татар халкына ул бик җитеп бетми. Бездә әдәп-әхлак бик көчле, мин аңа бик сөенәм. Ә менә үзеңне күрсәтә белү ягы аксый. Башкалардан өйрәнергә кирәк.

Милләт турында сүз чыккач, бер фикер әйтәсем килә: ни кызганыч, халыклар бер-берсенең начар ягын гына күреп ала. Башка милләтләрдән еш кына ишетергә туры килә: имеш, безнең ирләр дүрт хатын белән яши. Шулай итеп безне көлкегә калдыралар. Әйе, бу күренеш бар, тик бит ул бик сирәк. Һәм ул татарның асыл сыйфаты да, гадәте дә түгел!

**– Дистә елдан артык «Бөтенроссия татар гаиләсе» фондын җитәклисез. Аның эшчәнлеге нидән гыйбарәт? Конкрет нәрсәләр эшлисез?**

– «Бөтенроссия татар гаиләсе» фонды Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты каршында оештырылган коммерцияле булмаган иҗтимагый оешма санала. Без аны 2006 елда рәсми рәвештә РФ Юстиция министрлыгында теркәдек. Фондның беренче рәисе, оештыручысы ТРның халык язучысы һәм җәмәгать эшлеклесе, ТР Дәүләт Советы депутаты Туфан Миңнуллин иде. Туфан абый мәрхүм булганнан соң бу эшне Татарстанның халык шагыйре һәм җәмәгать эшлеклесе, ТР Дәүләт Советы депутаты Роберт Миңнуллин алды. Аның белән дә бик матур эшләдек.

Фондның бурычы – рухи-әхлакый, милли-мәдәни һәм гаилә традицияләрен торгызу; гаммәви мәгълүмат чаралары ярдәмендә татар гаиләсенең статусын күтәрү; татарларның милли-мәдәни, рухи үсешенә, милли үзаңын тәрбияләүгә ярдәм итү. Без Татарстанда яшәүче гаиләләр белән генә түгел, Россия, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез белән дә даими элемтәдә торабыз, чаралар үткәрәбез. Татарлар – дөнья буенча таралган тырыш, акыллы милләтләрнең берсе. Һәм без бер йодрык булып, ислам дине кануннарына таянып яшәргә тиешбез.

**– Иҗтимагый оешмага ярдәм итүчеләр бармы?**

– Безнең абруйлы, актив идарә әгъзаларыбыз бар, алар ярдәм итә.

Мәрхүм Туфан абый: «Миләүшә, безнең фондның акчасы булмас. Әтатар гаиләсе дигән сүз колакта яңгырап торырга тиеш. Ләкин син бу эшне ташлама», – дип әйтә иде. Дистә елдан артык аның әманәтен үтәп яшим, Аллаһка шөкер.

**– Чит төбәкләрдә еш буласыз. Андагы татарлар бездән аерыламы?**

– Шундый ук тырышлар, матурлар. Аерма – алар берничә тел белә. Мисал өчен Финляндиядә яшәүче милләттәшләребезне алыйк: ана теле – татар телендә гаиләдә сөйләшәләр, ә фин, швед, немец, инглиз телләрен көнкүрештә кулланалар. Татар теле миңа нигә кирәк дип утырмыйлар, бу аларның ана теле, бет-те-китте. Ә бездә ике тел өйрәнергә котлары оча. Татарларга гына түгел, русларга, башка милләтләргә дә кагыла бу.

Балаларга еш әйтәм: бер-берегез белән өйдә татарча, инглизчә сөйләшегез, ә рус телендә болай да урамда, укуда, эштә аралашасыз. Нәтиҗәдә өч тел дә онытылмый һәм сез заман таләпләренә туры килә торган алдынгы кеше буласыз.

**– Бөтенроссия халык санын алу нәтиҗәләре буенча Россиядә татарларның саны 600 меңгә диярлек кимеде. Моның сәбәбе нәрсәдә дип уйлыйсыз? Алга таба нәрсә эшләргә?**

– Безгә бүген сыйфатыбыз турында уйларга кирәк. Сыйфатлы милләт, аз санлы булса да, югалмый. Ә менә мескенлеккә төшкән милләт, күпсанлы булса да, югала. Югалмаган тәкъдирдә дә дөнья аренасында аңа карата хөрмәт булмый. Затлылык кирәк. Татар гомергә үзенең йөзен саклаган. Мин милләтебезнең киләчәге өметле икәнен беләм. Ул сыйфат ягыннан күтәреләчәк. Дөнья буенча, Россия киңлегендә карасак та, татарлар үз дәрәҗәләрен саклый, үзләрен күрсәтә беләләр.

**– Яшь татар гаиләләренә нинди үгет-нәсихәт бирәсез?**

– Без Россиядә сан буенча икенче урында. Милләтебезнең йөзе, тридицияләре саклануда татар гаиләләренең роле бик зур. Шуны онытмасак иде.

Милләтегез белән горурланыгыз, балаларыгызга татарларның горур тарихы, дөньяга танылган атаклы шәхесләре турында күбрәк сөйләгез дияр идем. Ә инде гомуми яшәешкә килгәндә, бер фикер әйтәсем килә: бүген бик күпләр кайгыны уртаклаша ала, әмма шатлыкны уртаклаша белми. Ә кешегә үзен бәхетле хис итү өчен кайгы уртаклашу гына кирәкми. Бик аяныч: кеше тирә-юньдәгеләрнең шатлыгын кабул итә алмый. Башкалар өчен сөенергә өйрәнсәк, бәхетебез артачак. Балаларга да шуны сеңдерергә кирәк. Күршең начар яшәсә, сиңа күңелле түгел бит! Балаларың да шуны күреп үсә.

Тагын... кешегә рәнҗемәгез, кичерергә өйрәнегез. Рәнҗетергә теләүчеләр байтак булыр. Мин, мәсәлән, бөтен кешене гафу итәм. Шуның белән бәхетлемен дә...

игелекле эшләр

# мәңгелек кыйммәтләр /

акыллы гамәлләр

## Бу санда тәкъдим итәбез:

Бер татар тулы бер армияне **ничек** алыштырган

Шәмбалыкчыда **нинди** музей бар

Такталачык авылы **ничек** яши

Иранга **ничек** сәяхәт кылырга

тарихи шәхес

# МӘХМҮТ ГӘРӘЕВНЕҢ МӘҢГЕЛЕК КӨРӘШЕ

Әскәр Сабиров

«Руслар Әфганстаннан йөз мең солдатын алып чыкты. Алар урынына бер татарны кертте». Пакыстан газеталарының берсендә безнең хәрбиләрнең оператив төркеме җитәкчесе Әфганстанга килгәч шундый язма басылып чыга. Көнбатыш аналитиклары да «оптимистик» фараз бирә: совет гаскәрләре чыгарылгач, Нәҗибулла хөкүмәте өч атнадан артык яшәмәячәк. Үзенең алтынчы сугышында катнашучы Мәхмүт Гәрәев исә башка фикердә тора.

Фото: tatarica.org, stuki-druki.com, stcdn.business-online.ru

Әлеге газета генерал-полковник Мәхмүт Гәрәевнең өстәлендә басылып чыкканнан соң берничә көн үткәч пәйда була – хәрби разведчикларыбыз тырыша. Газетадагы төртмәле сүз тапкырлыктан бигрәк, усал шаярту буларак кабул ителә, чөнки урамда 1989 елның феврале – совет гаскәрләренең әфган җиреннән чыгарылган вакыты. Ә Президент Нәҗибулла каршындагы совет хәрбиләренең оператив төркеме җитәкчесе булган «бер татар» буйсынуында нибары егерме биш киңәшче кала. Шуңа күрә Көнбатыш хәрби аналитикларының сүзләре, мөгаен, бик аз кешене генә гаҗәпләндергәндер.

Совет аналитикларының фикерләре дә оптимизм өстәми. Һәрхәлдә, берничә генерал, Кабулга бару перспективасын ишетүгә, кинәт «авырып китә» һәм госпитальгә ята. Гәрәевкә 65 яшендә ялганлап торырга да кирәкми югыйсә: Бөек Ватан сугышында алган дүрт яра һәм контузия гел сиздереп, борчып тора. Ләкин чын солдат боерыкны тикшерми, ул аны үти. Командировка күпмегә сузылачак? Ике-өч айга, диләр аңа...

СССР оборона министры Дмитрий Язов Әфганстанга китәчәк офицер белән сөйләшкәндә сорап куя:

– Ничек, барырга курыкмыйсыңмы?

– Миңа куркырга соң инде. 1941 елда Ташкент хәрби училищесын тәмамлаган ротадан 26 кеше сугыштан кайтты. 119 кешенең 26 сы. Миңа язмыш болай да кырык елдан артык гомер бүләк итте, аңа үпкәләү гөнаһ булыр, – ди ул.

## СУГЫШ – КОТОЧКЫЧ НӘРСӘ...

1941 елда Мәскәү янында хәлиткеч сугышлар барганда бер сапер юл баганасына: «До Берлина – 2000 км» дип язып куя. Кар көртенә бата-чума янәшә атлаган җәяүле солдат болай дип өсти: «...Ничего, дойдем!» («ничего» урынына сүзнең катырагы әйтелә, әлбәттә). Фронттагы бу эпизодны Мәхмүт Гәрәев соңрак бик еш искә ала, һәр тапкырында ярамаган сүзне йомшартыбрак әйтеп җибәрә. Һәм һәрвакыт: «Шундый солдатлар һәм аларны тудырган халык барысын да җиңәчәк, алар җиңелә алмый!» – дип өстәп куя. Ләкин үзен беркайчан да плакаттагы курку белмәс, кыю солдат итеп күрсәтергә тырышмый. Беренче сугышында да, соңрак та. «Куркыныч булды, бер генә мәртәбә түгел», – дип сөйли ул.

Сугышта иң куркынычы нәрсә? Бомбага тоту. Бу турыда ул 1942 елда батальоннарына килгән хәрби корреспондентка сөйли. Кайдадыр Медынь тирәсендә, Көнбатыш фронтта була бу хәл. Батальонны яңа гына алгы сызыктан чыгарганнар, алар урман аланында окоп казу белән мәшгуль. Хәбәрче исә төпченә, куркыныч янаганда, кемнәрнең нәрсә кичерүен ачыкларга тырышып аптырата. Комбат Гәрәев аңа үз куркулары мисалында аңлатып бирә: һөҗүмгә барганда бер нәрсәне беләсең – йә син дошманыңнан өстен чыгасың, йә ул сине юк итә. Снаряд шартлаганда чокырга очсаң да, исән калу мөмкин: ихтималлык теориясе буенча икенче снаряд шул ук чокырга төшмәскә тиеш. Әмма менә өстеңә бомба яуганда, аннан котылу мөмкинлегең юк, көчсезлектән нишләргә белмисең...

1941 елның ноябрендә беренче мәртәбә бомба астында калганнан соң, үзе дә сизмәстән, дога укый башлавы турында командир Гәрәев корреспондентка әйтеп тормый, әлбәттә. Дин искелек калдыгы дип саналган вакытлар. Әмма еллар узгач, әлеге эпизодны хәтеренә төшереп, аңлатырга кирәк таба: «Сугыш – коточкыч нәрсә. Адәм баласы, язмышы белән бергә бер калгач, яклау эзли башлый. Әгәр син үзеңнән өстен һәм сине яклый, саклый ала торган илаһи көч барына ышанасың икән, иң өметсез мизгелләрдә ярдәм булыр кебек тоела. Бу кайсы диннән булуыңа карамый».

Батальонга килгән хәбәрченең фамилиясе Симонов булып чыга. Аларның хәрби юллары әле күп тапкырлар кисешәчәк, алар хәтта дуслашып та китәчәк. Шактый вакыт узганнан соң, 1974 елда, язучы Константин Симонов фронтовик иптәшенә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә: хәрби архивларга кертмиләр. Генштабның хәрби-фәнни идарәсе башлыгы Мәхмүт Гәрәев рөхсәт боерыгы бирә. Моның өчен аңа партиянең баш идеологы, КПСС ҮК секретаре Михаил Сусловның хөерхаһлыгын алырга туры килә.

Нуленче еллар башында Мәхмүт Гәрәев тә архивларда күп утыра, язучы Симоновның фронт очеркларын һәм язуларын, рәсми хатларын анализлый, аларның барысын үзе белән очрашулардан алган тәэсирләре белән чагыштыра. Нәтиҗәдә «Константин Симонов как военный писатель» китабы дөнья күрә. Бу китап фронтовик язучы образын каралтырга тырышкан кешеләргә җавап булып тора.

**МӘХМҮТ ӘХМӘТ УЛЫ ГӘРӘЕВ.** 1923 елның 23 июлендә туа. Армия генералы, Бөек Ватан сугышында, Япония белән сугышта, тагын 4 сугышта һәм локаль конфликтларны җайга салу операцияләрендә катнаша, шул исәптән Әфганстандагы вакыйгаларда да. Хәрби фәннәр һәм тарих фәннәре докторы. 1995 елдан алып гомеренең соңгы көннәренә кадәр – Хәрби фәннәр академиясе президенты. 250 дән артык фәнни һәм публицистик хезмәт авторы. Алар арасында «Хәрби фән», «Әгәр иртәгә сугыш булса», «Сугышның бәхәсле сәхифәләре», «Маршал Жуков. Гаскәр белән идарә итү сәнгатенең уникальлеге һәм бөеклеге», «Бөек Җиңү полководецлары һәм хәрби мирас» һ.б. хезмәтләр бар. «Маршал Жуков. Гаскәр белән идарә итү сәнгатенең уникальлеге һәм бөеклеге» китабы өчен РФнең Г.К.Жуков исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Аның актив катнашлыгында күп кенә фундаменталь хезмәтләр, шул исәптән «Икенче Бөтендөнья сугышы тарихы. 1939–1945» дип аталган 12 томлык, «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы. Хәрби-тарихи очерклар» дип аталган 4 томлык, 2015 елда дөнья күргән «1941–1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы» дип аталган 12 томлыкның кайбер томнары эшләнә. Ул – Ленин ордены, дүрт мәртәбә Сугышчан Кызыл Байрак ордены, Александр Невский ордены һ.б. хәрби орденнар, медальләр иясе. 2019 елның 27 декабрендә Мытищидагы федераль хәрби мемориаль зиратта җирләнде.

## «...СОҢГЫ МӨМКИНЛЕККӘ КАДӘР»

Әфганстанда «бер татар»ның ни торганын күрсәтү форсаты командировканың беренче аенда ук килеп туа. Җәләләбад янында әфган халык армиясенең бер өлеше, мөҗәһитләрнең басымы астында паникага бирелеп, позицияләрен ташлап китә. Борис Пастухов* сөйләгәнчә, генерал каршылык күрсәтергә сәләтлеләрне җыя һәм, танкка утырып, аларны һөҗүмгә алып бара. Дошман тар-мар ителә.

Киңәшчеләр төркеме җитәкчесенең әфганлыларга үз мәнфәгатьләрен ничек якларга кирәклеген күрсәткән бәрелеш, күрәсең, Мәхмүт Гәрәев ил Президентына тәкъдим ителгәннән соң берничә көн үткәч булгандыр.

– Совет гаскәрләре чыгып киткәч, монда килергә ничек гайрәтегез җитте? Без ничек, кем ярдәмендә каршы тора алырбыз икән соң? – Әфганстан Хәрби көчләре Югары башкомандующие, ил президенты Нәҗибулла Кабулда үзенең баш хәрби киңәшчесен әнә шулай каршы ала. Аның сүзләрендә аптырау катыш ирония дә яңгырый.

Гәрәев югалып калмый. «Рус армиясендә борын-борыннан болай диләр иде: «Яхшы командир бер татарны да ике рәткә тезеп бастыра ала». Мөселманнар буларак, бергәләп, рәтләрне икеләтә арттырырга тырышып карыйк. Соңгы чиккә, соңгы мөмкинлеккә кадәр тырышырга кирәк...»

Аңа вәгъдәсен шактый катлаулы шартларда үтәргә туры килә. Әфган армиясендә, Гәрәев соңыннан искә алганча, төшенкелек хөкем сөрә. Мөҗәһитләрнең һөҗүмнәре генә түгел, Әфганстан халык-демократик партиясенең үзендәге эчке каршылыклар, низаглар, оешканлыкның бик түбән дәрәҗәдә булуы армияне какшата. Тәҗрибәле Гәрәев бурычларны төгәл билгели: гаскәрләрдә эшне активлаштырырга, төшенкелек белән көрәшергә һәм аннан котылырга. Союзникка исә шуны сеңдерү зарур: оппозиция һөҗүменә каршы торып була. Һәм монда бер хәрби белем генә җитми, дипломатия могҗизаларын да күрсәтергә туры килә. Өстәвенә, 1989 елда Мәскәүдә Әфганстан кайгысы калмый – СССР таркалу алдында тора.

Ел ярымнан соң Мәхмүт Гәрәевне Әфганстаннан чакыртып алалар. Өенә ул инде армия генералы дәрәҗәсендә кайта. Совет гаскәрләре чыгарылганнан соң, күп дигәндә, өч атна гомере калды, дип фаразланган Нәҗибулла хакимияте әле Гәрәевтән соң да яшәп кала әле.

Мәхмүт Гәрәевнең яшь чагы.

## ХӘРБИ ФӘННЕ ОКОПЛАРДА ӨЙРӘНӘ

Ташкент хәрби училищесын тәмамлаган 18 яшьлек кече лейтенант Гәрәев беренче тапкыр яуга 1941 елның ноябрендә керә. Немецлар башкалага бик якын килгән вакыт: Мәскәү янындагы Чернышевский казармаларыннан фронтка кадәр ара шактый кыска. Гәрәев бер взводны кабул итеп алырга тиеш була, әмма өлгерми кала. «Батальонга килеп төштем. Каршыма кулы бәйләүле старшина килә. Яралы. «Батальон командиры кайда?» – дип сорыйм. – «Юк», – ди ул. – «Ә офицерлардан кемнәр бар?» – дим. – «Беркем юк, беркем дә калмады», – дип искә ала Мәхмүт Гәрәев. – Миңа батальон белән командалык итәргә туры килде, гәрчә штат буенча комбат – подполковник, һич югында майор дәрәҗәсендә булырга тиеш булса да. Ике тәүлектән соң батальон командиры итеп бер капитанны җибәрделәр. Миңа рота белән җитәкчелек итү йөкләнде...»

Гәрәев өчен сугыш Калуга өлкәсендә 1942 елның августында ук тәмамланырга мөмкин була. Җәйге һөҗүмнәр вакытында ул аерым рота белән командалык итә. Ядрә аны һөҗүмгә барганда куып тота. Тиз генә кулын бәйләтә дә яңадан яуга ыргыла. Яңа командир килеп җиткәнче, өч көн сугыш кырында була. Ул арада кулы кара янып чыга. Медсанбаттагы хирурглар озак сөйләшеп тормый, кисәргә, дигән карарга килә. Шунда олы яшьтәге бер санитарка ярдәмгә килә: егетне санитар эшелоны белән Рязаньга җибәрттерә. Андагы госпитальдә Гәрәевнең кулын саклап калалар. Икенче тапкыр Гәрәевнең Витебск янында башын яралана. Дәваланып, яңадан фронтка китә...

1944 елда Мәхмүт Гәрәев батальоны Молодечнога (Мәхмүт Гәрәев бу шәһәрнең почетлы гражданины – ред. иск.) беренче булып керә. Белоруссия операциясе вакытында, «узып барышлый» гына, аның солдатлары Ворошилов исемендәге партизан отрядында сугышкан берничә мең кешене коткара. Тылларын чистартырга дип, дошман партизаннарга каршы берничә дивизиясен ташлаган була. Отряд урмандагы күл буена яшеренә, әмма чолганышта кала. Азык-төлексез сугышчылар һәлакәткә дучар ителә. Гәрәев подразделениесенең юлсызлык шартларында көтелмәгән һәм кискен һөҗүм ясавы нәтиҗәсендә дошман чылбыры өзелә, чолганышта калганнарны коткару мөмкинлеге ачыла...

*Ул вакытта Әфганстанда СССР илчесе.

Җиңү бәйрәмендә Кызыл мәйданда.

«Сугышның буеннан-буена, 1944 елның уртасына кадәр, мин иң түбән звеноларда сугыштым, – дип сөйли бер әңгәмәсендә Мәхмүт Гәрәев. – Рота командиры, батальон штабы башлыгы, комбат, аннан соң – бригада звеносында оператив бүлек башлыгы. Җиңел вазыйфалар булганын хәтерләмим. Һәрвакыт – алгы сызыкта, окопта. Сугышта без көн саен бер генә уй белән яшәдек: исән калырбызмы-юкмы?»

50 елга сузылган армия хезмәтендә ул СССР Генштабы башлыгы урынбасары дәрәҗәсенә кадәр күтәрелә. Бу үсешнең Садовое кольцо чикләрендә үз җиңүләрен «әвәләгән» штаб офицерларының карьерасы белән бернинди уртаклыгы да юк. Хәрби фәнне Мәхмүт Гәрәев Мәскәү яны окопларында, Ржев сазлыкларында, Кенигсберг өчен каты бәрелешләрдә үзләштерә. Инде аннан соң гына – академияләрдә…

## МӘҢГЕЛЕК КӨРӘШ…

Кырык бишенче елның тугызынчы маенда майор Гәрәев шелтә ала, мондый хәл хезмәт итү дәверендә бик сирәк була. Аларның частен икенче – Япония белән сугышка илтә торган эшелон Урал артына җитә. Шул вакытта солдатлар Җиңү турында ишетә. Шатлыктан һавага ата башлыйлар. Ә бу көнне нәкъ менә майор Гәрәев дежур тора. Аңа маскировка шартларын бозган өчен шелтә белдерәләр. Әле тагын махсус бүлек хезмәткәрләренә аңлатма бирергә туры килә. Ләкин бусы инде ату аркасында түгел, сыер аркасында килеп чыга.

– Бөтен кеше бәхетле – Җиңү, ә эшелон янында чандыр гына бер ир-ат провиант сыйфатында үзебез белән алып барган сыерларга кызыгып карап тора. Сыерлар немецларныкы, нәселле, тук, чиста – безнекеләр кебек түгел инде. Командир: «Җиңү шатлыгыннан берсен шушы ир-атка бүләк итик», – ди. Әйтелде – эшләнде. Бүләк иттек, эшелон кузгалды, ә теге ир-ат миңа ялына: «Урланган түгел, бүләк ителгән дигән белешмә язып бирегез инде», – ди. Мин планшеттан ашык-пошык кына кәгазь тартып алдым да: «Хәрби часть Җиңү көне хөрмәтенә фәлән-фәлән кешегә сыер бүләк итте», – дип язып куйдым. Һәм имзасы: майор Гәрәев. Менә шунда махсус бүлек кешеләре, әлеге язуда частьнең номерын күрсәтмәдеңме дип, кызыксына башлады…

Ә аннары тагын сугыш… Японияне җиңгәннән соң, Мәхмүт Гәрәевне Кытайга җибәрәләр – Халык-азатлык армиясен төзергә булышырга. Инде 70 нче елларда баш хәрби киңәшче штабы башлыгы сыйфатында Сүрия, Мисырдагы вакыйгаларда катнаша.

Һөнәри белемнәре буенча хәрби фәннәр докторы Мәхмүт Гәрәев белән тиңләшә алырлыклар бармы? Хәер, ул үзе, бу сорауны биргәндә, тормышындагы бер вакыйганы искә алып сөйләргә ярата. Бу хәл аның яшь чагында, хәрби хезмәтенең башында була.

«Рота белән тар гына юлдан барабыз, як-ягыбызда – кыр. Каршыга сугышның ачысын да, тәчесен дә татыган тәҗрибәле сержант килә, медсанбатка барышы. Минем яшь икәнемне күрептер инде, болай ди: «Әй, лейтенант, – ди, – син нәрсә, нишләп ротаңны колонналап алып барасың? Бүлгәләргә кирәк!» Мин бүлдем: бер рәтне – уңга, икенчесен сулга куйдым. Алга таба юл тотабыз. Каршыга – тагын бер сержант. Анысы да дәшми генә уза алмады: «Син нәрсә, лейтенант, солдатларыңны минага эләктереп, күккә очырырга телисеңме? Колоннага тез дә юлның кыл уртасыннан алып бар!» Тездем, алып киттем... Аннан соң, күпме гомер үтте, мин ике академия тәмамларга өлгердем, әмма ике киңәшченең кайсы хаклы булуына тәки төшенә алмадым», – дип, көлеп, сүзен тәмамлый Мәхмүт Гәрәев.

Хәрби тарих белән кызыксыну – монысы да аның хәрби карьерасының аерылгысыз бер өлеше. Кайбер батырлыклар, әйтик, якташыбыз майор Петр Гаврилов һәм Брест крепостен саклаучылар турында үз вакытында белүебез өчен без нәкъ менә аңа бурычлы. Эш шунда ки, сугыштан соң берничә ел узгач, Гәрәев Брест крепостена дивизия полкының штаб башлыгы итеп билгеләнә, озакламый аңа дивизия командиры вазыйфасы йөкләнә. Сугышчылар ватык кирпечләрне актарганда коралларга, диварлардагы язуларга юлыга. Крепостьне саклаучыларның язуларына. Гәрәев бу хакта «Огонёк» журналына хәбәр итә. Шуннан соң Брестка язучы Сергей Смирнов килеп төшә.

Күп кенә җәлилчеләрнең, шулай ук «Идел-Урал» легионына кергән, корал белән белорус партизаннары ягына чыгып, фашистларга каршы сугышкан 825 нче «татар батальоны» солдатларының намуслы исемен кайтаруга да хәрби тарихчы Мәхмүт Гәрәев эзләнүләре зур өлеш кертә. «Мин бу игелекле эшкә үз өлешемне кертүемә шатмын һәм моның белән чиксез горурланам, – дип сөйли генерал Мәскәүдә ТР Даими вәкиллегендә биргән интервьюсында. – Эш шунда ки, Моабит дәфтәрләре, «җәлилчеләр төркеме», аларның ничек кулга алынуы, җәзалап үтерелүе турында бердәнбер шаһит – Бельгия әсиренең сөйләгәннәре. Шуңа күрә дә моңа шикләнеп

Мәхмүт Гәрәев белән Минтимер Шәймиев.

караучылар табылды, бигрәк тә ул кеше башта бертөрле, аннан икенче төрлерәк сөйли башлагач. Һичшиксез, ул намуслы, яхшы кеше, әмма барысын да хәтердә тоту мөмкин түгел, үткәннәрне кире кайтара алмыйсың. Ә без немец коллегаларыбыз ярдәмендә Гитлер командованиесенең кулга алу, җәзалау турында боерыкларын таптык. Хәзер Муса Җәлил һәм аның иптәшләренең батырлыгы документаль рәвештә расланды».

## САНКЦИЯЛӘР ҺӘМ СУГЫШНЫҢ ЯҢА ЫСУЛЛАРЫ ТУРЫНДА

«Бездә 45 нче корпус командиры Станислав Поплавский бар иде. Беркөнне немецлар командование пунктына бәреп керә. Ул траншеяга чыга, янына каушап калган корпус штабы башлыгы йөгереп килә: «Бөтен җирдә немецлар!» Ә Поплавский нишли? Ул щетка ала да итеген чистарта башлый. Штаб башлыгы аптырап кала, әмма аңа акыл, хәлне дөрес бәяли һәм каршылык күрсәтүне оештыра алу сәләте кайта... Мин моны шуңа әйтәм: кайчак сугышта, хәер, көндәлек тормышта да бер элемент, көтелмәгән бер гамәл, инструкция һәм катгый боерыкларга караганда, күпкә хәлиткечрәк тәэсир итә ала».

Гәрәев сөйләгән бу вакыйга аның хәрби аналитик буларак фикерләү үзенчәлекләрен бик яхшы ача, дип уйлыйм. Генерал турында «Красная Звезда» газетасында басылган мәкалә (2018 елда Мәхмүт Гәрәевнең 95 еллыгы уңаеннан язылган) авторы, 1960 нчы еллар ахырында аның җитәкчелегендә хезмәт иткән кеше, болай дип яза: «Ул шаблоннарны сөймәде». Автор сүзләренчә, «Гәрәевнең, хәрби тәҗрибә анализы нигезендә, тактиканы җирле шартларны исәпкә алып камилләштерү буенча эшләнгән кайбер стандарт булмаган киңәшләре Көнчыгыш Пруссия һәм Ерак Көнчыгыштагы сугышлар барышында уңышлы тормышка ашырылды». Ә соңрак, сугыштан соңгы елларда, «безнең дивизиядә аның күрсәтмәсе буенча һәм турыдан-туры катнашында гаскәрләр өчен программалаштырылган укыту элементлары кулланылган хәрби әзерлек методикасы эшләнде һәм беренче тапкыр сыналды. Бераздан бу методика боерык нигезендә Коры җир гаскәрләренең барлык берләшмәләрендә кертелде».

Мәхмүт Гәрәевнең шаблоннарны яратмавы бу дивизияне СССР Кораллы көчләре һәм Варшава договоры илләре армияләре өчен алдынгы хәрби тәҗрибә мәктәбе итәргә мөмкинлек бирә. Бирердә Совет армиясе һәм союзникларның Югары командованиеләре катнашында әзерлек занятиеләре үткәрелә. Алай гына да түгел, генерал Гәрәевнең хәзерге заманның масштаблы һәм локаль бәрелешләрендә корал куллану үзенчәлекләре турында язылган кайбер китаплары бүген дә хәрби югары уку йортларында дәреслек буларак кулланыла. Сүз уңаеннан, Россиядә генә түгел, АКШ һәм башка илләрдә дә.

Тиз үзгәрә торган бүгенге дөньяда генералның фикерләре никадәр заманча соң? Менә Хәрби фәннәр академиясе президенты Мәхмүт Гәрәевнең «XX гасыр сугышларында Россия»** лекциясеннән өзек: «Бүгенге көндә шундый вазгыять урнашты: без берничә дистә ел дәвамында әзерләнгән атом сугышының ихтималлыгы бик аз. Гомумән, масштаблы сугыш ихтималы аз, чөнки сәяси максатларга ирешүнең башка ысуллары уйлап табылды: икътисадый санкцияләр, дипломатик басым, мәгълүмати сугыш. Эчтән җимергеч гамәлләр кылып, илләрне бер-бер артлы яулап алырга була. Куркыныч тудырмый гына, чөнки зур сугыш атом коралын куллануга китерергә мөмкин. Башка юллар табылды, алар арасында акча куллану да бар – Ирактагы кебек, анда барысын да диярлек сатып алдылар. Шуңа күрә хәзер Кораллы көчләрнең беренче чираттагы бурычы – локаль сугыш һәм бәрелешләргә әзер тору һәм, кечкенә конфликтлар үсә калса, күпмедер күләмдә зур сугышка да әзер булу».

Күрәсездер, бу кичәге көн турында түгел.

## АНЫҢ ЮГАРЫ ТӨГӘЛЛЕКЛЕ КОРАЛЫ

1994 елда Никита Михалков Мәхмүт Гәрәевне һәм тагын берничә ветеранны үзенең «Утомленные солнцем-2» фильмын карарга чакыра. Бу фильмны караганнан соң, генералның кәефе кырыла: «Без, бу фильмда сугыш белән бернинди дә уртаклык күрмәдек, дип әйттек. Ул ярсып китте, ә курсантларның мәгънәсез үлеме, үз гаскәрләре барганда күперне үзебезнекеләр үк шартлатулар булмадымы? Булды, тагын да ямانрагы булды. Ләкин сугыш мондый хаталардан гына торса, без җиңүгә ирешмәс идек. Ә солдатларның батырлыгы һәм фидакарьлеге кайда соң?»

Ярар, бу әле нәфис кино, ә менә Ливенворттагы (АКШ) хәрби-штаб көллияте территориясендә Икенче бөтендөнья сугышы музеен карап чыгу фронтовик ветеранны шок хәлендә калдыра. «Зур бина – музей. Безне анда чакырдылар һәм өч сәгать ярым йөрттеләр. Советлар Союзының анда катнашуы турында бер сүз дә әйтелмәде, – дип сөйли ул 2012 елда «Труд» газетасы хәбәрчесенә. – Анда Австра-

** Лекция 2005 елда «Публичные лекции Полит.рум» проекты кысаларында Мәхмүт Гәрәев тарафыннан укыла.

лия, Яңа Зеландия техникасы тәкъдим ителә, теләсә кайсы илнеке, тик безнеке генә түгел. Музейдан чыккач, мин алардан: «Ә Советлар Союзы сугышта катнашканмы?» – дип сорадым. Әлбәттә, катнашкан, диләр, ләкин ул шундый зур ил, аңа урын күп кирәк, бездә урын җитми, диләр. Шуңа күрә аларда безнең өчен урын юк һәм беркайчан да булмаячак. Ләкин үзебезне генә карагыз: Австралиянең Икенче бөтендөнья сугышында катнашуы – 10 томда, Япониянеке – 100 томда, Американыкы 120 томда тасвирлана! Ә безнеке – 12 томда...»

Мәхмүт Әхмәт улының реакциясе аңлашыла. Галим һәм фронтовик Мәхмүт Гәрәев язган соңгы китапларның берсе «Сражения на военно-историческом фронте» дип атала. Бу китап, әлбәттә, сугыш, көрәш турында. Гәрәевнең җиденче, соңгы көннәренәчә дәвам иткән көрәше турында. Дөреслек, хакыйкать өчен көрәш. Ялганга һәм алдауга каршы көрәш. Җиңүнең мәгънәсен һәм дәрәҗәсен киметергә тырышучыларга каршы көрәш.

Бу җиденче сугышны Мәхмүт Гәрәев һәм Хәрби фәннәр академиясе (ул – Академиянең алыштыргысыз президенты) соңгы дистә еллар дәвамында алып барды. Аның без искә алган китабы да, күпсанлы башка басмалары да – тарихны яңадан язарга тырышучыларга каршы югары төгәллекле корал. Аларның бернинди дә мөмкинлекләре юк: фактлар, саннар, аргументлар – Гәрәев үз коралын «ясаганда» күп нәрсәләрне өйрәнгән, белгән яки тикшергән генә түгел – ул барысын да үз язмышы һәм йөрәге аша кичергән. Гәрәев һәр сан артында кеше гомере торганын бик яхшы аңлый – яу кырында ятып калганнар күз алдында тора чөнки. Шуңа да бәхәсләр вакытында аның бер генә карышка да чигенмәве аңлашыла. Сүз югалтулар, саннарны алыштырулар турында булса – бигрәк тә. «Бу инде историография түгел, статистикага да бернинди катнашы юк моның, бу – пычрак сәясәт, – дия иде ул. – Кайберәүләрнең югалтуларны күбрәк булуын исбат итәсе килә, шул рәвешле алар Җиңүнең бәясен киметергә тырыша. Бу – бик четерекле һәм яраларга тия торган тема, фронтовиклар өчен – бигрәк тә. Бу мәсьәләдә ярыш юлына басу – коточкыч хәл».

Мәхмүт Гәрәев югалтуларны раслау комиссиясенең рәисе булып тора һәм аның иманы камил: «Югалтулар турындагы хакыйкатьне кешеләргә җиткерү – кирәк эш. Моны эшләмәсәк, без сугышның нәтиҗәләрен билгели алмыйбыз, җиңүнең нәрсә бәрабәренә яулап алынуын да бәяләү мөмкин түгел». Нәкъ менә Мәхмүт Гәрәевкә саннарның халыкка барып ирешүе өчен рәхмәтле булырга тиешбез: Советлар Союзының Бөек Ватан сугышындагы югалтулары – 26, 5 миллион кеше гомере. Шуларның 18 миллионын гади халык, фашистлар яулап алган территорияләрдәге явызлыкларның корбаннары тәшкил итә...

Алай гына да түгел, Мәхмүт Гәрәев, замана сәясәтенә яраклашырга тырышып, беркайчан да үз фикереннән баш тартмады. Бөек Ватан сугышында Сталинның роле нинди булган, дигән сорауга да җавабы кискен һәм анык аның: «Моңа хак җавапны тарихны өйрәнеп әйтергә мөмкин. Бөек Ватан сугышы тарихын гына да түгел. 1812 елдагы сугыштан соң, Россия барлык сугышларда да диярлек җиңелеп килә – Кырым сугышы булсынмы ул, Рус-япон сугышымы, Беренче бөтендөнья сугышымы. Минем фикеремчә, моның төп сәбәбе – хакимият башында торучыда, димәк, армия белән күп еллар дәвамында тәҗрибәле, яхшы җитәкчеләр идарә итмәгән, дигән сүз. Сугыш шартларында идарә тиешле дәрәҗәдә дөрес оештырылмаса, бер генә халык та җиңүгә ирешә алмый, алай гына да түгел, хәтта тиешле юнәлеш тә таба алмаска мөмкин...» Гәрәев бер генә мәртәбә дә Сталинны тиран булмаган дип расламый, шуңа да карамастан, үзенең әлеге «хөрлеге» өчен әллә никадәр тәнкыйть утына тотыла. Шулай да фактлар белән беркетелгән фикереннән баш тартмый.

– Бөек Ватан сугышы турындагы хакыйкатьне әле киләчәктә әллә ничә буын галим һәм язучылар ваемлар, дип уйлыйм. Ә спекуляцияләргә килсәк, яңалары табылып торачак, чөнки конъюнктура, әдәп-әхлак кагыйдәләре, культура үзгәреп тора, – ди ул. – Чөнки бу сугыш – кешелек тарихындагы яхшылык белән явызлык көрәшенең иң югары концентрациядәге чагылышы булды.

Ул Җиңүнең 75 еллыгын каршы алырга ярты ел кала арабыздан китте. Армия генералы Мәхмүт Гәрәевне соңгы юлга 154 нче аерым комендант Преображенск полкының Почет каравылы ротасы озата барды. Ватанны саклаучылар пантеонында легендар конструктор – корал төзүче Михаил Калашников янында җирләнде.

Аның китаплары – югары төгәллекле коралы калды. Димәк, сугышчы Мәхмүт Гәрәев әле һаман да көрәшүен дәвам итә.

Мытищидагы федераль хәрби мемориаль зиратта армия генералы Мәхмүт Гәрәевнең каберенә куелган һәйкәл.

# АСЫЛ ЗИННӘТ

Руфия Фазылова

Зыялы кеше 100 яшендә дә зыялы булып кала. Егетләрчә төз гәүдә, һәр сүзне төгәл, урынлы итеп әйтү, кирәк вакытта мәзәк сүз кыстыру – 100 яшьлек бабай күз алдына киләме? Юк. Апас районы Шәмбалыкчы авылында яшәүче Зиннәт Хәйруллин исә безне әнә шулай шаккатырды. 1941 елның августында Бөек Ватан сугышына китеп, туган ягына 1947 елны гына әйләнеп кайткан Зиннәт ага ким дигәндә ике кешелек язмыш яшәгән.

## «АЛТЫ ЕЛ ЙӨРЕП КАЙТТЫМ...»

1941 елның 21 августында яшь егетнең кулына повестка тапшыралар. Ул вакытта Зиннәт Хәйруллинга 18 тулган була. Көне-сәгате белән дигәндәй Чувашиянең Канаш шәһәренә чыгып китә алар. Берничә көннән яшь солдатларны Чебоксарга күчерәләр. Әнә шунда ул беренче тапкыр кулына автомат тотып карый.

– Безне Чебоксарда атарга, тиз йөгерергә дә өйрәттеләр, – дип сөйләде Зиннәт ага. – Дүрт-биш кирпеч салынган капчыкны иңгә асып, егерме-утыз чакрым әйләнеп кайта идек. Ротабызда 28 кеше, барыбызга бер мылтык. Идел буена төшеп, шул мылтыктан чиратлашып аттык.

Октябрь урталарында тулы бер ротаны Мәскәү янына алып китәләр. Бөек Ватан сугышының иң авыр чоры – немецлар Мәскәүгә якынлашканнан якынлаша бара. Көчләр тигез түгел. Нәкъ менә шул чакта совет армиясенең бөтен көче башкаланы саклауга юнәлдерелә.

– Мәскәүдән 30 чакрым ераклыктагы бер авылны фашистлар басып алган да, безне чиркәүнең чаң манарасына менеп күзәткәннәр, – диде Зиннәт ага. – Ул чагында Мәскәүгә эшелон-эшелон солдат агылды, шул исәптән безнең 81 нче корпус та. Хәтерлим, Ерак Көнчыгыштан күп килделәр. Һәм шул көчләр белән немецларны Мәскәү янынннан куалап җибәрдек. Мәскәү яны, Тула, Калинин өлкәләре азат ителде. Һәлак булучылар да күп булды. Аннары Белоруссия, Польшаны азат иттек. Шуннан безне, исән калган солдатларны, Көнчыгыш Пруссиягә җибәрделәр. Аны үз вакытында немецлар Россиядән тартып алган була. Без менә Көнчыгыш Пруссияне яңадан Россиягә кайтару өчен көрәштек. 1945 елның 9 маен да шунда каршы алдык.

Зиннәт ага сөйли, ә мин шаккатып утырам: Бөек Ватан сугышында катнашкан күпме кеше белән очрашып та мондый төгәл, барысын да истә тотучы ветеранны күргәнем юк иде. Бөтен нечкәлекләренә кадәр хәтерли бит!

– Үзләре чигенгән вакытта немецлар кечкенә-кечкенә отрядлар калдырган, – диде әңгәмәдәшем. – Шуның өчен безне сугыш тәмамлангач та өйгә кайтарып җибәрмәделәр, яшьрәк, зур яралары булмаган солдатларны,

Фото: Лилиана Вәлитова

шул фашистлар белән көрәшергә калдырдылар. Алар төнлә белән казармада йоклаган солдатларга яки юлда барганда һөҗүм итәләр иде. Менә шундый фашист отрядлары белән безгә дә берничә тапкыр очрашырга туры килде.

– Алты елдан артык фронтта булып, берәр тапкыр яраландыгызмы? – дим Зиннәт агага.

– Яраландым. Бер генә дә түгел. Башыма снаряд кыйпылчыклары тиеп, бик озак дәваландым. Аягым да җәрәхәтләнде. Тик Аллаһының рәхмәте белән гел аякка бастым.

## «ГОМЕРЕМНЕ БАЛАЛАРГА БАГЫШЛАДЫМ»

Сугыш тәмамлангач та, Зиннәт Хәйруллин шулай ике ел иленә хезмәт итә. Аннан соң исә туган авылына кайта. Әти-әнисе янында өч айлап яшәгәннән соң, Казанга килеп заводта эш белешә, тулай торактан урын да ала. Тик әти-әнисе бу хәбәргә бик көенә. «Абыең да безне ташлап читкә китте. Инде син дә чыгып китсәң, без нишлик?» – дип, әни кеше күз яшьләре белән елый. Сугыш кичкән егет, болынга чыгып, хәтфә үләнгә ятып озак уйлана. Әнә шул көнне ул туган авылында калырга карар кыла. Өлкән яшьтәге ата белән ана, уларның аркасыннан сөеп: «Авылда да кеше булырсың. Озак, бәхетле яшәрсең, менә күрерсең. Без синә хәер-догада торырбыз», – ди.

Фәрештәләрнең амин дигән чагына туры киләме, әллә әти-әнинең ихлас теләкләре кабул буламы, Зиннәт Хәйруллин авылда гына түгел, район, республика күләмендә дан казана...

– Авылда калуымны күреп, ул чактагы мәктәп директоры Рәшит абый мине эшкә чакырды, – дип дәвам итте Зиннәт ага. – Хуҗалык эшләрен алып барырсың, диде. Мәктәптә бер ел эшләгәннән соң Рәшит абый миңа укытучылыкка укырга киңәш итте. Сугышка кадәр Алабуга шәһәрендә сәүдә техникумында ике ел белем алган идем. Шуннан документларны алып, Тәтеш педагогика училищесына читтән торып укырга кердем. 1950 елда училищены бары бишле билгеләренә генә тәмамладым. Һәм шул елны КДПИның география факультетына читтән торып укырга кердем. Биш ел шунда белем алып, чын мөгаллим булып чыктым.

Читтән торып уку дәверендә Зиннәт Хәйруллин Шәмбалыкчы төп белем бирү мәктәбендә география, астрономия фәннәрен укыта. Һәм шуңа төшенә: укытучы һөнәре аныкы икән! Яшь мөгаллимнең шул өлкәдә үсәсе килә: мәктәптә яңа укыту алымнарын өйрәнә башлый, балаларның белемен карточкалар ярдәмендә тикшерүне кертә. Мәскәүдән география фәнен укыту буенча махсус журналлар яздырып ала...

– Үзебезнең мәктәп каршында география мәйданчыгы оештырдым, – дип дәвам итте зур тәҗрибәле мөгаллим. – География фәнен тирәнтен өйрәнү өчен махсус приборлар сатып алдым, кайберләрен кулдан да ясадык. Мәктәпнең үз остаханәсе бар, әнә шунда эшләүче Исхак абыйның кулы алтын иде. Ул безгә бик ярдәм итте. Мәктәп каршына флюгер урнаштырдык, махсус будкалар ясадык. Районның башка бер генә мәктәбендә дә мондый мәйданчык юк иде. Безгә хәтта күрше районнардан да килеп өйрәнә башладылар.

Хәләл җефете Саимә Искәндәр кызы белән.

Зиннәт ага газета-журналлар белән дә даими элемтәдә тора. Укытучылар өчен ул язган дәрес конспектлары Мәскәү журналларында басыла. Балалар белән оештырылган экспедицияләре турында республика газета-журналларында таныштырып бара. (Идел буенча гына да балаларны берничә тапкыр сәяхәткә алып чыга ул.) Кыскасы, тынгысыз мөгаллим, үз эшенең фанаты була ул.

– 1972 елда Шәмбалыкчы мәктәбе башлангычка калды, – ди әңгәмәдәшем. – Һәм без укучылар белән күрше Морзалар урта мәктәбенә

Укытучылар съездында.

ЗИННӘТ КӘЛИМУЛЛА УЛЫ ХӘЙРУЛЛИН – СУГЫШ ВЕТЕРАНЫ, КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ, I ҺӘМ II ДӘРӘҖӘ ВАТАН СУГЫШЫ ОРДЕННАРЫ КАВАЛЕРЫ, ТАТАРСТАННЫҢ АТКАЗАНГАН УКЫТУЧЫСЫ, РСФСР МӘГАРИФ ОТЛИЧНИГЫ.

кү̆чтек. Анда мине укыту эшләре буенча директор урынбасары итеп куйдылар. Шәмбалыкчы мәктәбендә дә күп еллар завуч булып эшләдем. Бик сагынам шул чакларны... Дүрт тапкыр бөтен Союз күләмендә Мәскәүдә үткән укытучылар конференциясенә барып чыгыш ясадым. РСФСР күләмендә оештырылган конференцияләрдә дә катнашып, докладлар сөйләдем. Тик тормый идем инде. Хәләл җефетем Саимә Искәндәр кызы да укытучы булгач, бер-беребезне бик аңлап яшәдек. Безнең өйдә төп тема мәктәп булды.

## МУЗЕЙ ДИРЕКТОРЫ

Лаеклы ялга чыккач та, Зиннәт Хәйруллин мәктәптә эшләвен дәвам итә. 1990 елны исә, яраткан һөнәрен калдырып, икенче юнәлешкә кереп китә.

Шәмбалыкчы татар дөньясына ике атаклы опера җырчысын биргән авыл – Фәхри Насретдинов белән Бану Вәлиеваны. Ләкин Шәмбалыкчы авылында әлеге данлыклы авылдашларына багышланган истәлекле бер урын да булмый. Зиннәт абый бу турыда күптән уйлап, шуңа борчылып йөри, тик мәктәптә эшләгәндә моның белән шөгыльләнергә җай чыкмый. Ниһаять, лаеклы ялда Шәмбалыкчыда атаклы опера җырчыларының исемен мәңгеләштерү артыннан йөри башлый.

– Бану Вәлиева безнең нәселдән, – диде Зиннәт ага. – Уфадан кайткан чакта безгә килми калмый иде. Фәхри абыебыз да онытылмасын дип, бу зур эшкә алынырга булдым. Район җитәкчелегенә дә әйттем. Фәхри абыйның туганнары белән дә элемтәгә кердем. Алай каршы килүче булмады, ләкин ярдәм итәм дип ашкынып торучы да табылмады.

Ярдәм итүчеләрне ул Казаннан таба. Кайчандыр Фәхри абый, Бану апа эшләгән Татар дәүләт опера һәм балет театрына барып керә. Театр музее җитәкчесе Рәмзия Такташ (Һади Такташның килене) Зиннәт абыйны дикъкать белән тыңлый һәм аның идеясен хуплый. Нәтиҗәдә, шул көнне үк Зиннәт ага Шәмбалыкчыга Фәхри абыйның концерт костюмын, Бану апа басып йөргән келәмнәрне алып кайта, шул исәптән дистәләгән фотосурәтне дә кулга төшерә.

– Рәмзия Такташ исенә төшерде: Фәхри абыйның дус фотографы булган, – диде Зиннәт ага. – Шул фотограф циркта эшли икән. Шуны эзләп, Казанның Ирек мәйданыннан циркка кадәр җәяү киттем. Фотографны эзләп таптым. «Фотоларым шактый, негативларда сакланган сурәтләр дә күп, мин сезгә аларны бик рәхәтләнеп тапшырам», – диде дусты. Шулай итеп, Казанга икенче килүемдә Фәхри абыйның әллә никадәр эксклюзив фотоларын алып кайттым.

Шәмбалыкчыда атаклы опера җырчыларына багышланган музей әнә шулайрак оеша. Башта музей кулак дип авылдан сөрелгән Хәлил абзый йортында эшли. Ике елдан соң Шәмбалыкчыда яңа мәдәният йорты ачыла. Шуның ике бүлмәсен музейга бирәләр. Авыл кешеләре дә канатланып китә – үзләрендә булган борынгы әйберләрне берәм-берәм музейга тапшыралар.

– Тиз арада ТР Милли музее белән дә дуслык күпере урнашты, – ди Зиннәт ага. – Казанга барып, башта үзләре белән таныштым. Аларны Шәмбалыкчыга – үзебезнең музейга чакырдым. Алар миңа музей фондын рәсми рәвештә теркәргә, алып барырга өйрәтте. Нәтиҗәдә, без рәсми рәвештә музей исемен алдык.

Үзе ачкан музейда 20 ел эшли Зиннәт абый. Шул гомер эчендә ике меңнән артык экспонат туплый. Арада затлылары да бар – Фәхри Насретдинов белән Бану Вәлиеваның шәхси киемнәре, аларның тавышы яздырылган пластинкалар, мәшһүр җырчылар көндәлектә кулланган предметлар...

– Зиннәт ага, сез бит әле дә егетләр кебек. Ни өчен музей эшен ташладыгыз? – дидем аксакалга.

– Үз теләгем белән китмәдем, кызым... 2010 елга минем урынга кеше куйдылар. Яшем зур дигәннәрдер. Шулай да бер ел буе музейны сагынып йөрдем. Хәтта экспонатлар төшемә керә иде.

## ТЫНГЫСЫЗЛЫК...

Тынгысыз кеше шул Зиннәт ага. Бүген ул үз өен музей иткән. Монда һәр картина, һәр предметның астында язу бар. (Улларыннан компьютерда яздырган.) Чигүле сөлгеләр дә төрдә тора, алар да бүләк икән. Шулай ук кемнән икәнлеге язылган. Бабайның өендә фотолар ябыштырып ясалган плакатлар бихисап. Аларны карагач, балачакка, мәктәп елларына кайтып килгәндәй буласың.

Зиннәт ага җәмәгате Саимә апа белән өч ул үстергән. Ике улы гаиләсе белән Казанда, берсе Красноярскида яши. Ни кызганыч, 50 елдан артык бергә гомер кичергән хәләл җефете вафат инде. Бабай бүген ике улы карамагында. Кышын алар янына китеп тора, җәен исә уллары чиратлашып кайта.

– Әтинең колагы начар ишетә, соңгы бер елда күзләре начарланды, ә калган җиренә зарланмый, – диде Зиннәт аганың уртанчы улы Илгизәр абый. – Әти кыш беткәнен түземсезлек белән көтә – туган авылына кайтасы килә аның. Май аеннан октябрьгә кадәр үзгә кеше – шат күңелле ул. Казанда исә боегып кала, көннәрне саный башлый. Авылдан киткәндә, яшәгән йортының бүрәнәләренә кадәр сыпыра...

– Зиннәт ага әти буларак нинди иде? – дим.

– Әйбәт булды. Без зыялы гаиләдә үскән бәхетле балалар. Дәрес әзерләгәндә әти аңлата иде. Безнең өчен авторитеты зур булды. Хәзер дә шулай – әти сүзеннән чыкмыйбыз.

Июнь аенда бик зурлап Зиннәт аганың 100 яшьлек юбилеен уздырганнар. Район мәдәният хезмәткәрләре бабайның капка төбендә махсус концерт куйган. Матур бәйрәмгә Апас районы башлыгы Айрат Җиһаншин килеп, Зиннәт агага ихлас теләкләрен җиткергән. Монысы медальнең бер ягы. Ләкин аның икенче ягы да бар – Шәмбалыкчыда юллар начар. Ветеран яши торган йортка килү өчен дә кыр юлыннан барырга кирәк. Язын-көзен ул юл өзелә. Ә авыл уртасындагы юлдан йөрү өчен күпер чыгасы бар. Тик ул агач күпер ватык, машина белән түгел, җәяү йөрергә дә куркыныч. Бу мәсьәлә безне генә түгел, бөтен авыл халкын борчый булып чыкты.

– Күперне якын көннәрдә ясыйбыз, – дип вәгъдә бирде Шәмбалыкчы авыл җирлеге башлыгы Физзәт Миңнуллин. – Авыл җирләре «Ибраһимов һәм К» хуҗалыгына карый. Аның җитәкчесе Таһир Ибраһимов бу проблеманы хәл итәргә алынды. Илле ике мең сумга шпалларга заказ бирелгән, китергәннәрен көтәбез. Аннары күперне сүтеп, тиз арада эшләргә дип сөйләшенде.

– ӘТИ КЫШ БЕТКӘНЕН ТҮЗЕМСЕЗЛЕК БЕЛӘН КӨТӘ – ТУГАН АВЫЛЫНА КАЙТАСЫ КИЛӘ АНЫҢ. МАЙ АЕННАН ОКТЯБРЬГӘ КАДӘР ҮЗГӘ КЕШЕ – ШАТ КҮҢЕЛЛЕ УЛ. КАЗАНДА ИСӘ БОЕГЫП КАЛА, КӨННӘРНЕ САНЫЙ БАШЛЫЙ. АВЫЛДАН КИТКӘНДӘ, ЯШӘГӘН ЙОРТЫНЫҢ БҮРӘНӘЛӘРЕНӘ КАДӘР СЫПЫРА...

...Һәр авылның үз аксакалы, тарихка кереп каласы кешеләре була. Шәмбалыкчыда ул, һичшиксез, Зиннәт ага Хәйруллин. Җырлый, шигырьләр иҗат итә. Әле «Балкыш» фестивалендә катнашмый башлаганына ничә генә ел. (Берничә тапкыр лауреат та булган.) Гомере буе туган авылына хезмәт иткән, аның кешеләрен белемле, зыялы итү өчен бөтен көчен куйган тынгысыз Зиннәт агага чын күңелдән исәнлек телибез. Тагын күп җәйләрне туган ягында уздырырга язсын аңа...

Зиннәт ага уллары һәм оныгы белән.

# ЯКТЫ ШӘХЕС – БИЕК ҮРЛӘР

Нефтьчеләр нәселе вәкиле булган Наил Мәганов илнең иң нәтиҗәле топ-менеджерлары исемлегенә керә. Аның профессиональлеге, югары һөнәри осталыгы, бурыч-максатларны төгәл ачыклап, аларны хәл итү юлларын билгели белү сәләте Татарстандагы бюджетны формалаштыра торган төп предприятиенең бүгенге һәм киләчәк уңышлары нигезен тәшкил итә.

**Рәүзил Хаҗиев,**
«Татэнерго»
АҖ генераль
директоры

Ун елдан артык Наил Өлфәт улы җитәкләгән «Татнефть» компаниясендә аның шәхесенең киң колачлылыгы, идарәчелек таланты һәм иң яхшы эшлеклелек сыйфатлары, киләчәкне күрә һәм куелган максаткаирешә белүе бик ачык чагыла. Тормышта максималист буларак, ул коллектив алдына да иң югары бурычларны куя, нәтиҗәдә алар уңышлы гамәлгә ашырыла. Бүген «Татнефть» компаниясенең углеводородлар чыгару күләме буенча Россиядәге әйдәп баручы нефть-газ компанияләре арасында беренче бишлеккә керүе һич тә очраклы түгел, ә компаниянең лицензия алынган участокларында расланган нефть запаслары 800 миллион тоннадан артып китә. Хәтта бүгенге катлаулы чорда да биредә озак вакытка исәпләнгән программаларны гамәлгә ашыру туктатылмый, чөнки алар киләчәктә компаниянең уңышлы үсешен тәэмин итәчәк. Аерым алганда, нефть һәм газ разведкасы һәм нефть чыгару эшләре күләме ел саен тотрыклы рәвештә үсә бара: әгәр 2021 елда 154 яңа бораулау скважинасы корылган һәм куллануга тапшырылган булса, 2022 елның 12 аенда бу сан 796 га җитә!

«Татнефть» һәм бөтен Татарстан өчен мөһим вакыйга – компаниянең нефть эшкәртү буенча алдынгылар рәтенә чыгуы да Наил Өлфәт улы исеме белән бәйле. Бу уңышлы эш бюджет керемнәрен сизелерлек арттырырга мөмкинлек бирде. Бүген ТАНЕКО комплексы Татарстанның 16 миллион тоннадан артык нефтен эшкәртә. Нефть эшкәртү заводлары комплексын төзү буенча 2005 елда башланган глобаль проектны гамәлгә ашыруда инициаторларның һәм иң актив катнашучыларның берсе ул вакытта «Татнефть» ГАҖ генераль директорының беренче урынбасары вазыйфасын башкарган Наил Мәганов булды. Наил Өлфәт улы компания җитәкчесе булуга ук, киң колачлы модернизация үткәрелде. Бу исә нефть эшкәртүне арттырырга, ә соңрак, заводның куәтен үстереп, хәтта икеләтә күбәйтергә мөмкинлек бирде. Бүген ТАНЕКО югары көндәшлеккә сәләтле, экологик чиста продукциянең 20 ләп төрен җитештерә, шул исәптән «Евро-5», «Евро-6» стандартларына туры килә торган автомобиль бензинын һәм дизель ягулыгын, авиация керосинын, югары индексны төп майларны һәм автомобиль майларын чыгара.

Хәер, нефть эшкәртү компания җитәкчелеге ниятләре буенча кызу темплар белән барган бердәнбер үсеш ноктасы түгел. Әйтик, нефть-газ химиясе юнәлеше ерак киләчәк өчен җитди потенциалга ия, бөтен ил буйлап һәм чит илләрдә ягулык салу станцияләре челтәре уңышлы үсә, ә «Татнефть» АҖнең Калининградтагы «Экопэт» бүлендек компаниясе Россиядә һәм Көнчыгыш Европада полиэтилентерефталат (ПЭТФ) җитештерү буенча иң эре предприятие дип танылды.

Барысын да санап бетерерлек тә түгел. Әмма шунысын билгеләп үтәргә кирәк: алдынгы топ-менеджер – Наил Мәганов җитәкчелегендә уйланылган һәм уңышлы үтәлеп килгән барлык проектларның максаты татарстанлыларның тормыш дәрәҗәсен үстерүдән гыйбарәт. Республиканың көньяк-көнчыгышында «Татнефть» тарафыннан максатчан рәвештә гамәлгә ашырыла торган күпсанлы социаль программалар да шуны дәлилли. Әлеге программалар ярдәме белән Татарстанның нефть башкаласы, бистәшәһәрләребез матурая, яшәү өчен уңайлырак, заманчарак була бара.

*– Хөрмәтле Наил Өлфәт улы!*

*Сезнең бөтен тормышыгыз – республикага, аның халкына риясыз хезмәт итү үрнәге ул. Сезне чын күңелдән туган көнегез белән котлыйм һәм киң колачлы бурыч-максатларны хәл иткәндә, чын профессионалларның, рухи яктан якын фикердәшләрнең һәрвакыт янәшәгездә булуын телим!*

Фотолар: «Татэнерго» АҖ, tatar-inform.ru. РЕКЛАМА

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU



# ТАҢ КАЛДЫРА ТАКТАЛАЧЫК

Фото: Александр Ефремов

# ТАКТАЛАЧЫК

Татарстан, әлбәттә, матур урыннарга бай, әмма искиткеч матурларына ул тагын да баерак. Такталачык авылы кебек оҗмах почмагына килеп эләккәч, моны тагын да шәбрәк аңлый башлыйсың.

Татьяна Вафина

– Әйдәгез, мин сезгә ташларны күрсәтәм! Бездәге кебек ташлар башка беркайда да юк! – дип каршы алды безне Такталачык авыл җирлеге башлыгы Марс Мансуров.

## ТАШ ИСТӘЛЕКЛӘР

Һәм без шул ташларны карарга юл тотабыз. Гарәп язулары сырланган ике борынгы кабер ташын авыл уртасына урнаштырганнар, бу урынны пөхтә итеп коймалап та алганнар...

– Морзаларны (татар дворяннарының иң югары катлавы – ред. иск.) әнә шулай җирләгәннәр, – дип аңлата экскурсоводыбыз.

Янәшәдә шундый ук ике һәйкәл тора. Беренчесе – 1702 елдан бирле билгеле булган бу авылга нигез салучыларның берсе, Мутиннар нәселенең ата-бабасы, Гәрәй волосте старшинасы Тимергә багышлап куелган. Җиде еллык сугышта катнашкан һәм башкорт халкының вотчиналык хокукларын яклаган әлеге шәхес 1759 елда бакыйлыкка күчкән. Икенче һәйкәл шул ук нәсел вәкиле, заманында башкорт хөкүмәте һәм Башревком әгъзасы, Башкорт хәрби шурасы рәисе булган Илдархан Мутин истәлегенә урнаштырылган.

– Монда авылыбыз каһарманнары яки дан аллеясы ясыйсым килә, – ди Марс әфәнде һәм бала чактан ук бу якларны җирдәге иң шәп урынга әйләндерү турында хыяллануын да әйтә.



1

Таш – кайчандыр шушы урында торган мәктәпнең символы ул.

2

– Ә монысы балалар мәйданчыгына виртуаль капка, – дип көлә авыл җирлеге башлыгы.

*Күпме еллар монда балкып торды*
*Мәгърифәтле белем учагы!*
*Сихри урын һаман үзенә тарта*
*Яшь буынны, җәеп кочагын!*

## ХЫЯЛЛАР, ХАТИРӘЛӘР

Чираттагы тарихи таш янына тәпилибез. Марс Тимерхан улы аны үзе генә белгән яшерен көчләр ярдәмендә вак ташлардан өелгән тау өстенә күтәртеп куйган. Таш – кайчандыр шушы урында торган мәктәпнең үзенә күрә бер символы ул. Авыл башлыгы монда укыган вакытларын, кайда нинди кабинет булганын, тиктормас малай чагында ни-нәрсәләр майтарганын искә төшереп ала. Мондый күңелле хатирәләрне тыңлау һәрвакыт кызык, балачакка кайтасы килә башлый... Теләк булганда, «кайтып» килергә була ул, дип саный Такталачык мәктәбенең элеккеге укучысы Марс Мансуров һәм кайчандыр мәктәп торган урында авыл халкы тырышлыгы белән корып куелган балалар мәйданчыгын күрсәтә. Монда таганы да, каруселе дә, шуып төшәр өчен таучыклары да бар. Әле тагын төзиселәрен, корасыларын җирлек башлыгы инде күптән уйлап йөри, димәк, алары да булачак.

## БАЛАЧАККА ВИРТУАЛЬ КАПКА

– Ә монысы балалар мәйданчыгына виртуаль капка, – дип көлә җирлек башлыгы.

«Виртуаль» дисә дә, чынлыкта ул бар, юлы да шул капкага илтә. Тик бу капкага бернинди койма да, дивар да тоташып китмәгән – каян телисең, шуннан керергә, шунда уйнарга була... Әмма мәйданчыкка барыбер шушы капка аша керәләр икән.

– Төзегән чакта: «Нигә кирәк инде бу? Балалар чыр-чу киләчәк, чүпләп бетерәчәкләр», – дип сөйләгән кешеләр дә булды. Бер дә алай түгел, үзләреннән соң җыештырып калдыралар, моның өчен мәйданчыкка чүп савытлары куйдык. Чыр-чуга килгәндә исә, шуңа да бала-чага бит инде алар! Баштарак алар гомумән безнең өйгә, минем балалар янына киләләр иде. 25 ләп малай-шалай җыелган чаклар булды! Өйдә чып-чын балалар бакчасы диярсең. Һәркайсы минем белән зурларча, кул биреп күрешә. Мин дә һәрберсе белән исәнләшеп чыгам – 25 тапкыр бит ул. Ә башкача була да алмый! Алар авылның киләчәге бит – монда алар яшәячәк, алар эшләячәк, алар төзиячәк, алар җитәкчелек итәчәк! Шулай булгач, ник әле аларны каядыр авыл читенә куып чыгарырга, ди? Минә шушында, күз алдымда уйнасыннар!

## БАКЧА АРТЫНДА

Кеше кулы белән ясалган истәлекле урыннарны карап чыккач, табигатьнекен багарга юл тотабыз.

3

– Бу – тегермән ташы, – ди Марс әфәнде, ташны йомшак кына сыйпап.

4

Һәм менә, рәхим итегез, – Актаныш районының Такталачык авылында чып-чын кунакханә.

Кайбер манзараның матурлыгын күреп, тын да алырга куркып торасың! Шундыйларның берсе – Сабан туе урыны. Хәтфәдәй яшел, типтигез басу... Кайдадыр еракта, тыныч табигать сурәтләнгән картинадагы шикелле, сыерлар утлап йөри... Офыкта исә ниндидер шәһәр йортлары шәйләнә...

– Агыйдел шәһәре ул, Башкортостан җире, – дип аңлата экскурсоводыбыз. – Ул Агыйдел елгасы буенда салынган, исеме дә шул хөрмәткә бирелгән.

Карашыбызны якынгарак күчерәбез – кечкенә сәхнәсе, утыргычлары булган мәйданчык уратып алынган. Биеклектән курыкмаган кыюлар Сабан туенда әтәч алырга менә торган багана да шунда...

## ТАГЫН БЕР ТАШ

Сабан туе мәйданчыгы тирәсендә дә безне тагын бер истәлек каршы ала. Монысы – түгәрәк зур таш, авырлыгы да шактый булса кирәк.

– Бу – тегермән ташы, – ди Марс әфәнде, ташны йомшак кына сыйпап. – Миңа аның өчен бер миллион сумга якын акча да тәкъдим итеп карадылар, барыбер сатмадым. Чөнки бу – безнең тарих, ә тарих сатылмый!

Җирлек башлыгы бу ташның кайчандыр иске тегермәндә ятканлыгы; 70 нче еллар башында кемнеңдер аны урларга маташуы, әмма колхоз рәисенең, бу хакта белеп алгач, ташны кире урынына кайтарырга кушуы; аны үзенең очраклы рәвештә ташландык тегермәндә табып алуы, чүп-чардан чистартуы; ташны монда грейдер белән алып килүләре, урнаштырулары турында сөйләде.

Хәзер бу урын – Сабан туеның төп фотозонасы, таш янында фотога төшми калмыйлар. Ә җирле шагыйрә Гәүһәрия Мусина хәтта шигырь дә чыгарган:

*Чорлар аша, бик күп еллар аша,*
*Хәтер шушы ташка тоташа.*
*Икмәк белән бергә сагышларын*
*Тарттыргандыр халкым җыр аша...*

## АВЫЛ МАСШТАБЫНДАГЫ КУНАКХАНӘ

Шәһәрдә гадәти күренеш дип саналган нәрсә авыл җирлегендә үзеннән-үзе истәлекле урыннар рәтенә керә. Дөресен генә әйткәндә, Татарстанда бик күп авылларны гизәргә туры килсә дә, аларда шәһәргә хас истәлекле урыннар безгә бик сирәк очрый иде. Шундыйлардан Аксубай районы Түбән Баланда авылындагы фонтан хәтергә килә. Кукмара районының Нырья авылында шәһәрнекеннән бер дә ка-

5

– Мин кул белән эшлим, ә хатыным – баш белән, – ди Рөстәм Вәлиев, кунакларга түгәрәк агач телемнәре белән матур итеп авыл стилендә бизәлгән мәҗлесләр залын күрсәткәндә.

лышмаган кафе эшли. Һәм менә, рәхим итегез, – Актаныш районының Такталачык авылында чып-чын кунакханә. Әлеге мөсафир йорты да, шунда ук эшләп торган ресторан да – җирле эшмәкәрләр Гүзәл һәм Рөстәм Вәлиевләрнең хезмәт җимеше.

– Мин кул белән эшлим, ә хатыным – баш белән, – ди Рөстәм Вәлиев, кунакларга түгәрәк агач телемнәре белән матур итеп авыл стилендә бизәлгән мәҗлесләр залын күрсәткәндә.

– Иҗади фикерле торган яхшы баш эләккән, – дип соклана фотографыбыз, черт тә черт фотоаппаратына баскалап.

– Мин Актанышның үзеннән. Ә хатыным шушы авылныкы, – дип дәвам итә Рөстәм. – Өйләнештек тә монда күчендек. Миңа монда кызыграк. Шәһәрдә матур киенеп, паркта йөрергә кирәк – андый нәрсә минем өчен түгел. Мин эшләргә яратам, ә монда кызыклы эш бик күп. Башта «КАМАЗ» машинасын йөрттем, ә хатыным укытучы иде. Аннары үз эшебезне ачарга булдык...

Ялгышмасак, Вәлиевләрнең эше бик уң бара.

## ТАКТАЛАЧЫК КҮЧТӘНӘЧЕ

– Хәзер монда чират, – ди авыл башлыгы. – Кемдер юбилеен бәйрәм итәргә тели, кемдер туй уздыра. Чыгарылыш кичәләре, туган көннәр, дисеңме... Барысының да монда киләсе килә. Чөнки урыны да уңайлы, бинасы да матур, ризыклары да тәмле. Ә бу тирәдән узып йөргән шоферлар, нефтьчеләр һәрвакыт монда куна кала. Алар өчен әнә мунча да әзер тора. Ә монда нинди тәмле ипи пешергәннәрен белсәгез! Бөтен якын-тирәдән ипи алырга бирегә киләләр. Үзләре өчен эшлиләр бит, кешеләр өчен!

Тышы кетердәп торган хуш исле ак ипидән гыйбарәт ошбу күчтәнәчне үзебез белән алып китәбез. Такталачык исемле матур, бай һәм мул ризыклы авыл барлыгы турында сөйләгәндә, өйдәгеләрне сыйларбыз.

## АВЫЛГА НИГЕЗ САЛУЧЫЛАР НӘСЕЛЕ

Гомумән, авылда эшкуарлык сәләте һәркемгә бирелгән.

– Эшләргә теләгән кешене эш үзе таба ул, бездә зарланып ятарга вакыт юк, – диде безгә Марс әфәнде, авыл белән таныштырып йөргәндә. Такталачыкта өйләр берсеннән-берсе матур, хуҗалыклар нык, җиренә җиткереп, зур итеп салынган. 1929 елда оешкан «Таң» колхозы, төрле чорларны, төрле сәяси стройларны күргән, бик күп җитәкчеләрне алыштырган, барлык дефолт, кризис һәм башка тетрәнүләрне кичергән булса да, һаман да яши бирә.

Хәер, җирле халыкка шундый урынны һәм шундый колхозны юкка чыгару, таркату оят та булыр иде. Чөнки бу авылга нигез салучылар һәр эштә зирәклекләре, елгырлыклары белән аерылып торган.

## МУТЯ ҺӘМ МУТИННАР

Мутиннар нәселенә нигез салучы булып 1743 елдан бирле билгеле Мутя Янурусов (Енарусов) санала. Ул Гәрәй волостеның старшинасы була. Кайчак хакимияткә Мутяга каршы, аны закон бозуда гаеплэп, шикаятьләр язганнар. Документларны укыйбыз:

*«1743 елда Гәрәй олысы башкорты Үтәгән Ичибаев аларның вотчина җирләренә рус крестьяннарын кертү, алардан законсыз рәвештә оброк җыю, шулай ук тоткан балыктан һәм вотчина җирләреннән 300 башкорт хуҗалыгыннан 120 сум, 20 пот чикләвек, 2 пот йон, 100 аршын киндер тукыма җыюлары турында яза».*

Мутя нәселе законсыз гамәлләрдә телгә алынмый, тормышта закон кысаларыннан чыкмыйча гына эш йөртә:

*«1751 елда Гәрәй олысының Такталачык авылыннан йөзбашы Тимер Мутин (Мутя улы) иптәшләре белән Каракүл олысының сарай крестьяннарына Җәкалҗә (Юрмалы) күлендә балык тоту хокукын елына 1 сум 50 тиен түләү бәрабәренә 10 елга арендага бирә. Тимернең улы да җәмәгать эшләрендә активлык күрсәтә. 1763 елда Гәрәй олысының Такталачык авылы старшинасы Атнагол Тимеров һәм 8 башкорт, шулай ук башка авыл вәкилләре Шәбез (Моховое) күлен еллык 12 сум хисабыннан 20 елга Каракүл олысының сарай крестьяннарына бирә, аларына «һәртөрле балык тоту җайланмалары һәм ятьмәләр белән җәен дә, кышын да балык тотарга, елым тартырга, ятьмәләр белән бүлеп куярга» рөхсәт ителә».*

*«Мутя Е (Я) нурусовның икенче улы бу эштә туганнарыннан калышмаган. 1762 елда, волость старшинасы булгач, Такталачык авылыннан Кунур Мутин иптәшләре белән халык телендә Ялан дип йөртелгән Кабан (хәзер Башкортостанның Краснокама районына карый – ред. иск.), Инеш-Түбә һәм Агыйдел аръягындагы Карыш Әрәмә күлләрендә балык тоту хокукын сарай крестьяннарына 20 елга арендага бирә…»*

Тимердән башлап, Такталачык авылына нигез салучылар колачлырак фикер йөртеп, югарырак дәрәҗәдә эш йөрткән:

*«Мутя улы Тимер (булачак «авыл каһарманнары аллеясы»нда без күргән һәйкәл нәкъ менә аның истәлегенә куелган – ред.иск.) 1759 елда, императрица Елизавета Петровнага тугрылыгын белдерергә дип, Санкт-Петербургка кадәр барып җиткән башкорт халкы делегациясе составында була. Ул иптәшләре белән бергә, Сенатка хат юллап, башкорт җирләренең басып алынуын тыюны, аларның сатылуы турындагы купчий кәгазьләренең бөтен волость халкы ризалыгы белән генә раслануын сорый. Шул ук вакытта Сенат, Тимернең үтенечена тиз арада колак салып, Оренбург губерна канцеляриясенә указ җибәрергә боера. Анда исә: «Моннан ары башкорт халкын берничек тә рәнҗетмәскә, таламаска, аларның җирләренә көч кулланып барып урнашмаска, һәм шуның белән әлеге башкортларны яклау гына түгел, ә аларга һәртөрле илтифат күрсәтергә, указларга яраклы рәвештә сакларга», – дип язылган була.*

## ТАКТАЛАЧЫК СҮЗЛЕГЕ

**Кайчандыр Такталачыкта гомер кичергән кешеләрнең кайсы катлауга (сословиегә) караганын барлаганда, безгә махсус сүзлек кирәк дигән нәтиҗәгә киләбез, чөнки монда шулкадәр буталып беткән ки, сүзлексез төшенү мөмкин түгел.**

Мәсәлән, 1795 елда Такталачыкта «67 йортта 422 **АСАБА (ВОТЧИННИК) БАШКОРТ** яшәгән». XVI гасырның икенче яртысыннан XIX гасырга кадәр Көньяк Урал буеның төньяк-көнбатыш өлешендәге җир биләүгә мирас хокукына ия булган халыкны әнә шулай атап йөрткәннәр. Асаба башкортлар катлавын формалаштыруда төрле этник төркемнәр: иштәкләр, ногайлар, татарлар, фин-угорлар һәм калмыклар катнашкан. Рус хөкүмәте, кайсы милләттән булуына карамастан, барлык асабаларны да «башкорт» сүзе белән атаган.

1902 елда Такталачыкта «391 йортта 1345 **ӘТӘМБИ (ПРИПУЩЕННИК)** яшәгән. Башкорт общиналарына караган җирләргә күчеп килгән җирсез башкорт, татар, чуваш һәм мариларны шушы сүз белән атап йөрткәннәр.

Моннан тыш, Такталачыкта **ТИПТӘРЛӘР** дә яшәгән. «1816 елда – 89, 1834 елда – 119, 1850 елда 162 типтәр ир-ат булган». Кемнәр соң алар һәм каян килгәннәр?
TATARICA энциклопедиясе мондый билгеләмә бирә:
«XVIII гасыр башында әтәмбиләр типтәрләргә (татарлар, чувашлар, башкортлар) һәм бобыльларга (марилар, удмуртлар, мордвалар) бүленгән.
Типтәрләр хәрби-йомышлылар һәм дәүләт крестьяннары катлаулары арасындагы урынны биләгән. 1790 нчы елларда типтәрләр хәрби-йомышлы халык разрядына күчерелә.
2 типтәр полкы 1835 елга кадәр гамәлдә була.
Типтәрләр, башлыча, Агыйдел елгасының түбән агымы буенда, Ык елгасы бассейнының көнбатыш өлешендә, башкорт-вотчинниклар арасына килеп урнашалар, башкорт авылларында җирлекләр («очлар») хасил итәләр.

Такталачыкта 1816 елда – 14, 1834 елда 20 **КҮП НИКАХЛЫ ГАИЛӘ** булган. Төрле чыганаклар күпникахлылык ир-атның - берничә хатыны, хатын-кызның берничә ире булуын белдерә дип аңлата. Әмма Такталачыкта, мөгаен, полигам никахның бер төре саналган күпхатынлылык, яки полигиния күзәтелгәндер, мондый очракта ир-ат бер үк вакытта берничә хатын белән никахта яши. Бу исә Такталачык авылында шактый бай ир-атлар тормыш кичергәнен белдерә. Чөнки күпхатынлылыкны рөхсәт иткән Коръәнне генә искә төшерү дә җитә, анда барлык хатыннарны да бертигез дәрәҗәдә тәэмин итеп торырга кушыла. Марксизмга нигез салучыларның берсе – Фридрих Энгельс исә: «Күпхатынлылык – байлар һәм аксөякләр гамәле ул», – дип ассызыклаган.
Бу карашны этнограф Петр Кудряшев (1797–1827) та хуплый, ул: «Бик сирәкләрнең генә бердән артык хатыны бар, чөнки фәкыйрьлек дин рөхсәт иткән нәрсәдән файдаланырга мөмкинлек бирми», – дип яза. Россия географы һәм төбәк тарихын өйрәнүче Василий Черемшанский (1821–1869): «Башкортларда, гомумән, барлык мөселманнарда кебек үк, байлар икешәр яки өчәр хатын тота, ә ярлыларныкы берәү генә була», – дип тәгаллек кертә.

6

Такталачык авылының атаклы мәчетләре.

7

Балыгы да, кысласы да бергә килешеп яшәп яткан буа.

8

1914 елда төзелгән земство хастаханәсе бинасы. Бөек Ватан сугышы вакытында бирегә хәрби госпиталь урнашкан була.

Гомумән, күрсәткән барлык хезмәтләре өчен Мутиннар нәселе Уфа губернасы дворян нәселләре шәҗәрәсе китабының 2 нче өлешенә кертелгән (1900).

Ә Такталачык авылы мәктәбендә бу җирлектән чыккан атаклы кешеләргә багышланган музей бар, ул Мөхтәр Мутин исемен йөртә. Драма актеры, ТАССРның атказанган артисты Мөхтәр Мутин профессиональ татар театрын булдыруга зур өлеш кертә. 1926 елда ул «Татар театры» китабын яза, ә 1937 елда «троцкийчылык оешмасы» әгъзасы буларак репрессияләнә, 10 елга ирегеннән мәхрүм ителә һәм Магадан өлкәсендәге лагерьда һәлак була.

Такталачык – күренекле татар әдибе, ТАССРның халык шагыйре Гамил Афзалның туган ягы. «Айлы кичләр» шигырьләр җыентыгы һәм «Борылам да карыйм» шигырьләр циклы өчен 1974 елда аңа Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе тапшырыла.

**НИЧЕК БАРЫРГА:**

Дөресен әйтик, Такталачык Казаннан шактый ерак - 347 километр. Актаныш район үзәгенә караганда бераз гына якынрак. Ләкин бу сәфәр үкенерлек булмаячак. Кызыклы тарих турында тыңлап, кайнар ипи ашап, мондагы табигатькә сокланып кайту үзен аклый.

**КАЙДА ТУКТАЛЫРГА:**

Төн куну һәм яшәү урыны белән проблема юк. «Авылда кунакта» кунакханәсе теләсә кайсы юлчы һәм туристны кабул итәргә әзер.

**НӘРСӘ ЭШЛӘРГӘ:**

Әлбәттә, чишмәгә барып килергә, чөнки Такталачык авылы чишмәсе дәвалау үзлегенә ия. Су ике торбадан ага. Уңдагысы – күз авыруларын, сулы тән авыруларын дәвалый. Гомумән, бөтен авырулардан шифалы алар. Бирегә, дәва эзләп, бөтен Татарстаннан һәм күрше Башкортостаннан киләләр. Без дә дәваланып алдык. Югач ачылып киткән күзләребез белән караган идек, моннан да матуррак һәм затлырак урын күргәнебез юк дигән нәтиҗәгә килдек.
Каршыбызда – авыл халкы чистартып, балык җибәргән буа, хәзер ул балык тоту өчен шәп урыннарның берсе буларак танылып килә. Өстәп әле кысласын да тотарга була. Алары монда буа буарлык, дип сөйлиләр.
Чишмәдән ерак түгел ялгыз каберлек бар. Анда бик күп еллар элек Мәккәдән өенә җәяүләп кайтып барган бер хаҗи күмелгән, диләр...

**НӘРСӘ КАРАРГА:**

Такталачыкта истәлекле урыннар җитәрлек. Мәсәлән, монда тарихи-мәдәни мирас һәйкәле – 1914 елда төзелгән земство хастаханәсе бинасы бар. Бөек Ватан сугышы елларында биредә хәрби госпиталь урнашкан.
Шунда ук, хастаханә территориясендә, Такталачык башлангыч мәктәбе укытучысы, 1919 елгы «сәнәк фетнәсе» вакытында җәзалап үтерелгән С.И.Фәйзуллинның каберен зиярәт кылырга мөмкин. 1984 елда аңа обелиск куелган.
Җирле зиратка барып килергә була. Анда Такталачык шәһәрлегеннән калган берничә кабер ташын күрерсез. Борынгылык белән кызыксынучы Марс Мансуров ул ядкәрләрне, туры мәгънәсендә казып алып, монда китереп урнаштырган.
Ә гомумән алганда, археологлар монда б.э.к. III гасырдан алып б.э. II гасырына кадәр булган пьянобор культурасына хас керамика калдыкларын тапкан. Такталачык җирлеге урынында төрле чорлардагы 350 дән артык каберлек табылган, шул исәптән чиялек культурасына караганнары – мәҗүсилек билгеләре күзгә бәрелеп торган мөселман каберлекләре дә бар, Күп кенә каберлекләрдә түгәрәк төпле савытлар, бизәнү әйберләре, мәет битлекләре, Алтын Урда ханнарыннан Үзбәк һәм Җанибәк хан тәңкәләре очрый...

**КЕМ ТУРЫНДА ТЫҢЛАРГА:**

Такталачык истәлекле урыннарга гына түгел, ә танылган кешеләргә дә бай. Мутиннардан соң монда күпме күренекле затлар яшәгән һәм яши! Алар арасында атказанган химиклар, физиклар, музыкантлар, педагоглар, археографлар, табиблар, шагыйрьләр, язучылар, сәнгать эшлеклеләре һәм аеруча күңеллесе – Ленар Шәех кебек журналистлар бар. Аңа каләмдәшләреннән ялкынлы кайнар сәлам!

## БӨЕК ПОЛКОВОДЕЦ, ДИОГЕН МИЧКӘСЕ ҺӘМ МЕҢЛӘГӘН РАРИТЕТ (6+)

Интерактив карта ярдәмендә Александр Македонский үткән шәһәрләр буйлап сәяхәт итәргә. Борынгы миф һәм риваятьләрне ишетергә. Македонский һәм Дарий патша төшерелгән зур пазлны җыярга. Македонскийның алты метрлы сөңгесен күтәреп карарга. Диогенның өенә керергә. Кисәкләрдән борынгы грек вазасын җыеп, аның исемен, ничек кулланылганын аңларга. Археолог роленә кереп, борынгы предметларны табарга. Бөек цивилизацияләрнең 2500 еллык тарихы белән танышырга... – болар Дәүләт Эрмитажы тупланмаларына нигезләнеп оештырылган «Александр Македонский. Көнчыгышка юл» күргәзмәсенә килгән кунаклар күрә һәм эшли алганнарның бары тик бер өлеше генә. «Эрмитаж-Казан» үзәге хезмәткәрләре экспозицияне балалар белән карарга теләүчеләр өчен махсус чек-лист та төзеде. Килегез, карагыз – үкенмәссез.

**18.30 дан 23.00 гә кадәр, «Эрмитаж-Казан» үзәге, 3 кат. «Казан Кремле» музей-тыюлыгы**



## ИРАНГА КЕЧКЕНӘ ГЕНӘ СӘЯХӘТ (6+)

Иң борынгы цивилизацияләрнең берсе белән танышу өчен әллә кайларга барырга кирәкми. «Минем Иран» күргәзмәсе моны Казанда эшләргә мөмкинлек бирә. Экспозициядә уникаль әйберләр, кулдан эшләнгән җәүһәрләр урын алган. Эмаль бизәк, агачтан уеп ясалган әйберләр, кыйммәтле ташлар белән бизәлгән предметлар, чүкү үрнәкләре, каллиграфия, келәм туку, «терме» техникасында тукылган тукымалар, миниатюра – боларның барысын да үз күзегез белән күрергә, Иран осталарының иң гүзәл иҗат җимешләренә сокланырга мөмкинлек бар. Шулай ук «галамзани», «терме», «минакари»,«хатамкари», «фирузекуби» кебек серле терминнарның мәгънәсенә төшенергә дә була.

**Кабул итү урыннарының күргәзмә заллары, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы**

Фотолар «Эрмитаж-Казан» үзәгеннән, tatar-inform.ru, ТР ДССМ нан алынды.



## МӘҢГЕЛЕК ТОРМЫШ (6+)

Петр Кончаловский, Аристарх Лентулов, Роберт Фальк һәм башка бөтен дөньяга танылган рус рәссамнары – «сезаннизм» һәм примитивизм юнәлешләре осталарының эшләрен «Бубновый валет» күргәзмәсендә күрергә мөмкин. Күргәзмә Татарстан Дәүләт сынлы сәнгать музее тупланмаларына нигезләнеп оештырылган. Революциягә кадәрге Россиянең иң эре күргәзмә сәнгать берләшмәсе вәкилләренең картиналары бүген дә кыю фикерле булулары, оригиналь формалары һәм традицион кануннарны кире кагулары белән шаккатыра. Узган гасыр башында күпчелек эшләрнең җитди тәнкыйтьләнүе очраклы түгел: аларны күпертелгән, эпатажлы, тәмамланмаган эшләр дип атыйлар, ә рәссамнарны рәсем сәнгате законнарын белмәүдә гаеплиләр. Ә бүген бу эшләргә белгечләр һәм сәнгать сөючеләр сокланып карый.

**Сишәмбе–якшәмбе, 11-00 - 20-00 сәг. Дүшәмбе – ял көне**
**ТР ДССМ Заманча сәнгать галереясы**
**Казан ш., Карл Маркс ур.,57**

## ИСЛАМ СӘНГАТЕНДӘ ДӨНЬЯ МОГҖИЗАЛАРЫ (6+)

Мөселман җәннәте дүрт зур елга ярында урнашкан, аларның икесе (ә бәлки, дүртесе дә) бер үк вакытта җир буйлап ага икән, диләр. Зөя – зур елга ярында урнашкан музей утравы – тамашачыны җир елгасы ярларыннан оҗмах бакчаларына алып бара торган күргәзмә тәкъдим итә. Анда «тукталмый торган сулы елгалар, тәме үзгәрми торган сөт елгалары, эчүчеләргә ләззәт бирә торган шәраб елгалары һәм чистартылган бал елгалары» ага... Керамика, бронза һәм көмештән ясалган касә һәм чүлмәкләр, укалап, ефәк җеп белән чигелгән пәрдәләр, ялтыравык йөгертелгән чынаяклар, зәркән бизәнү әйберләре, урта гасыр китап иллюстрацияләрен һәм хәзерге рәссамнарның әсәрләрен үз эченә алган мөселман сәнгате әлеге дөньялар аша алып баручы булып хезмәт итә. Рәссам илһам ала торган фантазия дөньясы пәйгамбәрләргә ачышлар иңә торган шул ук фәрештәләр дөньясы дип санала. Мәрҗани фонды (Мәскәү шәһәре) тупланмаларына нигезләнеп оештырылган «Җәннәт сулары һәм җир елгалары. Ислам сәнгатендә дөнья могҗизалары» күргәзмәсе тамашачыга мөселман сәнгате мантыйгын аңларга һәм, Җирдәге образларның матурлыгы белән ләззәтләнеп, аларда оҗмах билгеләрен күрергә тырышырга тәкъдим итә. Экспозициядә йөздән артык әйбер – рәсем, графика, скульптура, керамика, кыйммәтле металлардан эшләнгән предметлар бар. Күргәзмәнең күп кенә экспонатлары халыкка беренче тапкыр күрсәтелә, башкалары, киресенчә, – Фонд коллекциясенең иң танылган җәүһәрләре.

**30 июльгә кадәр. Көн саен 09:00 дән 18:00 гә кадәр.**
**Шимбә һәм якшәмбе 09:00 дән 18:30 га кадәр**
**Сәнгать галереясы, Зөя утрау-шәһәре**

## ТӨСЛЕ «АРАФ» (12+)

Төркия рәссамы Рәшит Алтун күргәзмәләре АКШ, Франция, Польша һәм башка илләрдә уңыш белән барган. Хәзер аның иҗаты белән Казанда танышырга мөмкин. Рәссамның картиналар сериясе «Араф» дип атала, бу исә тамашачыны борынгы чорларга алып китә, бүгенге дөнья турында җитди уйланырга мәҗбүр итә. Нәкъ менә бу серия «Башта» күргәзмәсенең нигезенә салынган. Картиналар болытлардан югарырак, өстән карап ясалган кебек тоела, шуңа күрә тамашачы, эш вакытында рәссам кайда булды икән, дип кызыксына. «Араф»та рәсем сәнгатенең мистик асылы күрсәтелә. Әлеге картиналарда шулай ук пространствоның ниндидер субстанциягә әверелүен күрергә мөмкин. Рәссам исә бу әверелү мизгелен туктатып, аны киндергә күчергән кебек тоела.

**23 июльгә кадәр**
**ТР ДССМ Заманча сәнгать галереясы**
**Казан, Карл Маркс ур., 57**

# ФУТБОЛ БӘЙРӘМЕ КАЙТАВАЗЫ

Муса Юлдашев

Хәтерлисезме ул көннәрне? Казан урамнарында бәйрәм рухы. Елмаюлы йөзләр. Оттыручыларның күз яшьләре. Мәңгелек көндәшләрнең туганлашуы. Төрле телләрдә сөйләшсәләр дә, бер-берсен җиңел аңлаучы җанатарлар. Бәхет, шатлык атмосферасы. Биш ел элек Казанда футбол буенча дөнья чемпионаты матчлары үтте.

Бу бәйрәм мәңге дәвам итәр кебек тоелды. Ләкин гомуми шатлык дулкыны бик тиз килгән кебек тиз генә китеп тә барды. Нәрсә калды соң? Дөньякүләм бәйрәмнән калган җылы истәлекләр, аңа бәйле урыннар калды. Алар бүген дә туристларны Казанга тартып тора. Килгән кунакларга казанлылар бик теләп ярдәм итә: үзләре дә бу көннәрне сагына чөнки.

Менә тимер юл вокзалы янындагы «Рамада» кунакханәсе артында артык күзгә ташланмый торган ишегалды. Хәер, күзгә ташланмый дип тә әйтеп булмый, чөнки йортның стенасына бөек Лионель Месси һәм Лука Модрич сурәтләре төшерелгән! Аларга якынрак килү өчен өчен кырыс вахтерша яныннан узарга кирәк. Ләкин кунакларның ихлас кызыксынуын күреп, ул да йомшара, үзе дә безгә кушлып китә.

– Тегендәрәк тагын берсе бар – Роналду!

Барысы да рәсем белән ләззәтләнгәндә, экскурсовод мураларның «сихри көче» турында да сөйләп ала. Месси һәм Роналдуны кунакчыллык йөзеннән чемпионат алдыннан махсус ясаганнар – уенчылар үз портертларын күреп илһам алсын өчен, чөнки алар икесе дә бу кунакханәдә яшәгән. Ләкин нәтиҗәдә аларның командалары чемпионаттан төшеп кала. Мураларның «яшерен сихри көче» турында ишеткәч, Россия белән Хорватия уйнар алдыннан Лука Модричны да рәсемгә төшерергә ашыгалар. Ләкин монда «сихри көч» тәэсир итә алмый кала, чөнки мурал эшләнеп бетми...

Тагын бер раритетны иң ышанычлыларга гына күрсәтәләр. Юлдагы гап-гади чуен люк футбол буенча дөнья чемпионаты эмблемасы белән бизәлгән икән. Күз алдыгызга китерегез: иң тәвәккәл җанатарлар мондый зур һәм кызыклы сувенирны, мөгаен, күтәреп алып китәрләр иде! Шуңа күрә раритетның кайда булуын әйтмибез – фотосын гына күрсәтәбез. Өстәвенә, мундиал турында сөйли торган башка урыннар да җитәрлек. Чемпионатка махсус ачылган Фестиваль бульварында 33 гранит шардан торган скульптура композициясе бар. Беренчесе – зуррагы – безнең уртак планетабыз, калган 32се – катнашучы илләр. Янәшәдә генә бронза малайлар ишегалдында туп тибә: шундый малайлардан Роналду белән Месси кебек футболчылар үсеп җитә дә...

Ә мундиалның төп шаһиты – ул, әлбәттә, футбол аренасы. Чемпионат көннәрендә анда эләгү лотереяда зур акчалар отуга тиң иде. Ул көннәрдә футбол аренасы гөрләп торды. Монда машинасын ниндидер кореялылар бозып киткәнен күреп, Неймар күз яшьләрен яшерә алмады. Монда испаннарга каршы уенда Иран җанатарлары, кычкырып та, сызгырап та, барабан кагып та, үз командаларына көч бирергә тырышты. Монда Бельгия Бразилияне сенсацион рәвештә җиңгәннән соң, Латин Америкасы фанатлары тирән кайгыга чумды. Монда...

Хәер, бу уеннарның исәбе, отучылар һәм оттыручылар – инде күптән мөһим түгел. Алар барысы да футбол статистлары өчен генә. Без саклап калган иң мөһим нәрсә – стадиондагы, Казан урамнарындагы, Гаилә үзәге янындагы фан-зонадагы бәйрәм рухы. Бөтен кеше бәхетле, бер-берсе белән дус чактагы атмосфера... Һәм һәр кунак, кайдан гына килгән булса да, Татарстанга, Россиягә мәхәббәтен белдергән чак. 2018 елның июль көннәрендә шулай булды.

Һәм тагын шулай булачак әле.

Муса Юлдашев фотолары

ЧМ 2018



НИЖНЕКАМСК

ТАТМЕДИА

# ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

KazanExpress

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АҖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама